1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2020 ГЫЙНВАР № 1

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



БАЛАГА **хыянәт**
кыргыйлар дөньясы...


серле САНДЫККА НИ СЫЯ?!
гореф-гадәт

гафу иттем, ТИК КАЛМАДЫМ
ачыктан-ачык

Лена КОЛЕСНИКОВА:
«Эшең уңышлы буласына ышанырга кирәк!»

Хәтер – мәңгелек...

Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас... Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.



Сәхифәбезне гап-гади Әгерҗе егете Закирҗан Әхмәт улы Әхмәтовтан башлап җибәрәбез. Сугышка ул 1942 елда чыгып китә. Беренче көннән үк аның иң дәһшәтле, канкойгыч урынына – Сталинград фронтына эләгә. Яралана... Госпитальдән соң Икенче бөтендөнья сугышының хәлиткеч бәрелешләренең берсендә – Курск дугасында катнаша. Соңыннан Ленинград фронтына җибәрелә. Сугыш тәмамлануга ул Әгерҗегә – хатыны, кызы (минем әнием), улы янына әйләнеп кайта. Тагын бер кызлары туа... Выборг операциясендә күрсәткән батырлыгы өчен маршал Леонид Говоров бабамны гаиләсе белән Ленинградта төпләнеп калырга, бу шәһәрнең «мактаулы гражданы» булып яшәргә чакыра. Әмма Закирҗан туган ягында калуны хәерлерәк күрә...

P. S. Частьтан киткән кулдан гына язылган хатта (стиле үзгәртелмәде) мондый юллар бар: «Тов. Ахметов З. А. в период боевых действий на высоте 164,7 6.07.43 года расчет его пулемета, при движении пехоты за танками метким ураганным с дальней дистанции разил врага, не давая ему продвинуться вперед и вклиниться в нашу оборону. При наседающей пехоте противника Ахметов менял позицию и продолжал вести смертельный огонь. Отразил несколько атак противника и поддерживал огнем подразделения.
Тов. Ахметов достоин Правительственной награды ордена Красной Звезды».

Лариса МАЛИКОВА

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

Фамилия, имя и отчество-АХМЕТОВ Закир Ахметович
Военное звание-красноармеец
Должность-Пулеметчик 8 батареи 110 Отдельной Зенитной Артиллерийской Бригады ПВО

Представляется к награждению орденом "КРАСНАЯ ЗВЕЗДА"

1. Год рождения-1907г.
2. Национальность-Татарин
3. Партийность-беспартийный
4. С какого времени в Отечественной войне-С 11.4.42г.
5. С какого времени в Красной Армии-С 11.4.42г.
6. Имеет ли ранения или контузии-Два тяжелых и одно легкое в 1942-1944гг.
7. Каким РВК призван-Агрызским РВК Татарской ССР.
8. Чем ранее награжден-Наград не имеет.
9. Постоянный домашний адрес-

I. КРАТКОЕ КОНКРЕТНОЕ ИЗЛОЖЕНИЕ ЛИЧНОГО БОЕВОГО ПОДВИГА ИЛИ ЗАСЛУГ.

В борьбе с немецко-фашистскими захватчиками, на фронтах Отечественной войны, показал себя мужественным и стойким защитником Родины. Участвуя в боях под Сталинградом 15.12.42г. был тяжело ранен. Находясь на Белградском направлении, в составе действующей Армии, 28.8.43г. был легко ранен и не покинул поле боя, воодушевляя своих товарищей на боевые подвига. Принимая участие в наступлении войск 2 Украинского Фронта 28.10.1944г. был третий раз ранен. За период службы на батарее показал себя дисциплинированным, трудолюбивым и хорошо знающим свою специальность бойцом. Материальную часть содержит в чистоте и исправности. За образцовую службу и примерную дисциплину от командования батареи и дивизиона имеет ряд благодарностей.

Командир 110 ОЗАБр ПВО
Полковник- /Тимошенко/

Начальник штаба 110 ОЗАБр ПВО
Майор /Морозов/

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: Анна Арахамия

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Лена Колесникова
Фото: шәхси архивтан

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 13.01.2020 ел.
Заказ А-17
Тираж 4010

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



PRESSA

Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!
Яңа елда беренче очрашуыбыз. «Сөембикә»безне үз иткән һәркем белән кабат күрешүләр шундый рәхәт... Шактый зур вакыйгалар көтә безне быел: Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгы, ТАССР төзелүгә 100 ел, Президент сайлаулары, Бөтенроссия халык санын исәпкә алу...
Республикабыз юбилее уңаеннан башлап җибәргән сәхифәбезне күбегез яратып өлгерде инде. Дөресен әйтергә кирәк, шактый мәшәкатьле, әмма мавыктыргыч эш булып чыкты ул. Тик ул елларда журнал тышлыгында чыккан хатын-кызларны барыбер табабыз! Очрашабыз, язмышларының Татарстаныбыз язмышы белән тыгыз үрелеп баруын, тормышларында журналның зур роль уйнавын ишетеп, кабат шаккатабыз...
Җиңүнең 75 еллыгы... Бер карасаң, сугыш инде бик еракта калган кебек. Әмма яу кырында башын салган каһарманнарның тол хатыннары, ятим үскән балалары җанында әрнү булып яшәгәндә, ул бездән берничек тә ерак була алмый. Хәтер яшәгәндә, безнең бүгенгебез өчен гомерен кызганмаган батырлар рухы да яшәр... Шул уңайдан уйланылган сәхифәләр шактый. Тышлыгыбызның икенче битендәге яңа проектка аерым тукталасым килә.
Абый белән бабабызның алдына утырып, орден-медальләрен тотып карый-карый, сугыш истәлекләрен сөйләтергә өлгергән буын әле без. Ә бүгенге яшьләр Бөек Ватан сугышы турында бары кинодан, әдәби әсәрләрдән, дәреслекләрдән генә белә.
«Сугыш – бабамның язмышында» дигән фәнни-тикшеренү эшен әзерләгәндә кызым интернет челтәрләрендә бабам турында тарихи документлар тапты: ул хезмәт иткән хәрби часть җитәкчелегенең аны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләргә тәкъдим итү турында кулдан язган хатны һәм бүләкләү турындагы приказны. (Яңа сәхифәбезне шул документлардан башлап җибәрәбез дә). Кызларыма бабам турында еш сөйли идем, билгеле, тик бу документлар табылгач, алар кинәт үзгәрде. Ерак бабалары белән якыннан танышкан кебек булдылар. Батырлыгы белән чын-чынлап горурландылар. Сугышның безнең нәселгә кагылган өлешен тойдылар...
Бу приказларның күчермәсен абыема да бирдем, туганнан туган энеләрем гаиләләренә дә тараттым. Хәзер ул аларда да кадерле ядкарь булып саклана. Сезне дә бу проектта катнашырга чакырабыз: сугыш кырыннан кайта алмаганнар рухына бер дога булыр ул...

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Фото: Анна Арахамия

Безнең тышлыкта



«Бер-ике елдан яшьләр «Татар кызы» конкурсын оештыруны төбәкләрдәге җитәкчеләрдән үзләре сорый башлады. Бөтендөнья татар конгрессына рәхмәт – алар күтәреп алды.»

10

Омтылган – зурга омтылыр!
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без



6

Балага хыянәт
Чулпан Галиәхмәтова

Безнеке... үзебезнеке! 18
Мәдинә Авзалова






21

Менә шундый ул!..
Эльмира Закирова

ЭЧТӘЛЕК

Татар дөньясы



22 Яхшы хатын – диннең яртысы
Гөлнур Сафиуллина

26 «Минем өчен балаларым дәрәҗә»
Раилә Хәялиева



30 Сандык тулы байлык, сандык тулы сер...
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш



37 Кыз вөҗданы
Диләра Зөбәерова

Яшәеш



48 Үз бәясен белгән хатын-кыз көчле ул...
Чулпан Галиәхмәтова



52 Америка
Роза Динмөхәммәтова

Хуҗабикә

62 Котлет... яшелчәдән



60 Корольләр табыныннан



АКТУАЛЬ ТЕМА



БАЛАГА ХЫЯНӘТ



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

XXI гасырның егерменче елын ваклыйбыз. Яңа технологияләр, инновацияләр заманасы көн саен яңалыклар, ачышлар белән шаккаттыра. Әйе, кешелек алга барырга, камилләшергә тиеш кебек. Тик кайчак әле һаман үзебезне кыргыйлар кебек тотабыз. Җитеш тормышыбызда, әдәп-әхлак ни өчен дөнья малы белән бергә үсми икән ул? Кайбер чакта, нигәдер, адашып кала. Ә нәрсә мәҗбүр итә аны адашырга? Рухи байлык җитмәүме? Ул булмаса, кеше әхлакый яктан үлә, диләр. Җәмгыять әнә шундый үлем бусагасы алдында тора микән әллә? Югыйсә алда язылачак хәлләр булмас иде бит…

Үз нарасыеның җанын кыйган... Берничек тә аңлатып булмый торган кансыз җинаять... Иң зур гөнаһ! Тугыз ай буе йөрәк астында йөрткән, аның йөрәк тибешен сизгән, ачыргаланып, сират күпере кичеп тапкан сабыең дөньядагы дәвамчың бит ул. Ана – бала өчен иң изге фәрештә, яклаучы, бала аны бөтен барлыгы белән ярата, тоя. Ике арада хыянәт турында сүз дә булырга тиеш түгел кебек. Ә менә тормышта, кызганыч, очрый. Менделеевскида бер атаның ике баласын үтерүе шомландырды. Исерек хәлдә булган ул, ата кеше – ата каз дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр дип, бу фаҗигане үзебезчә аңларга тырышсак, Чаллыда ике баласының гомерен өзгән анага нәфрәтләндек. Бу адымга ничек баралар? Язмабызда әлеге проблеманы белгечләр фикерен тыңлап һәм дин күзлегеннән чыгып аңларга тырышып карадык.



Казан дәүләт медицина академиясенең психиатрия һәм суд-психиатрия кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты, психиатр Лилия МИҢНЕТДИНОВА:

«...Аерылу, милек бүлү, ир кайтару, көнләшү кебек очракларда сөеп-назлап үстерелгән балалар ата-аналар өчен шантаж коралына әйләнә дә куя...»

Статистика ни сөйли?

Мәскәүдә социаль сферада попечительлек мәсьәләләре буенча Совет утырышында чыгыш ясаган Россия Эчке эшләр министрлыгы вәкиле Станислав Колесник белдерүенчә, соңгы дүрт елда ата-аналарның балаларына карата кылган җинаяте 92 процентка, аерым алганда, үтерү очраклары ике тапкырга арткан. Җәзалау фактлары 48 процентка үскән. Узган елның алты аенда балаларына карата рәхимсез мөнәсәбәттә булган ата-аналарга бер меңнән артык җинаять эше кузгатылган.

Татарстан Республикасының Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Гүзәл Удачинаның еллык докладына күз салыйк. Республика Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2018 елда балаларга карата көч куллану җинаятенең 1137 очрагы теркәлгән. Аларның яртысы, төгәл итеп әйтсәк, 518 е рәхимсез гаилә әгъзалары өлешенә төшә. Әлеге җинаятьләрнең күп өлеше балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына карата эшләнә. Шундый 661 очрак теркәлгән. Һәм аларның 48 проценты гаиләдә булган. Тәгаенләп әйтсәк, 142 җинаятьне ата-аналар (тәрбиягә алган ата-аналар) кылган. Узган ел ахырында Татарстанда әтиәни тарафыннан дүрт бала үтерелә. Һәм шуны әйтергә кирәк: алар социаль яктан куркыныч хәлдә яшәгән гаиләләрдә үскән балалар түгел.

Көнчелек уты балага тия

Баласының җанын кыйган хатын-кызларның барысын да бер әйбер берләштерә – бәхетсез шәхси тормыш. Күрәсең, бала Ходайдан сорап алынмаган. Ире ташлаган, авырын төшертергә өлгермәгән, гаиләдә бала белән кабул итмиләр – иректә әхлак заманында, кызганыч, мондый язмыш сценарийлары күп. Хатын-кыз үз проблемасын хәл итү юлын таба алмый, нәтиҗәдә, аны бар нәрсә ярсыта, бөтен ачуын баладн ала. Бәхетсезлегендә аны гаепли. Күпмедер вакыттан соң агрессия фаҗигагә китерергә мөмкин. 2015 елда үткәрелгән Америка галимнәре тикшерүләреннән күренгәнчә, әниләрнең 70 проценты яңа туган баласының төне буе көйсезләнүенә ачулы уйларын яшерми. Ә аларның чирегенә баланы үтерү уе килә хәтта.

Ата-ана баланың газраиле булган җинаять инфантицид дип атала. Ул берничә төрле. Яңа туган сабыйларны үтерү – неонатицид. Мондый аналарга җинаять кодексы буенча җәза җиңеләйтелә, бу элек-электән шулай, чөнки яңа гына баладан котылган хатын стресс хәлендә яши әле. Гадәттә, Татарстанда елына мондый төрдәге ике очрак теркәлә. Һәм ул елдан-ел тотрыклы булып кала.

Психологлар әйтүенчә, баланың 5 яшькә кадәр әнисе корбаны булу ихтималы зуррак. Кечкенәләр генә түгел, яшүсмерләр дә якын кешесе кулыннан җан бирә кайчак. Ә бит ананың бәбиләгән вакытта кичергән стресс халәте шул вакытка кадәр сузылмый, димәк, башка сәбәпләр бар. Моны ачыклар өчен Казан дәүләт медицина академиясенең психиатрия һәм суд-психиатрия кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты, психиатр, психотерапевт Лилия Миңнетдиновага мөрәҗәгать иттек. Галимә әйтүенчә, баласын үтергән кешеләр ике төркемгә бүленә: психик авырулар һәм психик яктан сәламәт кешеләр. Беренче категориягә керүчеләр күп түгел. Россия буенча алсак, алар саны хокук бозучылар арасында 11–14 процент, Татарстанда ул уртача 8 процент тирәсе. Психик сәламәт кешеләр җинаятькә эмоциональ яки рациональ рәвештә бара. Эмоциональ мотив белән җинаять кылучылар арасында ир-атлар да, хатын-кызлар да бар, тик соңгылары күбрәк, чөнки без эмоциональ халык. Аерылышу, милек бүлү, ирне кире кайтару, көнләшү кебек очракларда сөеп-назлап үстерелгән балалар ата-аналар өчен шантаж коралына әйләнә дә куя. Аларга карата кылынган җинаятьтә бу яшерен сәбәп булып тора да инде. Психиатр әйтүенчә, үч алу уе, көнләшү аффектка китерергә мөмкин. Ә ул вакытта кеше нишләгәнен белештерми башлый. Нәрсә кылганын аңлагач инде, үз-үзен үтерергә тели. Чаллыда булган фаҗигагә дә әнә

Фото: www.pixabay.com

Әниләрнең 70 проценты

яңа туган баласының төне буе елавына карата ачулы уйларын яшерми. Ә аларның чирегенә баланы үтерү уе килә хәтта.

шул көнчелек утында яну китерә бит. Көнләшү – җинаятькә этәргән иң көчле эмоциональ мотивларның берсе. Үз вакытында Мольер да: «Йөрәк белән акыл көрәшендә йөрәк җиңә», – дип язган. Баласының гомерен өзгәннәргә суд-психиатрия экспертизасы үтү мәҗбүри. Әлеге тикшерүләрне үткәргән Лилия Миңнетдинова җинаятьчеләрнең үзләрен төрлечә тотулары хакында әйтә. Әйе, күпчелеге үкенә, тик кайберләре үзенең хаклыгына ышана, һәм ул бу адымын максатына ирешүнең бер этабы итеп кабул итә. Монысы кешенең шәхесе, холкы белән бәйле инде.

Гормоннар гармониясе булмаса...

Узган ел Мәскәүдә 36 яшьлек әни 3 яшьлек һәм тугыз айлык ике баласын кочагына алып, суицидка бара. Ул үлемендә беркемне дә гаепләмәскә кушып, язу калдыра. Фаҗигадән соң, ире хатынының соңгы айларда гел үлем хакында сөйләгәнен әйтә. Психологлар, ана бала тапканнан соң була торган депрессиядә яшәгән, дип фаразлый. Бу халәтне күпләр авыруга санамый, аны дәвалау өчен хастаханә юлын таптамый, бигрәк тә яшь әниләр. Ә мондый депрессия күпләрдә күзәтелә. Бу чорда баласын үтерүгә үк барып җитүчеләр күп түгел, шулай да бар. Психиатр сүзләренә караганда, патологик депрессия елдан-ел арта. Мондый вакытта ана баласына игътибар итми, йә иң куркынычы – җинаять кыла. Алар тирә-якта нәрсә булганын аңлап бетерә алмый.

Хатын-кызның депрессиядә булуын ничек ачыкларга соң? Психиатрлар аны махсус критерийлар ярдәмендә билгели. Тик моның өчен табибка йөрергә кирәк. Ә берничә атна инде кәефем юк, дип, белгечкә консультациягә бару бездә әле кабул ителмәгән. Тирә-яктагылар да көйсезләнүдән туктар әле диебрәк кенә карый, әллә ни әһәмият бирми. Тик бу игътибарсыз калдыра торган хәл түгел. Психиатр әйтүенчә, әгәр хатын-кыз бик тиз алҗый, аны бернәрсә дә кызыксындырмый, һәрвакыт зарлана, елый, борчыла, ярсып китүчәнгә әйләнә икән, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Балага карата патологик ярату да депрессия билгесе булырга мөмкин. Табиблар белдерүенчә, хатын-кыз башына да китереп карамаган яшерен психик авырулар күп очракта бала тапканнан соң кискенләшә. Ул шулай ук авырга узгач та, климакс вакытында да килеп чыгарга мөмкин.

– Нәрсә этәрә моңа, беркем дә сәбәбен белми. Белсәк, авырулар да булмас иде. Ә менә мондый халәтне китереп чыгарган механизм билгеле. Бу нейромедиаторлар эшләп чыгару белән бәйле. Нейромедиатор үзе серотонин, норадреналин, дофамин, мелатонин гормоннарыннан тора. Алар уйлау сәләте, хәтер өчен җаваплы. Әнә шул дүрт гормон безнең кәефне билгели. Ниндидер бер фактор бу гормоннарның эшчәнлеген үзгәртә. Ул нәселдән килгән сәбәпләр, экология, агулану, травма, инфекция булырга мөмкин. Шулай ук озакка сузылган стресс та тәэсир итә. Хатын-кызларда барган гормональ чорларны да онытмаска кирәк, – ди психиатр Лилия Миңнетдинова.

XIX гасырда ук француз галиме күрем алды синдромы вакытында хатын-кызларда агрессия артуына игътибар итә. Үзенең тикшеренүләрендә галимә дә моны раслый. Бу чорда ул хатын-кызларның гормональ фоны үзгәрү белән бәйле. Кубань дәүләт университеты тикшеренүләреннән шул ачыклана: балаларын үтерүче хатын-кызларның яртысы кияүдә, аларның башка балалары да бар һәм бәбиләгәннән соң психикасына да зыян килгән. Алар 25–35 яшьләрдәге ханымнар. Бу – бала табу өчен иң яхшы чор дип исәпләнә.

Балачак ядкаре

Оясында ни күрсә, очканында шул булыр дип тикмәгән генә әйтмәгән борынгылар. Кечкенә чакта алган тәрбия балаларның киләчәк тормышында зур роль уйный, язмышларын билгели дип әйтсәк тә, ялгыш булмас. Аның нинди гаиләдә үсүе бик мөһим. Назга төренгән, бер-беренә хөрмәт булган, тормыш кыйммәтләре дөрес куелган гаиләдә үскән балалар үз юлларын тапмый калмый. Ә киресенчә икән... Россия суд психиатрлары тикшеренүләре ачыклавынча, баласын үтерүгә барган хатын-кызларның 68 проценты уңышлы булмаган гаиләдә тәрбияләнгән, ә 85 процентының үз гаиләсендә конфликтлар булган. Әлеге саннар турыдан-туры балачак хатирәләре белән бәйле. Алдау, җәнҗал, сугышу, кимсетү, эчүчелек үсмер кыз тормышының аерылгысыз бер өлешенә әйләнә икән, ул инде аны киләчәктә үз гаиләсенә дә күчерми калмый. Сабыеның газраиле булучылар, нигездә, балачакта эмоциональ, сексуаль һәм физик көчләү кичергән хатын-кызлар. «Бу җинаятькә барган хатын-кызларның 20 проценты гына исерек хәлдә була», – ди Лилия Миңнетдинова. Яңа туган балаларның гомере күбрәк авыл җирендә кыела. Һәм, гадәттә, сабый гаиләдәге беренче бала да булмый. Коточкыч социаль хәлене түзә алмаудан, йә балачак хатирәсе тәэсирендә хатын-кыз шул адымга бара. «Миңа да авыр. Балама да авыр булмасын, интекмәсен», – дип, шул рәвешле балаларын «коткарырга» уйлыйлар, ди табиблар. Ә үскән балаларның гомере рәхимсез аналар кулыннан шәһәрдә күбрәк өзелә. Мондый төр җинаятьләрнең 60 проценты калада яшәүчеләргә туры килә. Стресслар, кредит чокырлары, ир белән хатын арасында мөнәсәбәт-

ләр ачыклау белән аңлата моны белгечләр.

Ярата белеп яратсаң...

Күз ачканда – дүшәмбе, йомганда инде җомга көн булган нindидер ыгы-зыгылы агрессив дөньяда яшибез шул. Чабабыз, бернигә җитешмибез, даими стресс кичерәбез. Шуңа күрә дә хәзерге заманда невроз, депрессия кебек психик үзгәрешләрдән интегүчеләр саны арта. Бер мәлгә туктап калып, иң соңгы чиккә җитмәс өчен нишләргә кирәклеген уйлап та карамыйбыз. Ә бит стресска каршы профилактика гап-гади, һәм күпләр аңа кул гына селти. Физик хезмәт, кояш яктысында саф һавада сәгать ярым булса да йөреп кайту никадәр мөһим юкса! «Моннан кала, булган хәлләрне аек акыл белән кабул итеп, анализларга һәм онытырга өйрәнергә, тешне кысып түзеп яшәргә кирәкми», – ди психиатр. Дөрес, кеше тормышындагы икътисадый шартлар да тәэсир итми калмый. Тормыш кыйммәтләренең үзгәрүе дә гаиләдә кризис китереп чыгара. Күрәсең, балалар да Аллаһы Тәгалә бүләге дип кабул ителми башлады. Югыйсә баланың бер укмаш каннан үсеп, дөньяга тууы чынлап та могҗизага тиң, һәм ул бәхет, кызганыч, күпләргә бирелми. Баласын кочагына алганда ана әнә шул хакта уйлансын иде. Бала бит ул бәгырь ите. Әлеге кыйммәтләрне аңлап яшәсен иде дә соң аналар... Бит тиресен, фигураны кайгырту белән беррәттән, психик халәтеңә дә игътибарлы булу кирәк шул!

Бала иң элек ана яратуына мохтаҗ! Ә аны, кызганыч, кибеттән сатып алып кына булмый. Ул тормыш кыйммәтләре дөрес итеп куелган, яратуга корылган, әхлаклы, иманлы гаиләдәге тәрбиядән килә. Дөньяны, кешелекне бары ярату гына алга алып бара. Чын ярату гына кеше күңелендә изгелек һәм миһербанлылык арттыра. Күңеле мәхәббәт, наз белән тулган ана гына үзеннән соң лаеклы дәвамчылар, бакыйлыкка күчкәч, аның рухына дога кылучылар калдыра ала. Тормыш агышы әнә шул вакытта гына дөрес һәм камил була түгелме соң?!

ДИНСЕЗ ТОРМЫШ ҺӘЛАКӘТЕ



Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН, «Гаилә» мәчетенең имам-хатыйбы

Кеше гомерен өзү – зур гөнаһ. Аллаһы Тәгалә иркендә була торган әйбергә кешеләр кул сузарга тиеш түгел. Баланың ата-аналар тарафыннан җәберләнүенә, хәтта ки җаны кыелуына бары тик иманлы булмау сәбәп. 70 ел динне халык өчен опиум дип расларга тырыштылар. Мәчет манараларын кисеп аударды-лар, чиркәүләрне бетерделәр, муллаларны аттылар, мәдрәсәләрне яптылар, динне юкка чыгардылар. Аны башка кыйммәтләргә, башка нигезләргә алыштырырга тырыштылар. Без – совет чорында үскән өченче буын. Өченче буында да әле динсезлек, әдәп-әхлак юк: Алла күрә, Алла белә, фәрештәләр яза, начарлык эшләгән кеше, бу гөнаһ дип, башына да китерми. Ул аны аңламый. Ул белми. Әйе, алар арасында күпмедер процент чирле, авырулары да бардыр. Төрле хәлләр булырга мөмкин, аны аңлап була. Ләкин күбесенчә – динсезлек сәбәп. Хәзерге вакытта нинди социаль чирләр бар – барысының да тамыры әнә шуннан килә. Ә бит дин моның бөтенесен саклый, бер калыпта тота иде.

Дин – намаз, ураза гына түгел, ул – рухи тынычлык. Телевизор, компьютер ише техника ял итәргә тиеш булган кебек, кешеләр дә аңа мохтаҗ. Ә без ял итә белмибез. Ял итик әле дибез дә, социаль челтәрләргә кереп китәбез. Ә анда күпме мәгънәсез, кирәксез мәгълүмат. Тулысынча ял итәр өчен дөньяны онытып торырга тиешбез. Ә бу кайчан була ала? Тәһарәт алып, намазлык өстенә басып, Аллаһы Тәгалә каршына баскач... Кеше рухи яктан ял итә алмый икән, депрессиягә барып җитәчәк. Дин күңел тынычлыгы бирә. Намазга баскач, башыбыз ял итә. Менә шуны онытмыйк. Шуңа күрә динсез яшәп булмый.

ОМТЫЛГАН – ЗУРГА ОМТЫЛЫР



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Аның «Чиләбе өлкәсе татарлары конгрессы» иҗтимагый оешмасының Башкарма комитеты рәисе итеп сайлануына ун ел булды. Ун ир-егеткә бүлеп бирердәй зур йөк! Хәер, йөкләр җитәрлек аңарда. Тагын – Чиләбе өлкәсенең Иҗтимагый палата әгъзасы. Чиләбе өлкәсе Кануннар чыгару җыелышы депутаты... Халыкара «Татар кызы» бәйгесенең Дирекция җитәкчесе. Лена Рафыйк кызы КОЛЕСНИКОВАны – татар дөньясында иң уңышлы хатын-кызларның берсе дип беләбез. Ә уңышка ирешкән гүзәл затларның барысына да хас уртак сыйфатлар бар. Аның мисалында моның чыннан да шулай икәнен раслыйсы килә.

НӘРСӘГӘ ТОТЫНСАЛАР ДА, АЛАР АНЫ МАВЫГЫП ЭШЛИ

– Әгәр үземә тапшырылган эшнең бер кызыклы ягын тапсам, аның кемгәдер файда китерәсен аңласам, ул шунда ук мине бөтереп ала! Һәр проектның исә иҗади ягы булмый калмый. Ирем оештырган «Классика» даруханәләр челтәрен җитәкли башлаганда безнең фармацевтлар прилавка артында, пыяла тәрәзә артында утыра иде әле: киштә янына барып, дару кабын кулга тотып карауны күз алдына да китереп булмый. Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү системасын кертү Чиләбе өчен зур яңалык булды: даруханәләребез иркенәйде, яктырды, матурайды. Балаларымның кечкенә чагы иде әле, шуңа күрә даруханәдә сабыйлар өчен берни булмавына да игътибар итми кала алмадым. Шәһәрдә беренче булып балалар ассортиментын алып кайттым. Имезлектән, шешәдән башлап уенчыкка кадәр. Биологик актив кушылмалар бүген генә модага керде, ә без аларны инде шул чакта ук саттык. Интерьерны яңарттык, олы кешеләргә утырып торырга урыннар булдырдык, кан басымын бушлай үлчи башладык. Компания эчендә уку үзәге оештырдык: фармацевтлар анда белемнәрен күтәрде. «Классика» 200 даруханәне берләштерә, анда яшь кызлар да бик күп иде. Алар арасында «Мисс-Классика» конкурсы үткәрә башладык. Шуңа күрә конгресска килгәч, «Татар кызы»на һич икеләнмичә тотындым: мондый бәйгенең яшьләр өчен кирәген белдем.

Дөресен әйтәм, Чиләбедә татар конгрессы барлыгын аңарчы ишеткәнем булмады. Һәм кинәт миннән аны җитәкләүне сорыйлар! Иң беренче бу тәкъдимне шәһәр башлыгы җиткерде – без аның белән күршеләр. «Шаяртасыздыр», – дидем... Аннан шушы ук сүзне ирем әйтте. Аптырап калдым... Өченче тапкыр яныма эти килде... Башкарма комитет әгъзалары белән танышырга баруым истә. Килдем, беркемне белмим. Барысы да татарча сөйләшә, ә мин аңласам да, җавап бирә алмыйм... Сания Шевченко белән Ирек Сабиров: «Барысы да сезне булдыра дип әйтә», – диләр. Ризалашсам да, үземнән ни көткәннәрен белми идем әле... Икенче көнне үк Троицк шәһәренә, татар-башкорт китапханәсенең 120 еллык юбилеена чыгып киттек. Төн утырып татарча чыгышымны ятладым. Мине шундый җылы каршы алдылар! Күзләрендә өмет күрдем... Шул беренче мизгелне хәтерләп калдым – ул бу эшнең халыкка кирәклегенә инандырды. Кирәклегемне, файда китерә аласымны тойганда мин таулар күчерә алам...

Бу вазыйфага керешкәч, бер нәрсәне аңладым: «Чиләбе өлкәсе татарлары конгрессы» дип аталса да, өлкәдә аның барлыгыннан хәбәрдар түгелләр. Бер ел буе өлкә буйлап йөреп, андагы татарлар белән очраштым. Кайда татар үзәге бар, кайда ансамбль, кайда китапханә... Аның каравы, бу безгә берләшергә ярдәм итте.

Кая гына барсам да, бөтен җирдә очрашуга өлкән яшьтәгеләр генә килүенә игътибар иттем. «Татар кызы» – яшьләрне берләштерү проекты булырга тиеш иде. Кызлар булган җирдә егетләр дә җыелыр дип уйладык. Сайлап алу турлары үткәрдек. Ә финалны «Трактор»да – 7 мең кеше сыешлы залда үткәрдек! Берничә максатка берьюлы ирештек: Чиләбе өлкәсе хөкүмәтен конгресска йөз белән бордык. Мәдәниятебезне яңа ягы белән һәм зур масштабта күрсәттек. Хөкүмәт уйланып калды, өлкәдә яшәгән милләтләргә игътибар итәргә кирәклеген аңлады. Бездән соң башкортлар да, башка үзәкләр дә ниндидер бәйгеләр үткәрә башлады – конгресс аларны үз артыннан ияртте.

«Хәзинә» газетасы һәм шул исемдәге тапшыру чыга башлады. Конкурс, газета һәм тапшыру кон-

Шушы 10 ел эчендә бер белмәгән кешеләрнең: «Рәхмәт, Лена!» – дип килеп әйткәннәре еш булды. **Бу сүзләр алга таба атларга көч бирде.**

грессны танытты да инде. Һәм Чиләбе өлкәсендә генә дә түгел. Муса Җәлил исемендәге шигырь укучылар конкурсын да беренче елны ук башладык. Андагы катнашучыларның күплеге! Әйтерсең аны бөтенесе дә көтеп кенә торган!

Шәһәр паркында уза торган өлкә Сабан туен шәһәр янындагы болынга алып чыктык. Иң беренче елны ук губернаторга кердем: «Әйдәгез, ничек тиеш – шулай үткәрик, табигатьтә узсын!» – дидем. Иң беренче Сабантуй 40 мең кешене җыйды!

2010 елда беренче тапкыр татарча «Голубой огонек» төшердек. Ул экранга чыккач, өлкә каналының рейтингы кинәт югары күтәрелде. Яңа елдан соң өч тапкыр кабатлап күрсәттеләр. Алып барырга Руслан Шәрәфетдиновны чакырдык. Ул чакта үзебезнең татарча алып баручыларыбыз юк иде әле. Хәзер бар – конгресс проектларында үстеләр. Безнең проектта катнашучылар, гадәттә, конгресс тирәсеннән инде китми – үзләре оештыручыга әйләнә.

АЛАР БИК ЕШ ҖИТӘКЧЕ УРЫННАРГА КҮТӘРЕЛӘ

– Ирем оештырган «Классика» даруханәләр челтәренә 1993 елны килдем. Миңа ул чакта 24 яшь иде. 1997 елда инде компания үз кулыма гына калды... Әмма бер көндә генә берәү дә җитәкче булмый, барысы да күпкә алдан башланган дип саныйм. Мәктәпкә кергәнче үк пионер булырга хыялландым. Кызыл галстук тагуга башта звено, отряд советы, аннан дружина советы председателе булдым. Институтта комсорг итеп сайландым. Моңа омтылмасам да, шулай килеп чыкты. Үземне артык кыю дип тә әйтә алмыйм, әмма беркайчан тик кенә утырып тора белмәдем. Миңа гел нәрсәдер оештырырга кирәк. Әле менә яңа гына Чесменск районындагы бердәнбер татар авылы Редутта булдык. Чиләбедән өч сәгать ярым барырга кирәк аларга. Барлык гореф-гадәтләрне саклап яшиләр. 2010 елда «Татар кызы» бәйгесе белән анда каз өмәсе үткәргән идек. Без килеп киткәч, район җитәкчелегенең мөнәсәбәте дә үзгәрде аларга: шунда ук «Татар мәдәнияте музее» ачарга рөхсәт иттеләр. Бик кунакчыл бер әби: «Миннән соң да өем буш тормасын», – дип, йортын музейга васыять итеп калдырган. Экоканикулга туристлар килә, шунда берничә көн яшиләр, сыер, тавыкларны карыйлар. Чиләбе хөкүмәтенә: «Редут – экотуризм ноктаnumberларының берсе булсын», дигән тәкъдим белән чыктык хәзер без.



PRESSA

Бүгенге яшьләр дөньясы безнекен кысрыклап чыгарачак, тик аларныкы да татар дөньясы булып калачак.

УҢЫШКА ИРЕШӘЧӘКЛӘРЕНӘ ҺӘРВАКЫТ ЫШАНАЛАР

– Уңышка ирешәчәгеңә ышаныч юк икән – эшкә тотынмасаң да була. Икеләнергә дә ярамый. Янында фикердәшләр булу да бик мөһим. Тик менә «Татар кызы» мондый зур проект булып китәр дип уйламадым, билгеле. Ул чакта төп максатым – Чиләбе өлкәсе яшьләрен туплау иде. Беренче елны ук конкурстан соң Минтимер Шәрипович үзенә дәшеп алды. «Әйдә, Лена, тотын», – диде... Шулай итеп, «Татар кызы» Бөтенроссия күләмендәге бәйгегә әйләнде: аңа Курган белән Екатеринбург кушылды, аннан Пермь, Төмән...

АЛАР ТӘВӘККӘЛЛӘҮДӘН КУРЫКМЫЙ

– Мин, чынлап та, тәвәккәл! Моны хәзер үземне Ходай җитәкләп йөртү белән генә аңлата алам. Элек эчке сиземләвем булыша дип белә идем. Ә аннан җаным белән Ходайга якынлашкач, барысы да үзгәрде. Күңелемнән гел аңа мөрәҗәгать итәм, сөйләшәм. Ул нindидер юлны яба икән – ул якка бармыйм гына. Тик моны аңларга ирешү тиз булмады, мин аңа озак килдем. Без дә, безнең әти-әниләр дә атеизмда тәрбияләнгән бит. Әбием бик дини иде, дога кылмыйча, Коръән укымыйча бер көн дә уздырмады... Бу юлга басуыма конгресска килүем дә ярдәм итте. Башта догалар өйрәндем. Иртән торып дога укымыйм икән, көнем уңышлы булмый – шуны аңладым. Иң кызыгы: мин – «ябалак», элек иртә тора алмый идем. Ә догалар укый башлагач, бишенче яртыда инде уянам. Бу вакытта ялгызым гына дога укый, теләкләр тели алам. Әйтерсең лә Ходай үзе белән аралашу мөмкинлеге булсын өчен тормышымны шулай көйләде... Аллаһы Тәгаләгә ышану хәзер миңа бик нык ярдәм итә. Тормышта төрле мизгелләр, катлаулы чорлар булды: авыртулар, якыннарны югалту, «Классика» белән аерылу... Хәзер аңлыйм, Ходай боларның барысын миңа шулай әйбәтрәк булачагын белгәнгә биргән.

ТИРӘ-ЮНЬДӘГЕЛӘРГӘ АЛАР ҺӘРВАКЫТ РӘХМӘТЛЕ

– Юлыма очраган кешеләрнең берсе дә очраклы булмаган. Моны хәзер яхшы беләм. Һәрберсен Ходай җибәргән... Янындагылар: «Бу нәрсәгә инде сиңа?» – дип торса, нинди эшкә тотынсаң да, канатлар киселер иде... Таяныр кешеләремнең берсе һәрвакыт ирем булды – аңа рәхмәтлемен. Аннан – балаларыма. Өчәү алар минем. Иртәдән кичкә кадәр яннарында кайнашкан әни була алмадым. Аның каравы, мөстәкыйль булып үстеләр. Алу түгел, бирү мөһимрәк икәнен, күбрәк өләшкән саен, күбрәк килгәнен аңлый алар. Ирем дә шулай уйлый. Ул депутат булганчы да кешеләргә күп булышты. Үзе православие динендә булса да, мәчетләргә дә, татар-башкорт җәмгыятьләренә дә ярдәм итте. Балалар моны күреп тора. Көн дәвамында кемгәдер булышмаса, улым көнен бушка узган дип саный... Олысы кияүдә инде, үзе дә әни, ике оныгым бар. Ул минем кебек түгел, балаларын башкача тәрбияли: аларга сайлау мөмкинлеге бирә, фикерләрен сорый. Оныклар – башка халәт. Яннарында көн саен булырга тырышам. Үзе әни булгач, кызым белән дә күпкә якынайдык.





ЯҢАЛЫК ЯРАТАЛАР, ҮЗЛӘРЕ ДӘ ҮЗГӘРЕРГӘ ҺӘРВАКЫТ ӘЗЕР

– Чиләбе татар конгрессында ел саен яңа проект! «Нәни энҗеләр», «Нәни тамчылар» бәйгеләре... Ә театр турында миңа моңарчы бик күп сөйләделәр. Сугышка кадәр Чиләбедә татар театры булган, тик соңыннан инде труппа кабат җыелмаган. 70 нче елларда да «ЧТЗ»да халык театры эшләгән. Ул актерлар белән очрашырга да туры килде. Кыскасы, театр турындагы идея күптән яшәде. Нигә тотынып карамаска? Башта яшьләрне җыйдык. Аннан режиссер эзли башладык. Ренат Әюпов белән телефон аша гына таныш идек: Троицкида үткән бер чарага Кариев театрын чакырган булды. Ул үзе килә алмады, әмма элемтәләр калды. «Шалтыратып карыйк әле», – дим. Ә Ренат шунда ук «риза», диде! «Башмагым»га тукталдык... «ЧТЗ театры» ул көнне шыгрым тулы иде. Спектакль тәмамлангач, аягүрә 15 минут алкышладылар. Халык театрны көткән! Әмма иң сөенечлесе тагын шул: Казанда, «Иделйорт» төбәкара театр коллективлары фестиваль-конкурсында без быел Гран-при алдык! Зур җиңү булды бу! Ренат Әюпов инде яңа пьесалар җибәрде, тиздән репетицияләр башлыйбыз. Артистларыбыз күңелендә кабынган рух сүнмәсен иде... Чиләбе мәдәният институтының режиссерлар әзерли торган бүлегендә үз кешебезне укытасыбыз килә. Ринат Закиров күптән түгел исә миңа: «Ә син театр Чиләбедә генә булырга тиеш дип саныйсыңмы? Сездә бит шәһәрләр күп», – диде. Аның нәрсә әйтергә теләгәнен яхшы аңладым...

«ЮК», «БУЛМЫЙ» СҮЗЛӘРЕН БЕРКАЙЧАН КУЛЛАНМЫЙЛАР

– Конгресска килүгә үк Муса Җәлилгә һәйкәл кую турында уйлый башладым. «Бәлки сездә әзер проект бардыр?» – дип, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Зилә Вәлиевага да кердем. Ул чактагы мәдәният министры Айрат Сибагатуллин белән конкурс та башлап карадык, килеп чыкмады. Ә аннары Татарстан Дәүләт музее директоры Гөлчәчәк Нәҗипова белән таныштым. Сүз иярә сүз чыкты... «Бездә әзер һәйкәл бар! – диде ул. – Инде ничә ел «запасник»та саклыйбыз. Элек опера театры эчендә торган. Беркемгә дә кирәкми, ал». Аннан өстәде: «Ә кем эше икәнен беләсеңме? Урманченыкы!» Ышанмадым! Икәү ишегалдына чыктык. Тора! Ачык һавада, урамда, такталар белән томаланган... Мәдәният министрлыгына йөгердем. Урынбасарларның берсенә кирәкле кәгазьләргә кул куйдырдым. Документлар әзер! Бер кәгаземне онытып калдырган идем, кире алырга барсам, министрлыкта бу хакта инде хәбәр таралган. Икенче бер урынбасар: «Ул һәйкәл безнең үзебезгә кирәк!» – ди... Шунда ук Чиләбегә шалтыраттым: «Транспорт, кран җибәрегез», – дим. Алар иртүк килеп тә җитте, төяп алып та киттек. Җәен алып кайттык, октябрьдә инде куйдык. Ачылышына Муса Җәлилнең кызы Чулпанны чакырырга Зилә Вәлиева тәкъдим итте. Һәм Чулпан ханым, чыннан да, килде! Хәзергәчә аралашып, сөйләшеп торабыз... Шагыйрьнең туган һәм һәлак булган көннәрендә һәйкәл янында гел кеше бездә.

Ә хыяллар икәү иде минем! Җәлил һәм Тукай! Җәлил белән җиңелрәк булды – ул Советлар Союзы Герое. Конкурс аша да аны инде бездә беләләр иде. Ә Тукай Чиләбе өчен ятрак әле. Аңлатырга, инандырырга озак вакыт кирәк булды. Газетаны да эшкә җиктек, тапшыруны да... Бер һәйкәлне дә кабатлыйсы килмәде. Златоуст шәһәрендә Александр Лахтачев дигән скульптор бар: Тукай шигырьләрен алып, аның



■ Ике ел элек «Татар кызын» Европада үткәрдек. Сигез ил катнашты! Алдагы бәйгене Үзбәкстан кабул итәчәк. Узган ел исә ике кыз килеп: «Әйдәгез, Америкада да үткәрик», – дип мөрәҗәгать итте. Кем белә?!

PRESSA

янына киттек... Һәйкәл инде әзер, ачар өчен табигатьнең матур чагын – майны көтәбез. Шәһәр үзәгеннән – Революция мәйданыннан нибары бер тукталыш барырга кирәк булачак. Һәйкәл өчен кирәкле акчаның зур өлешен, әлбәттә, Татарстан бирде. Икенче зур өлешен халык җыйды. Һәр чарада «Тукай һәйкәленә» дигән тартма торды бездә. Ай саен, пенсиясеннән өзеп, 200 әр сум акча җибәреп торучы пенсионерларыбыз булды. Сөйләгәндә дә күзләрем яшьләнә...

АЛАР УҢЫШЛЫ КИЯҮГӘ ЧЫГА

– Мин Дәүләт Думасы депутатына түгел, студент егеткә гашыйк булдым. Без танышканда I курска кергән генә идем әле, ә ул II курс студенты иде. Арабызда мәхәббәт кабынды: саф, чиста хисләр... Чиләбе дәүләт политехника институтының энергетика факультетын тәмамладык. Илдә үзгәртеп кору башланды. Диплом алганда эшкә барырга тиешле предприятиеләребезгә кирәкми идек инде. Белемебезне кайда кулланып була дип эзләргә тотындык. Олег эшмәкәр булып китте.

Уңыш болай гына килми бит ул. Өйләнешкәч, сигез ел буе бер тапкыр да ял итмәдек. Иремне ул елларда күрмәдем диярлек. Гел эштә, гел командировкада: ил буйлап йөреп, элемтәләр урнаштырды. Бизнеста да, иҗтимагый эшләрдә дә бер-беребезгә терәк булдык. Мин конгресска килгәнче үк Олег безнең мәдәнияткә, гореф-гадәтләргә хөрмәт белән карады. Әтинең туган авылы Кунашакка кайтканны хәтерлим. Тирә-күршеләр җыелды. Ирем, түбәтәй киеп, барысы белән бергә табын артына утырды, догага кулын күтәрде. Һәркайсы белән танышып, исәнләшеп чыкты. Бер әби шунда: «Олег, пятерка сиңа! Пятерка!» – дигән иде... Әйе, ул башка гореф-гадәтләрдә, башка аш-суларда тәрбияләнгән. Әмма безнең гаиләдә дуңгыз ите ашау юк. Соңгы вакытта ул итне, гомумән, ашамый, ә ашаганда, тәмлерәк дип, хәләлне сайлый иде... «Татар кызына өйләнмә», – димәде аңа әти-әнисе. Ә минем әти әйтте, ул, гомумән, никахыбызга каршы иде. Хәзер мин аны аңлыйм... Ирем чиркәүгә бара, мин – мәчеткә: бу безне аера. Диндә дә бергә булуыбызны бик телим дә... Тик мин беркайчан да православие динен кабул итмәячәкмен, ә ул – исламны... «Аннары кайда булырбыз?» дигән уйлар гел ешрак керә...

АЛАР ҺӘР СИТУАЦИЯДӘ ХАТЫН-КЫЗ БУЛЫП КАЛА БЕЛӘ

– Үзем турында болай әйтү авыррак, билгеле... Әмма тирә-юнемдәгеләрдән: «Бернинди вазыйфаларга карамыйча, гел хатын-кыз булып каласыз», – дигәнне еш ишетәм. Күпләр нигәдер хатын-кыз депутат кырыс булырга тиеш дип саный. Мин, күрәсең, башка камырдан... Закон чыгару җыелышларында утыруга караганда, кешеләр белән эшләү күбрәк ошый. Постулатлар аша түгел, матурлык, ярату, күңел җылысы аша аларның фикерләрен үзгәртергә телим. Ярдәм итәргә! 2012 елда депутат булып Магнитогорск шәһәреннән сайландым. Балалар, Картлар йортлары, инвалидлар оешмасы, бала тудыру йортлары – кулымнан нәрсә килә, мин иң элек аларга булышам. Милләттәшләр яныма учакка тартылган кебек җыела... «Нәни энҗеләр» бәйгесендә катнашучы сабыйлар бигрәк тә. Кайда очратсалар да, танышлар, йөгереп килеп кочып алалар. Зур хыялым бар – Чиләбедә татар мәктәбе ачасы иде. Балаң анда уку – дәрәҗә булырлык мәктәп! Минтимер Шәрипович соңгы очрашуыбызда миңа үз проекты – билингваль мәктәп турында сөйләде. Бик тәфсилләп! Күңелем сизә – юкка түгел!



Фотолар: шәхси архивтан

ФОТОПРОЕКТ: «ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Әнисә ҺАДИЕВА. Фото: Рөстәм ҺАДИЕВ. Балтач районы.

Бер мизгел.
Фоторәсемгә әйләнгән бер мизгел.
Ана белән Баланы кабат-кабат үткәнгә: шушы көнне, шушы сәгатьтә кичергән Бәхеткә, ул чактагы хис-тойгыларга алып кайтачак әле ул. Әни – җир йөзендәге иң кадерле кеше дип искәртеп торачак. Шатлыкларыңа аның кебек сөенүче башка берәү дә булмаячак, борчу-хәсрәтеңне ул гына үзенекеннән зуррак итеп кабул итәчәк. Аңлаячак, кичерәчәк, канат куячак... Яратачак! Бернигә карамый! Гомер буе...
«Объективта – әни» конкурсы тәмамланды, әмма проектыбыз дәвам итә.
Фотосурәтләрегезне көтәбез: гомер альбомындагы ул мизгелне безнең белән дә бүлешегез!
Иң уңышлы эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк.



Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

УКУЧЫЛАРНЫҢ ЯРАТКАН АПАСЫ































Фото: Анна Арахамия

Мәдинә Гарипова: «Тормышта актив булырга кирәк. Кемгәдер булыша алу – куаныч ул. Бик күпләр ярдәм итәргә теләсәләр дә булдыра алмый – сәламәтлекләре, мөмкинлекләре юк. Андый мөмкинлегең булу үзе бәхет бит».

Мәдинә ханым редакциябезгә үзе килеп керде. «Сөембикә»не 90 яшьлек Әлфия апам бик яратып укый, ул җибәрде мине сезгә», – диде ул, һәм сумкасыннан 1962 елгы «Азат хатын» журналын чыгарды. Сентябрь тышлыгыннан яшь-яшь кыз – Казандагы 53 нче мәктәпнең башлангыч сыйныф укытучысы Мәдинә Закирова елмая...

Мәдинә Ганиевна Гарипова (бүгенге фамилиясе хәзер шундый) – 46 еллык педагогик стажлы хезмәт ветераны, «Һөнәргә тугрылык өчен» медале иясе. Балачактан ук педагог булырга хыялланган ул. Казанның 5 нче мәктәбен тәмамлагач, укуын Арча педагогика көллиятендә дәвам итә. Үзе белем алган мәктәптә 20 елдан артык укыту бәхете дә насыйп булган аңа. Хәтта үзе укыган чактагы директор Анатолий Авксентьев кул астында эшләгән.

Узган елның декабрендә 80 яшьлек юбилеен үткәргән Мәдинә апалар буыны сугыш елларын, зур төзелешләр, югары идеяләр чорларын кичкән. «Иң истә калганы – сиреналар тавышы, – дип сөйли ул. – Дошман самолетлары Зөягә якынлаша башласа, хәвеф сиреналары кычкырта башлый. Тәрәзәләрне томалап яшәүләр, ипи карточкалары – барысы да истә».

Казанның ул чактагы «Дегтярная» урамы аның балачагы, яшьлеге эзләрен саклаган урын. Бүген бу тирәләрдә «Казанның меңьеллыгы паркы» урнашкан. Мәдинә апа күңелендәге хатирәләрне яңарта: «Хәзерге Казан белән ул еллардагысы икесе ике шәһәр кебек. Әле дә альбомымда бер фото саклана – мин анда телогрейкадан, иңемдә көянтә-чиләкләр. Без үскән ике катлы агач йорт, яшел чирәмле ишегалды, су коенган, кер чайкаган Кабан буйлары гел күз алдымда. Җәй челләсендә бөтен күршеләр белән ишегалдында төн кунабыз... Ишекләрнең дә биге булмады...»

Кабат 1962 елга әйләнеп кайтыйк әле. Мәдинә апа «Азат хатын» тышлыгында чыгу тарихын сөйли. «Уку елы ахырында мәктәпкә РОНО инспекторы килгән иде. Минем дә дәресемә кереп утырды. Күпмедер вакыттан соң мәктәп директоры өйгә үзе килгән: сине фотога төшерергә чакырталар, ди. Бакчага барырга әзерләнеп йөргән чагым иде. Җәйге сарафаннан, кулыма кәрзин тотып, килешенгән урынга – Черек күл паркына киттем. 1962 елның сентябрь тышлыгындагы рәсем – әнә шул көнне төшкән фото. Гомерем буе түр стенамда эленеп торды ул. Ул чакта күпме хат алганымны белсәгез! Көн дә эшкә килүемә ике-өч хат көтә иде. Күбрәк егетләр яза – танышырга телиләр, араларында солдатлар да бар, хәтта җәза үтәтү урынынннан да яздылар...»

Мәдинә Ганиевна гомере буе һөнәренә тугры кала. Лаеклы ялга чыккач та, тагын 12 ел эшен дәвам итә. «Әле дә актив булырга тырышам. Вахитов районының Ветераннар советына йөрим, дус кызларымның хәлләрен белешеп торам. Ахирәтләремнең йомышларын үтәп, кирәк-яракларын алып кайта алуыма да куанам. «Инстаграм»ны үзләштерәм, видеога, фотога төшерергә өйрәнәм», – дип елмая ул. Кайчак, сагышланып, вакытсыз югалткан бердәнбер кызы Луизасын сагынып ямансуласа да, оныгы Эмильнең уңышларына куанып, яңалыкка омтылып, аралашудан тәм табып яши Мәдинә ханым.

Лилия ГӘРӘЕВА

PRESSA



БЕЗНЕКЕ... ҮЗЕБЕЗНЕКЕ!

Хатын-кыз авыруларын дәвалау үзенә бер нәзакәтлелек таләп итә. Ул турыда иң якын кешеңә сөйләве дә кыен, уңайсыз. Ә менә аңа сөйлиләр, аңа ышаналар, серләрен бары аның белән уртаклашалар.

Аның белән сөйләшүе үзе бер рәхәт. Эчкерсез, самими, ә күзләрендә очкын... Ул балкып кабына да, үзе артыннан ияртеп, әллә кайларга алып китәр сыман. Хәер, без шул халәттә калдык та бугай инде.

Ул сөйли. Еракта, бик еракта калган көннәргә әйләнеп кайта да күз ачып йомганчы җанын җилкендереп торган кайнар вакыйгалар эчендә кала. Онытылырлыкмы соң алар?! Ана һәм дөньяга аваз салачак бала гомере бизмәнгә куелганда, минутлар түгел, секундлар кадерле! Бер мизгелдә аның күз алдына бала табарга җыенган яшь ана килеп баса. Әнә ул ачыргаланып кычкыра. Шул мәлдә аның бөтен өмете – янында кайнашкан ак халатлы табибларда. Ә алар, нишләптер, югалып калды. Гадәти булмаган хәл. Ана көчәнә генә башлый, ә туарга өлгермәгән баланың йөрәге тибүдән туктый. «Ярып алыйк. Югыйсә бала үлә», – дип инәлә ул бала табучы хатын янында бөтерелгән табибка. «Юк, әнисен саклыйбыз. Ә бала табар әле ул». Ярып алганнан соң гына әлеге хәлдә башкача юлның булмавы ачыклана. Кендек сабыйның муенына дүрт тапкыр

Пациентларның яраткан табибы булу зур бәхеттер ул. Андыйлар турында «Ходайдан» дип, тикмәгә генә әйтмиләр бит.

чорналган була. Буылып үлүгә тиң хәтәр очрак. «Ул егет хәзер институтның 3 нче курсында укый», – дип елмая табибә.

Яшәү белән үлем арасының кул сузымында гына булуына ничәмә-ничә мәртәбәләр инанды икән ул. Утыз елдан артык эшләү дәверендә пациентларының яраткан табибына әверелгән КФУның медицина-санитария бүлеге хатын-кызлар консультациясенең акушер-гинекологы Гүзәл Зәкәрия кызы ГАЛӘВЕТДИНОВА белән әңгәмәбез үзе һәм һәркайсыбызны борчыган хатын-кыз чирләре хакында.

«Кем буласымны 6 яшьтән белдем»

– Мин Менделеевск шәһәрендә сигез балалы гаиләдә дөньяга килгәнмен. Әти белән әни мин белә-белгәннән бирле химия заводында эшләделәр. Олы апам Фирая медицина училищесын тәмамлады. Абыем Фираят – медицина институтын. Тора-бара ул оста хирург булып танылды. Аның турында һәрвакыт хөрмәтләп, олылап сөйлиләр иде. Әнием Рәхилә ике сүзнең берендә: «Әнә, абыеңа кара!» – диде. Һәм мин карадым да... 5-6 яшьләр тирәсе булгандыр, Фәрит абыем миңа чүпрәк курчак алып кайтып бирде. Ул вакытта курчаклар шундый иде бит. Шул курчакка бертуктаусыз укол ясаганымны хәтерлим. Юешләнгәч, аны мич башына киптерергә менгереп куям. Башка уенны белмим дә. Шуңа гел (ул чагында миңа 6 яшьләр булгандыр) табиб булам, дидем. Унынчы сыйныфны тәмамлагач, документларны ике дә уйламыйча, медицина институтына биреп кайттым. Тик менә конкурстан гына үтә алмадым. Иң «престижный» югары уку йортларының берсе иде бит ул. Хәзер дә шулай анысы. Үземә шундый ышанган идем. Керә алмавыма бик борчылдым. Елап ятып булмый бит инде. Кайттым да үзәк район хастаханәсенең регистратурасына эшкә урнаштым. Башта һаман бер уй: «Инде нишләргә?» Шул вакыт таныш бер хирург медицина училищесына керергә тәкъдим итте: «Урта медицина персоналы булудан да шәбе юк», – диде. Ни өчен шулай дигәндер, белмим. Мин аның киңәшен тотарга булдым.

Таяныр кешеләр булганда...

...Гүзәл Алабуга медицина училищесына укырга керә. Бер үк вакытта бала табу йортында да эшли. Укол ясарга да, бала таптырырга да өйрәнә. Тәҗрибә туплый. Ике ел сизелми дә үтеп китә. Училищены кызыл дипломга тәмамлагач, Чаллыда ашыгыч ярдәм күрсәтү хезмәтендә эшли башлый.

– Янәшәмдә һәрчак минем өчен җан атып торган шәфкатьле кешеләр булды. Биредә озак эшләмәдем. Бервакыт гинекология бүлеге җитәкчесе әйтә миңа: «Син укуыңны дәвам итәргә тиеш. Институтка бар. Бармасаң, тукмап ташлыйм», – ди. Үзе көлә. Билет алып кайтып кулыма тоттырмаган булса, кем белә, бәлкем, кыймаган да булыр идем. Тәвәккәлләп киттем Казанга. Бу – 1980 нче еллар. Мәскәүдә Олимпия уеннары бара. Казан гөр килә. Таныш-белеш миңа: «Дохлый номер. Блатың булмаса йөрмә дә!» – дип тора. Юк әле, мин әйтәм, барам. Бер биология фәнен генә бирә алырмын. Имтиханда: «Перепончатые крылья» дигән сорау эләкте. Ышанасызмы, нәкъ шул минутта кулыма шөпшә килеп кунды. Каян очып кергәндер ул?! Үзем дә соңыннан хәйран калдым. Нәкъ әкияттәгечә бит. Кулымда тыныч кына утырган шөпшәгә карый-карый соравымны әзерләдем. Иң гаҗәбе – чакмады да бит. Бераздан очып китте тагы үзе. Ә мин имтиханны «бишле»гә тапшырдым. «Бишле» дигәч, ышанмый тордым. «Миңамы?» – дим. «Ничек шундый чибәр кызга «бишле» куймыйсың инде?» – диләр. Әни: «Ходай сиңа тел ачкычлары бирсен», – дип теләп калган иде. Рас килде. Шөпшә турындагы сорауга шөпшә үзе әйтеп торды. Дөньяда шундый хәлләр дә булгалый. Соңыннан укырга кереп, лекцияләргә йөри башлагач, дуслашып киткән кыз: «Синең баскычтан очардай булып төшкәнеңне мин дә күрдем», – диде. Бер егет әйтте шунда: «Керүен керерсез, укуын ничек укырсыз менә...»

...Әйбәт укый кыз. Укыган чорда Волгоградта һәм Курскида үткәрелгән олимпиадаларда катнаша, призлы урыннар яулый. Ә институтны тәмамлагач, остазы профессор Лев Козлов аны – үзенең иң сәләтле укучысын – ординатурада калдыра. Әңгәмәдәшем соңлап кына – 29 яшендә бик әйбәт кешегә кияүгә чыгуы, бер-бер артлы кыз һәм малай табуы, кызы Зөлфиянең бүген 3 нче бала тудыру йортында үзе шикелле акушер-гинеколог булуы, улы Илдарның нәшриятта эшләве турында сөйләп ала. «Балалар икесе бер елны гаиләле булдылар: берсе өйләнде, икенчесе кияүгә чыкты, – ди Гүзәл Зәкәриевна. – Аннары... бер-бер артлы малайлары туды».

«Ирем – Казанда, мин – Менделеевскида»

– Ничек алай? Берегез – анда, берегез – монда... Гаиләне ничек саклап кала алдыгыз?

– Бу хакта сүзнең булуы да мөмкин түгел. Бер-берсен яраткан, бер-берсенә ышанган кеше андый вакытлыча булган гына югалтуларга бирешми. Мин бит тиктомалдан кайтып китмәдем. Әнием кинәт авырый башлады. Үзем карыйм, дидем. Балалар минем янда. Ә Фәрит атна саен диярлек кайтып йөрде. Без аерым яшәгән биш ел эчендә йорт салып куярга да өлгерде. Яхшы фотограф та әле ул. Аның фоторәсемнәре белән бөтен өй тулган. Карап торсаң, гаилә тарихын чагылдыручы бер музей диярсең.

Район хастаханәсендә эшләгән ул елларны сагынам мин. Берсендә суган утыртырга өч мәртәбә чыктым. Түтәлгә барып кына җитәм, өй янына «ашыгыч ярдәм»

Фотолар: Анна Арахамия һәм гаилә архивыннан

Статистик мәгълүматларга караганда, бала табу яшендәге хатын-кызның 60 проценты (?!) гинекологик авырулардан җәфалана.



машинасы килеп туктый. Тагын мин кемгәдер кирәк! Хатын-кыз өчен кирәкле һөнәр сайлавымны шул чагында аңладым. Алар синнән күзеңә карап ярдәм көтә.

...Гүзәлия Зәкәриевна өчен һәр пациент – үзе бер дөнья. Ул һәркайсы белән алар телендә сөйләшә. Ә иң мөһиме: вакытында тиешле ярдәм күрсәтә. Эштә аз гына югалып тордымы, пациентлары чаң суга башлый. «Кайда югалды безнең табиб? Ул бит безнеке, үзебезнеке...» – диләр. «Әтинең әнисе Хәбибә әби кендек әбисе булган. Безгә ул нәселдән килә», – дип, тикмәгә генә горурланмый безнең табибә.

Сердәшче дә, дәвалаучы да

– Хәзер яшьләр башка. Җенси мөнәсәбәтләргә дә иркен, җиңелчәрәк карыйлар. Сезгә дә шуның аяныч нәтиҗәсе белән еш очрашырга туры килгәләгәндер?

– Килешәм, башка. Эшләү дәверемдә миңа да төрлесен күрергә туры килде. Аборт ясатырга килгән 13 яшьлек баланы да, йогышлы чир корбаны булган кызларны да... Төрлесен. Бүген яшьләр җенси тормыш белән бик иртәләде. Юк, мин моны начар дип әйтмим. Ләкин алар түшәккә кем белән ятканын ачык белергә тиеш. Теләсә кем белән ярамый! Аннан килеп, күбесе сакланмый да бит аларның. Ә эш узгач: «Миңа бала кирәкми», – дип аборт ясатырга килә. Мәсьәләнең икенче ягы да бар: хатын-кызның кайберсе, бик теләсә дә, балага уза алмый. Сәбәбе төрле. Әйтик, кайсының аналык көпшәсе шартлый, кайсы аналыктан тыш йөклелек булганда зыян күрә. Бөтен яктан да сау-сәламәт кызлар сирәк хәзер. Кемдә – бөер, кемдә бавыр проблемасы, күбесе хроник тонзиллиттан җәфалана. Шундый хәлдә балага узып, тугыз ай күтәреп йөреп кара әле син?! Инде килеп, аналык җиңсәсенең ялкынсынуы, кольпит, эндометриоз ише ятышсыз чирләргә әледән-әле очрап торган аналык муентыгындагы яман чирне дә өстәсәк, алдыбызга хатын-кыз авыруларының ни җитди генә булмавын дәлилләүче тулы бер картина килеп баса.

Әле папиллома вирусы турында әйтергә онытып торам. Бу чир, нигездә, җенси юл белән йога. Аналык муентыгындагы яман чир исә беренче һәм икенче стадиядә үзен берничек тә күрсәтми. Аналыктан бүленде, авыр ис килгәндә, ягъни өченче стадиядә инде соң була.

Әйе, мөрәҗәгать итүчеләрнең кайберсе белән сәгатьләр буе сөйләшергә, аңлатырга туры килә. Алар шул хатын-кыз табибына гына ачыктан-ачык барын да сөйләп бирә ала бит. Һич хәтердән чыкмый торган бер очракны гына искә алып китәм. Бер кыз белән сөйләшәбез. 25 яшьләр тирәсе булыр. Карап туйгысыз чибәр үзе. Авырга узгач, ВИЧка анализ тапшырган. Тискәре дип килгән. Биш ай узгач, тагын тапшырган. Анысында инде уңай нәтиҗә белән... Кыз еламый гына. Каршыма килеп утырды да, тәүбә итәргә килгән кеше шикелле, түкми-чәчми барын да сөйләп бирде. Сөйгән егете кемнәндер йогышлы авыру йоктырган, ул кызга күчкән. Кыз аны үлеп ярата, ди. Шул ирдән бер-бер артлы ике кыз бала тапты. Шөкер, сәламәт балалары. Әти белән әни гомер буе даруда булачак. Бик мәкерле чир бит ул.

Авырга узып, баласын төшертергә килгән 36 яшьлек бизнесвумен да, «аборт ясатма», дип үгетли торгач, кыз бала тапты. Хәзер миңа чиксез рәхмәтле.

...Аның ханымнар, буй җиткән кызлар колагына гына әйтәсе сүзләре, теләкләре бар: хатын-кыз, елына бер генә мәртәбә булса да гинекологка күренсә икән, авырга узган хатын баласын срогын тутырып тапса икән, хатыннар бала табудан курыкмаса икән, авырга беренче тапкыр узучылар аборт ясатмаса икән, өйләнешүчеләр, туйга кадәр ВИЧка тикшерү узсалар икән, баланы ярып алуларга бераз тынычрак карасалар икән... Ник дигәндә, бер ярып алсалар, икенчесен дә ярып алалар, дигән сүз бүген чынбарлыкка туры килми. Чөнки хәзер Казан шәһәренең күп кенә бала тудыру йортларында (шул исәптән, 4 нче һәм 1 нче бала тудыру йортларында да) икенче баланы әнинең үзеннән таптыру өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган.

Авырга узган хатын бала тапканчы өч мәртәбә скрининг уза. Шул рәвешле, карында яткан баланың Даун синдромы, церебраль паралич чиренә хромосомалар тикшерелә.

Әңгәмә ахырына якынлаша. Табиб безне озата чыга. Кабинеты янына куелган эскәмиядә дистәләгән әниләр һәм булачак әниләр аны көтә. «Берсен дә кире борып җибәрмим. Эш сәгате тәмам димим. Эшемне яратам», – ди ул кояштай балкып. Ничек үзебезнеке димисең инде шундый кешене! Безнеке... үзебезнеке ул!

Мәдинә АВЗАЛОВА

МЕНӘ ШУНДЫЙ УЛ!..

Таныйсызмы? Безнең Мәдинә апа шушы була инде! Хәер, сезнең өчен ул – Мәдинә Авзалова. Йөрәкләрне тетрәндерерлек, каз тәннәре чыгарырлык, сискәндерерлек язмалары белән укучылар күңелен яулаган журналист ул. «Бигрәк дөрес язган!» – дип, аның каләменнән төшкәннәрне кулдан-кулга йөртеп укыйлар.

Социаль темалар, кеше хокуклары, иҗтимагый оешмалар, авыл хуҗалыгы, эшкә урнашу, мәшгульлек, милек, торак, сәламәтлек... У-у-у... ул колачлаган темаларны искә төшереп санап чыгу да җиңелләрдән түгел шул! Өстәвенә, парламент хәбәрчесе! Бала хокукларын яклаучы, аналарны кайгыртучы журналист тагын... Әйтсә – өздереп әйтә! Эшләсә – яндырып эшли! Хаклыкны даулап ярсып чыга! Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында һич тайчанмыйча командировкага да чыгып китә, ябык ишекләрне дә ачтыра, ишек бикле булса, форточкадан керә, әллә нинди проблемаларны чишә, күпләргә ярдәм итә, кемнәрнедер утлы табага бастыра, ни кырыс түрәләрне дә йомшарта белә безнең Мәдинә апа! Уңган-булган (Кукмара кызы булсын да!), җитез-тиктормас, тынгысыз (сөекле нәнәсе Гөлчәчәк ападан күчкән сыйфатлар), чая, тәвәккәл, тиз аралашучан, яшь кызлар сыман җиңел гәүдәле (хәер, яшьтән үк спортчы да бит ул, студент елларында җиңел атлетика буенча университет данын яклап йөгергән!), журналистларга хас оператив (командировкадан кайтуга ук язмасын редактор өстәленә кертеп салмаса, Мәдинә буламыни ул?!)... Салкын акыллы хирург, оста дипломат, таләпчән укытучы, гадел юрист, күз карашыннан аңлый белгән психолог сыйфатларын үзенә туплаган чып-чын журналист ул, кыскасы!

Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, «Фидакарь хезмәт өчен» медале иясе Мәдинә Авзалованың дәрәҗәле исемнәре, бүләкләре генә дә никадәр! Татарстан Президентының Мактау грамотасы һәм дипломы, «Калкан һәм каләм» конкурсында «Иң яхшы журналист-криминалист» булып танылу, Мәдәният министрлыгы, Кеше хокуклары буенча Татарстанның вәкаләтле вәкиле тапшырган дипломнар... Ике тапкыр «Бәллүр каләм» иясе булу... Ә шулай да аның өчен иң зур бүләк – укучыларының яраткан авторы булу, әлбәттә.

Без аның командировкалардан кайткан чагын яратабыз. Кайларда гына булмаган, кемнәрне генә күрмәгән, ниләр генә хәл итмәгән!.. Ә язмалары белән дөньяны үзгәртергә әзер. Һәм үзгәртә дә!.. Мәскәү янындагы Томилинода, Пушкинода урнашкан SOS Балалар авылыннан нинди уйлар белән кайтканын күрсәгез иде сез! «Әтиәнисе ташлап калдырган балалар менә шундагы кебек өй шартларында, гаилә җылысында, яратуга коенып үсәргә тиеш!» – диде ул. Шулай язып та чыкты. Озак та үтми Авзалова хыялындагы андый гаиләләр республикада да күренә башлады. Андыйларны Мәдинә апа Мөслимнең Күбәгеннән табып кайтты. Ике өйнең берсендә тәрбиягә алган сигезәр, унар бала! Журналист Авзалова ул гаиләләрне бөтен татар дөньясына танытты!

Ташландык балалар, Картлар йортына тапшырылган аналар, хатын-кызлар колониясендәге тоткыннар, гомерләренең санаулы сәгатьләрен хосписта уздыручы сабыйлар, залим ирдән җәберләнеп яшәүче хатыннар... Аның геройлары да бик үзенчәлекле ханымнар шул: мисс-майор йә автобус йөртүче, поезд проводнигы йә комбайнчы... Журналист Мәдинә Авзалова яклап, йолып калган берсеннән-берсе гыйбрәтле язмышлар искә төшә...

Яктыртасы темасын җентекләп өйрәнеп, һәр сүзен үлчәп, һәр фикерен дәлилләп яза торган талантлы журналист шул ул. Тикмәгә генә аңа заманында «Ватаным Татарстан» газетасында ирләр генә эшли алырлык икътисад һәм төзелеш бүлеген ышанып тапшырмаганнардыр инде. Төзелә генә башлаган Алабуга заводлары, КАМАЗ цехлары... Республика язмышы хәл ителә торган җаваплы чорларда парламент хәбәрчесе булулар... Депутатлар арасында төн уртасына кадәр утырып, Татарстанның мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул ителгән тарихи мизгелләрнең эчендә кай-наулар... Көнозын сессиядә утырулар, кайткач, «полоса-полоса» материал бирүләр... Менә шундый ул Мәдинә апа!

«Кешеләргә ярдәм итү – миңа Ходай тарафыннан йөкләнгән бурычтыр. Җәберләнгән, кыерсытылган кеше үтенеп килә икән, булдыра аламмы, юкмы – аңа ярдәмгә алынам. Авыр чакта кешене ташламыйм. Бу – минем принцибым. Кемгәдер булышмасам, көнем бушка, әрәмгә узган кебек...» Мәдинә Авзалованың шул сүзләре аны тулаем ача да сала инде! Шуңадыр, бәлки, Кояш дип йөртәләрдер үзен. Көнбагыш чәчәген хәтерләткән сары чәчләре, елмаюлары, җылылыгы, яктылыгы өчен. Коллегалары, исәпсез-хисапсыз дуслары, танышлары аңа, яратып, «Мәдинәкәй-гөлкәй» дип дәшә. Аны Татарстан журналистикасының легендасы дип йөртәләр. Фикерләре, эш стиле исә, журналистиканың алтын кагыйдәләре булып, без – каләмдәшләре күңеленә уелып бара... «Кызый, уйлап яз!», «Чәчәкләп-бизәкләп язарга яратмыйм – проблеманы конкрет мисаллар, фактлар белән ачам», «Язганнарымны кат-кат тикшертмичә басарга бирмим», «Йөрәгеңне кушып, кеше яратып укырлык итеп язарга кирәк», «Бүгенге эшеңне иртәгәгә калдырма!»...

...Үзе яши торган Осиново бистәсеннән редакциягә иң алда килеп утырып. Өстәлендә һәрчак автобуста укып килгән «Комсомольская правда», «Российская газета» ятар. Прическасы, гәүдәсенә килешле джинсылары, җитез хәрәкәтләре, креативлыгы һәм позитивлыгы аны гел яшь, тынгысыз күрсәтер. Көн саен шулай. Тәвәккәл, җитез, кыю, баш бирмәс чын егетләр холкына хатын-кыз йомшаклыгы, уңган хуҗабикә осталыгы, сер сыяр кайнана зирәклеге, ягымлы дәү әни юмартлыгы, сылу хатын көязлеге дә кушыла да, ул кабатланмас Мәдинә апабызга әйләнә!

Эльмира ЗАКИРОВА

ЯХШЫ ХАТЫН – ДИННЕҢ ЯРТЫСЫ

– Диндә хатын-кыз җәннәткә керсен өчен өстәмә бер шарт бар: ире аннан риза булырга тиеш. Айгөл минем ризалыгымны алды инде ул... Фәһим хәзрәтнең бу сүзләренә бик күп мәгънә салынган.

Гөлнур САФИУЛЛИНА



...Алар табиб чиратында таныша. Айгөлнең инде озын итәк кигән, башына яулык япкан – намазга баскан чагы. Алма кебек пешкән матур чагы! Яңа гына Төркиядән, укудан кайтып төшкән, хәрби комиссариат кәгазьләре артыннан йөрүче егетләрнең мөслимә кызга игътибар итүе исә һич гаҗәп булмый, билгеле. Берсе, күн куртка кигәне, Айгөл китәргә дип торгач, артыннан кузгала: «Адресыгызны бирегез инде...»

– Чит кешегә адрес бирмим, дидем дә, биек үкчәләрем белән кырт-кырт басып китеп бардым... Бер атнадан соң, институттан чыгып килгәндә, кемнеңдер: «Әссәламегаләйкем!» – дип дәшүенә борылып карадым. Шушы егет! «Мин инде сезне институт янында өч көн буе каравыллыйм», – ди. Аның исемен бик озак хәтерләп кала алмадым әле...

Фәһим аның янына гел дусты белән бергә килеп йөри. Айгөл белән дә күбрәк Мәхмүт сөйләшә. (Мәхмүт Шәрәфетдиновның киләчәктә Казанның Борисково бистәсендә урнашкан «Шамил» мәчете имам-хатыйбы булачагын әле берәү дә белми. – *Г. С.*) Килеп йөри дип... Алар нибары биш тапкыр очрашалар, аннан инде Фәһим Сабага кызның кулын сорарга кайта. Айгөлнең әнисе Гөлсинә ханым булачак киявенә бер генә таләп куя: «Укытып бетерәм дип вәгъдә итсәң генә кызымны бирергә ризалашам». Барысына да күнә егет... Туй гына булмый кала: ике көн алдан, көтмәгәндә, Фәһимнең әтисе вафат була. Яшьләр, автобуска утырып барып, район үзәгендә никахларын икәү генә рәсмиләштереп кайталар.

Аллаһы Тәгаләнең нуры иң элек мәчет-мәдрәсәләргә, дин гыйлеме таратучы мәктәпләргә иңә, шуннан бөтен Җир өстенә тарала.

Ул көнне Буа районы Карлы авылында яшәүче Әхмәтҗановлар гаиләсенә ЗАГСтан ике белешмә кайта: берсе – 50 яшьлек әтиләренең үлеме, икенчесе – яңа гаилә төзелү турында. Тормыш шулай башлана...

Ул чакта Фәһим, Буа мәдрәсәсендә укытып йөрүен калдырып, Казанга күчеп килә. Айгөле диплом яклаганчы, ике ел эчендә кем генә булып эшләргә туры килми аңа: йортлар да төзи, ремонт та ясый, машина да йөртә, хәтта ит тә чаба! Ә аннан Татарстан Диния нәзарәте аңа Чүпрәле районында дин дәресләре укытырга тәкъдим итә – Президент Аппаратының ул чактагы җитәкчесе Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин якташларына дини белем бирерлек кеше эзли икән. Фәһим шунда ук ризалаша: авылда эшләү аның максаты була.

– Иске Кәкерле авылына иртәгә Рамазан ае башлана дигән көнне барып төштек. Көз, караңгы, пычрак... Безгә дигән йортның сату-алу эшләре төгәлләнмәгән икән. Фатирга керттеләр... Суык өй, кулда җиде айлык кечкенә Мәрьям. «Иртәгә кире кайтып китәрсез, балага салкын тияр», – ди ирем. Шөкер, икенче көнгә йорт җылынды...

Иске Кәкерле – Чүпрәле районындагы үзенчәлекле авылларның берсе. Кайчандыр анда биш (!) мәчет эшләп торган: бер иман йортында әйткән азан тавышы икенчесенә кушылып яңгыраган... Өченчесенә, дүртенчесенә... Юкка гына «Кече Истанбул» дип йөртмәгәннәр аны!

Гыйлемгә сусаган авыл аларны колач җәеп каршылый. Тансык кунак була бу гаилә Кәкерледә. «Ашарларына юктыр», – дип, көз буе авыл халкы аларга ризык ташый: итен, сөтен, бәрәңгесен... Ачык йөз белән каршы алалар, әмма мишәрләрчә сынап карыйлар: «Булдырырлармы?»

Сынатмыйлар! Иске Кәкерле, Мочәли, Каракитә, Чокалы... Фәһим хәзрәтнең шәкертләре бөтен Чүпрәле районы була ул чакта. Балалар, өлкәннәр, хатын-кызлар, ир-атлар...

– Иске Кәкерле – икенче туган авылым кебек, – дип искә төшерә ул. – Ислам дине теориясен бөтен нечкәлекләре белән башта Казанда, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә өйрәндем, аннан – Төркиядә. Шушы тупланган барлык гыйлемемне тормышта кулланырга исә Чүпрәледә өйрәндем... Бик дини як бу. Кәкерледә ике мәчет эшләп тора иде, без анда яшәгәндә өченчесен салдылар. Гаҗәеп тырыш халык! Иртәнге сәгать сигезгә инде Коръән ашы мәҗлесенә чакыралар. Төн йокламыйлардыр дип уйлый идек... Андагы бабайларга мин бик рәхмәтле: гореф-гадәтләрне җиренә җиткереп саклаганнар.

Әгъзам Гобәйдуллин: «Дүрт елга дип кенә чакырам. Чүпрәле синең өчен соңгы тукталыш булмас әле, олырак урыннарда хезмәт итәчәксең дип беләм», – дип кайтарткан була Фәһимне. Тик дүрт елдан соң Иске Кәкерле авылының 90 яшьлек мулласы Фатыйх хәзрәт: «Мин бу егеткә ышанам, хәзер имамыбыз ул булыр», – дигән сүзне әйтә. Үзеңә булган өметне, ышанычны аяк астына ничек салып таптыйсың?! Фәһим, әлбәттә, китми, кала: «Минем әле монда эшлисе эшләрем бар», – ди.

Иске Кәкерле алар өчен олы бер тормыш мәктәбенә әйләнә. Халык арасындагы ихтирам, хөрмәт шушында яулана: килгәннәренә җиде ел булганнан соң, аны Чүпрәле районы мөхтәсибе итеп куялар. Яшь гаилә өчен дә сынау еллары була бу. Айгөл бит әнисенең уенын-чынын кушып: «Мин сине калага, зур урында эшләүче кешегә генә кияүгә бирәм», – дип үстергән кызы. Шәһәрдә яшисе кеше! Ә монда... Иң ерак районнарның берсе, бернинди шартлары булмаган иске өй, кулда ике яшь бала... Ә ул, боларның барысын «онытып», иренең иң зур таянычына әйләнә.

– Фәһим хыялын һәрвакыт кычкырып әйтә дә, «Моны ничек тормышка ашырырга икән?» – дип уйлый башлыйм. Аннан икәү утырып барысын да хәл итәбез. Мәктәп белән дә шулай булды...

«Нур» башлангыч мөселман мәктәбе... Әлмәт шәһәре һәм районы имам-мөхтәсибе Фәһим хәзрәт Әхмәтҗанов һәм аның җәмәгате Айгөл ханымның иң зур горурлыгы! Бу хакта алар Фәһим хәзрәт Әлмәткә имам-мөхтәсиб итеп билгеләнүгә хыяллана башлаганнар. Дагстанда шундый ук мәктәпне күреп кайткач, бу хыял тагын да ныгый.

– Мәктәпне дүртенче балабыз димәс идем, – ди Фәһим хәзрәт. – Бала ул үзеңнеке, синеке генә, ә мәктәп – җәмгыять өчен кирәкле эш... Үзебез кечкенәдән дини белем ала алмадык, шуңа да күпне югалттык. Бездән соң киләсе буын бездән яхшырак булырга тиеш... «Нур»ның ишекләрен ачып керү миңа бик рәхәт, әмма иң мөһиме – анда башкаларга рәхәт булырга тиеш. Бездә укучы балалар, иртән әти-әниләре китерүгә, машинадан төшәләр дә мәктәпкә йөгерәләр. Сагынып киләләр!

Татарстан Президентының нефть сәнәгате мәсьәләләрендәге киңәшчесе Шәфәгать Тәхәветдинов, Әлмәт шәһәре һәм районының ул чактагы башлыгы Айрат Хәйруллинның матди ярдәме белән төзелгән бу мәктәптә бүген 36 бала белем ала. Ул-кызларын шушында укыту өчен кайбер гаиләләр Чаллыдан, Түбән Камадан, Нурлаттан күченеп килгән. Махсус!

«Нур» мәктәбе башкалардан нәрсә белән аерылами? Малайларның – түбәтәйдән, кызларның яулыктан йөрүе белән аерыла бу мәктәп башкалардан. Тагын – мәктәп программасы буенча дәресләр тәмамлангач, барысы бергә намазга басу белән. Өстәмә дәресләрнең үзгәлеге белән – алар гарәп теле өйрәнә, аятьләр ятлый, инглизчәне кабатлый, әдәп-әхлак кагыйдәләре белән таныша. Сыйныф саен – интерактив такта, проектор... Әмма Әлмәтнең бу мәктәбе иң элек җылылыгы белән аерылып тора! Фәһим хәзрәт белән Айгөлнең хыялында ук шулай туган ул: татар милли бизәкле тәрәзә пәрдәләре, шундый ук бизәкле ишекләр, чишенү

«Нур» мәктәбе дүрт телдә сөйләшә: татарча, русча, гарәпчә һәм инглизчә.



Мәктәпнең директоры Гөлчәчәк Мизхәт кызы Габдрахманова: «Без, әлбәттә, һәр баланы исемләп беләбез, – ди һәм санап китә: – Камилә, Газинур, Сөләйман, Мөхәммәд, Салих, Вилдан, Раяна, Мәликә, Мәрьям, Сәкинә, Айшә...»

бүлмәсе... Барысына җан җылысы салынган. (Төзелеш институты дипломы Айгөлгә менә кайчан кирәк була!)

– Узып киткәч кенә җиңел кебек тоела, чынлыкта һәр адымы авыр булды, – дип искә төшерә Айгөл. – Төзелеш эшләре алып бару да. Балалар җыю да. Укытучылар туплау да. Фәһим акча эзләп чыгып китте, мин документлар артыннан чаптым. Шуңа бик кадерле дә безгә бу мәктәп... Проблемалар бар, әлбәттә. Ата-аналар белән эшләү җиңел түгел. Дини кануннар буенча гына яшәүче гаиләләрнең мәктәпкә таләпләре бик югары. Кайберләре хәтта гореф-гадәтләрне дә кабул итми...

Мәктәпнең мең мәшәкате барысы да Фәһим хәзрәт өстендә: балаларны көнгә өч тапкыр ашатуны оештыру, укытучыларга хезмәт хакы түләү, мәктәпнең киләчәге турында уйлау... Соңгысы, мөгаен, иң катлаулысыдыр. Инде бу мохиткә ияләшкән балаларны ничек чыгарып җибәрергә? Тугызынчы сыйныфны булса да шушында тәмамласыннар өчен кайдан мөмкинлек табарга? Хәзрәт юлларын эзли. Иң беренче чиратта спортзал төзергә кирәк, аның нигезенә инде акча бар, аннан чират – янкормага...

– Кыен чакларда көч алыр өчен бер генә чыганак бар... Анда-монда бәрелеп ярдәм эзләп йөрисең дә, кулларыңны күтәреп, Аллаһыдан сорыйсың: «Синнән башка беркем бирми», – дисең. Ә ул: «Бу бәндәм кайчан минем ишегемне шакыр икән?» – дип сабыр гына көтә... Эшлисе эшләр байтак. Бәлки барысының җимешен дә күрә алмабыз, чәчәк атканын да, әмма башларга кирәк... Шөкер, җитәкчеләрнең борып чыгарганы юк. Бигрәк тә «Татнефть»нең генераль директоры Наил Маһановка рәхмәтлебез...

Әйе, мәктәпнең мең мәшәкате Фәһим хәзрәт өстендә, тик аның мәшәкатьләре бер мәктәп белән генә чикләнми. Кул астында – кырыкка якын мәчет, шуның кадәр имам. Ир-ат һәм хатын-кызлар мәдрәсәсе. Әлмәт, Чирмешән, Зәй, Мөслим һәм Сарман районнары казые да ул. 2013 елда Фәһим хәзрәт Әлмәт мөхтәсибәтенә килгәч, анда Коръән-хафизлар әзерләү бүлеге ачылган. Гает бәйрәмнәре зурлап шәһәрнең үзәк паркында үткәрелә башлаган. («Бишәр мең халык җыела. «Татнефть» ул көнне балаларга аттракционга 2,5 мең бушлай билет кына тарата!») Ә ифтарлар, киресенчә, өйләргә кайткан. (Фәһим хәзрәт аны гаилә бәйрәме, ди.) Укытучылар белән очрашулар, авыл саен вәгазь кичәләре оештырыла башлаган. («Аллаһы Тәгаләдән гел бер нәрсәне сорыйм – сүзем үтемле булса икән».) Курслар, якшәмбе мәктәпләре. («Дустыңны алып кил, бүләк алырсың» акциясе белән мәчеткә әллә никадәр яңа бала килде!») Мөслимәләр, азан әйтүчеләр бәйгеләре... Әлмәт шәһәре мәгариф бүлеге каршында эшләүче «Әтиләр советы» оешмасын да Фәһим хәзрәт Әхмәтҗанов җитәкли. Өлгерә!

– «Минем эшнең яртысын Айгөл башкара», – дияргә ярата Фәһим хәзрәт. Шаярта, билгеле... Дөрес, мәчет үткәргән чараларның оештыручысы булгач, өлешем дә аз кермидер анысы... Фәһимне бит барысы да үз итә. Ихласлыгын, халык өчен тырышуын күреп торалар. Иске Кәкерледә гел: «Ярый әле безгә кайттыгыз, авылны үзгәрттегез!» – диделәр, инде бу сүзләрне хәзер Әлмәттә кабатлыйлар... Ул бик матур җырлый, гармунда уйный. Мәктәпне тәмамлагач, энисе: «Улым, әллә мәдәният-сәнгать юлын сайлыйсыңмы?» – дип әйтеп караган. Ә Фәһим ниятеннән баш тартмаган. Мулла оныгы бит! Шушы яшенә җитеп, авызына бер тапкыр хәрам капмаган, аракының тәмен дә белми – Ходай аны шулай саклаган... Өч кызыбыз өчен аннан да яхшы әти юк. Бергә спорт белән шөгыльләнәләр, тимераякта шуалар, нинди генә сорау туса да, аңа мөрәҗәгать итәләр. Никадәр тыгыз чагы булса да, сөйләшергә вакыт тапмый калмый...

Әңгәмәбезгә Фәһим хәзрәт нокта куя:

– Мөхәммәд пәйгамбәр: «Яхшы хатын – диннең яртысыдыр», – дигән. Мин моның мәгънәсен яшиящи аңладым... Без кавышканда, дини яктан Айгөл алай ук тирән белемле түгел иде. Аңа өйрәткәннәремнең барысы да уңышлы туфракка төште... Үзем хәзер шуның җимешен татыйм. Айгөл – тормышымның терәге. Аның белән горурланам, хөрмәт итәм, яратам... Без хәзер бертөрле уйлыйбыз да. Гаиләдә фикердәшләр булу исә зур бәхет ул. Аллаһы Тәгаләгә мондый бүләге өчен мең шөкер укыйм...

2020 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР
(һиҗри исәп буенча 1441–1442 еллар)

28 февраль – Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим һәм Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре. Бу айда шулай ук кече хаҗ – гомрә хаҗы кылына.

20–21 март – Мигъраҗ кичәсе. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә.

7, 8 апрель – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтүл-Бәраәт». Уңыш, изгелек иңә торган көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәлен һәм догала-рында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

24 апрель – изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн. Сабырлык вә рәхмәт ае. Ярлыкау һәм гыйбадәтне аеруча күп кылу, ураза тоту ае. Коръән иңгән ай.

19 май – Рамазан аеның соңгы 10 киченең берсе – Кадер кичәсе (күп вакыт ул 27 нче кичкә туры килә). Бу кичәдә Аллаһы Тәгалә Мөхәммәдне (с. г. в.) пәйгам-бәр итеп сайлаган кичә. Кадер кичәсендә башкарган изгелекләр мең ай эчендә кылынган яхшылыкларга караганда да хәерлерәк. Бу кичәдә гөнаһлар гафу ителә, догалар кабул була.

21 май – Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы – һиҗри, 922 нче милади ел).

24, 25, 26 май – Гайдел-фитыр көннәре. Ураза гаете.

30 июль – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар Мәккә янындагы Гарәфә тавына бара һәм тау итәгендә намаз укыла торган көн.

31 июль – Гайдел-әдхә, Корбан гаете. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган корбан чалу бәйрәме.

1, 2, 3 август – Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә фарыз намазларыннан соң, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен махсус догалар укыла.

20 август – 1442 ел – яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Хәерләр (зәкят) бирелә, изге гамәл-ләр кылына торган ай. Бу көнне Аллаһы Тәгалә игелек эшләүчеләрнең гөнаһларын ярлыкар, савапларын арттырыр.

28, 29 август – Гашура бәйрәме. Бу көннәрдә мөнәҗәт-ләр, догалар укыла.

14 октябрь – Сәфәр ае башланган көн.


28, 28 октябрь – Мәүлид бәйрәме. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) туган көн. Бу көннәрдә мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер таратыла.

Төзүчесе: хаҗи Абдулла ДУБИН.



Фото: Ксения Богданова

PRESSA





Раилә ХӘЯЛИЕВА

«МИНЕМ ӨЧЕН БАЛАЛАРЫМ ДӘРӘҖӘ»

Балачактан ук үз көнен үзе күрә, үз сукмагын үзе сала ул. Сөйләгәннәрен уйлап-уйлап йөрим дә, бер нәтиҗәгә киләм: кесәң такыр булса да, башыңдагы белемең сине кеше итәрлек, илгә танытырлык булсын икән ул. Китаплардан сеңдергән гыйлем, зирәклек Себердән яланаяк чыгып киткән егетне Санкт-Петербургның иң хөрмәтле кешесе иткән әнә! Бүгенге көндә ул – Әнвәр Ризван улы СӘЕТБАГИН – Россия һәм Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, педагогика фәннәре кандидаты. Күпкырлы фидакарь хезмәте өчен Халыклар дуслыгы һәм «Почет билгесе» орденнары, Россия Президентының Рәхмәт хаты, Россия Федерациясе хөкүмәтенең Почет грамотасы белән бүләкләнгән.

ТАМЫРЛАР Без үзебезне Себер татарлары дип атап йөртсәк тә, тамырларыбыз Казанга килеп тоташа. Бабаларым – Казан татарлары. Әтием Омск өлкәсе Тевриз районы Байба авылында туып-үскән. Әнием – янәшәдәге Тарск районыннан. Әниемнең әбисе 1974 елда вафат булды. Төгәл ничә яшьтә икәнлеген белмәсәк тә, безнең исәп буенча 107 яшьләр булырга тиеш иде аңа. Динле, намазлы әби иде ул. Әбинең абыйсы Шәйморза революциягә кадәр үк хаҗга барып кайта. Исеменнән күренгәнчә, морзалар нәселеннән булырга тиеш ул. Минем әти бик иртә үлеп китә. Тайгадан кисеп китерелгән агачларны баржаларга төяп җибәрү өчен җаваплы була ул. Иртыш елгасы буйлап саллар агызу хезмәтен бөтен гаилә белән башкаралар. Ул көнне дә алар тайгадан китерелгән агачларны үзләренең баржасы аша зур кран белән ярдан алып, икенче баржага күчерәләр. Барлык туганнарыбыз да баржада мәш килә. Кем пешекче, кем төяүче... Бандеровчылар килеп, кранның каешын кисә. Кран ава башлый. Әти, кранны терәтеп калырга теләп, иңсәләрен куя, әмма зур кран авып, әтине изеп ташлый. Бәхеткә, ярый әле баржа суга аумый, барлык туганнар да шунда юкка чыккан булыр иде... Миңа ике яшь ярым, энемә өч ай булган килеш, 23 яшьлек әнием тол кала. Шуннан соң безне алып, ул үзенең туган авылы Шыкларга (авылның икенче исеме – Рәҗәп) кайтып китә. Кабат кияүгә чыга, тагын сигез бала таба. Бераз зуррак үскәч, әтиемнең олы йөрәкле сеңлесе Гөлимҗан апаны эзләп таптым, аңа чаклы бер энесе белән очрашканым булды. Мин бүгенге көндә әти ягыннан булган туганлык җепләрен, бабаларымның язмышларын ачыкларга тырышып карадым, әмма бернинди дә мәгълүматым юк шул. Иртәрәк башлыйсы, Гөлимҗан апамнар исән чагында барысын да сорашып каласы калган аны. Хәзер шуңа үкенәм. Һәр елны өебезгә мулла чакырып, әби-бабайлар, әти-әнием, бу дөньядан киткән барлык туганнар рухына Коръән укытабыз, Аллаһ үзе кабул итеп алсын. Әниемнең әтисе Нурмөхәммәт Әйдимов – Бөек Ватан сугышы ветераны. Бабай вафатыннан соң, әбием сеңлесе янына Үзбәкстанга күчеп китә. Инде соңрак, әбиебез авырый башлагач, аны карарга дип әни дә Үзбәкстанга китеп бара. Алар икесе дә шунда вафат булдылар.



БАЛАЧАК Мин сигезенче сыйныфка кадәр үзебезнең авылдагы мәктәптә татарча укыдым.

Кемнәндер нәрсәдер өмет итү минем өлешемә тигән көмеш түгел иде. Җан асрар өчен үземә үҗәтләнергә, 14 яшьтән акча эшли башларга, тормыш җаваплылыгын үз кулыма алырга туры килде. Иртә олыгаерга туры килде шул...

Тугызынчы класстан соң, мәктәптә яхшы билгеләргә генә укыган һәм актив эшчәнлек алып барган өчен миңа Мәскәүгә һәм Ленинградка юллама биргәннәр иде. Мәктәп директорына кереп, «мин бармыйм», дидем. Киеп барырга алмаш киемем дә, өс-башымны карарга мөмкинлегем дә юклыгын аңлаттым. Җәй көне үземә киемлек акча эшләргә җыена идем. Мәктәп миңа яхшы костюм-чалбар, күлмәк, аяк киеме алды, юлда тотарга 40 сум акча бирде. «Барасың, син моңа лаек!» – дип озатып җибәрделәр. Ленинград белән мин беренче тапкыр шунда таныштым, бу шәһәргә шунда гашыйк булдым.



УКУ Тормыш миңа үзе гыйлем бирде. Сигезенчене авыл мәктәбендә татарча укып бетергәннән соң, район үзәгендәге рус мәктәбенә күчтем. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Үзбәкстанга киттем. Чирчик шәһәрендә электрохимкомбинатка урнаштым, шактый зарарлы катализатор цехында эшли башладым. Анда алты гына ай эшләсәм дә, нурланышның зарары бүгенге көндә дә сизелә...

Химкомбинатта эшләгән чорда Акташ пионер лагерена вожатый итеп җибәрделәр. Лагерьга ничек килеп керүем әле дә истә. Алтмышар баладан торган 13 отряд бар иде анда. 13 нче отрядта иң тәртипсез малайлар җыелган – аларны йөгәнли алмаганга ярдәмче чакырганнар икән. Менә шул ярдәмче булып мин килдем. Отряд белән танышырга көндезге йокы вакытында кердем. Мендәрләр оча, тавыш-кычкырыш... Вожатыйлары педагог белеме алган тәҗрибәле укытучылар булса да, тәртип урнаштыра алмыйлар. Мин урнаштырдым: салкын сулы Чирчик елгасы шактый суытты кызу канлыларны. Төштән соң унөченче отряд строй белән линейкага килеп рапорт биргәч, бөтен кеше аһ итте. Өч көнләп вакыт уздымы икән, өлкән пионервожатый тәртип бозганы өчен урыныннан куылды. Кемне куярга дип уйлаша торгач, минем кандидатурага тукталганнар. Җаваплылык зур, бала саны күп, җитмәсә, педагогик белемем дә юк бит минем ул вакытта! Үзем дә 19 яшьлек бала! Барысын да оештырырга, тәртиптә тотарга, чаралар уздырырга кирәк. Пединститутның өченче курсын тәмамлап килгән студентлар миңа бойкот оештырды. Ләкин бер атна эчендә бөтенесен дә тәртипкә керттем. Макаренко, Крупская һәм башка педагогларның хезмәтләрен төннәр буе укып чыга идем. Яңа тәрбия планнары кордым. Үзем туплаган белем, төннәр буе укылган китаплар шактый зур авырлыкларны кичеп чыгарга ярдәм итте. Икенче елга инде мине яңа сменага чакырдылар, анысын әкиятләргә багышлап оештырдык, аннан соң хәрби теманы сайладык... Ул күңелле сменаларны әле дә сагынып сөйләүчеләр бар. Андый вакытта күңелем горурлык хисләре белән тула. Үзем дә бит нәкъ шунда чын тормыш мәктәбе уздым, оештыру осталыгын чарладым.

Җәйләрне пионерлагерьларда уздырсам да, химкомбинатта комсомол оешмасы секретареның урынбасары саналдым. Шуннан мине Чирчик шәһәр комсомол оешмасының оештыру бүлегенә чакырып алдылар. Бернинди белемсез, урта мәктәпне тәмамлаган килеш! Үзлегемнән китаплар укырга яраттым шул мин, нәкъ менә шул чорда алган белем запасы ярдәм итте.

Берникадәр вакыттан соң, Ленинградта урнашкан Югары профсоюз мәктәбенә укырга керү тарихым болайрак булды. Шәһәр комсомол оешмасында эшләп йөргәндә үзешчән сәнгатьтә катнаша идем. Халык театрында уйныйм, нәфис сүз сөйлим. Көннәрдән бер көнне «Химиклар» мәдәният сарае директоры мине үзләренә эшкә чакырып алды. Күчтем, бер хезмәт хакына ике бүлек эшен алып бара башладым. Бервакыт директор ялда чакта безгә Монголиянең мәдәният министры килә дигән хәбәр килеп ирешә. «Химиклар» мәдәният сарае бөтен Үзбәкстан өчен үрнәк иде ул вакытта. Халык аптырашта калды. Кем кабул итәр? Эшебез белән кем таныштырыр? Бу җаваплы эш миңа йөкләнде. Дулкынлансам да, бөтен осталыгымны, тырышлыгымны куеп, эшне башкарып чыктым. Министрга мине «Химиклар»ның директоры итеп таныштырдылар. Ул безнең мәдәният сараен бик ошатып, эшчәнлегебезне югары бәяләп китеп барды. Берничә көннән мине җитәкчелеккә чакырдылар. Үзем турында, кайда яшәвем, кайда белем алуым турында сораштырдылар. Ун класс кына белемем булуга карамастан, бик гаҗәпләнделәр. Нәтиҗәдә, Ленинградка укырга җибәрергә булдылар. Мәскәүдә юридик белем алу мөмкинлеге дә бар иде, әмма мин Ленинградны сайладым.



УҢЫШЛАР Ленинградтан соң кире Үзбәкстанга кайтасы килми иде инде. Себердә туган кешегә андагы эссегә түзү бик авыр. Мине, яшь белгеч буларак, Пушкин районындагы «Детскосельский» совхозы мәдәният йортына билгеләделәр. Шулай итеп, авылда яши башладым. Тырышкан кеше һәрвакыт хөрмәткә ирешә. Тиз арада Ленинград өлкәсенең иң яшь мәдәният җитәкчесе булуга ирештем. Аннары авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең «Нива» мәдәният сараена директор итеп куйдылар. Анда сигез ел эшләдем. Аннары инде илдә зур үзгәрешләр башланды, идеология җимерелде. В. П. Капранов исемендәге мәдәният һәм техника сараенда җитәкчелек иткән еллар тормышымның иң авыр вакыты булды. Бина тимер тарттыргычларда гына тора. Астыннан әле метро линиясе дә уза. Мин килгәндә инде тарттыргычларның кайберләре шартлап өзелгән дә иде. Дотацияләр бетте, акча табарга, коллективларны таралудан сакларга кирәк. Мең төрле сорауны берьюлы хәл итәргә тырышып, анда-монда йөгерәм. 18 ел буена ул бинаны иңсәләремдә күтәреп

торгандай хис иттем. Әлбәттә, бу елларда бездә «Чишмә» татар-башкорт җәмгыятенең гөрләп эшләп килүе миңа аерым энергия бирә иде. Халкыбызның гореф-гадәтләрен яңарттык, милли бәйрәмнәр, затлы кичәләр оештырдык. Милләткә файда китерү, милләттәшләрне туплап тору ошый иде миңа. Шулай да, бу Мәдәният сараенда эшләгәндә бик күп борчулар аша узып, эштә ярты сәламәтлекне калдырып китәргә туры килде. Инде менә 15 ел Санкт-Петербург үзәгендә урнашкан бай тарихлы М. Горький исемендәге мәдәният сараеның җитәкчесе мин. 1927 елларда төзелгән, заманына күрә шәһәрдә генә түгел, илдә бердәнбер булган театр-концерт комплексын һәм кинотеатрны үз эченә алган Мәдәният сарае ул. 1968 елда рәсми рәвештә архитектура истәлеге булып танылa. Шунысын да әйтеп узыйм, М. Горький исемендәге мәдәният сарае – Бөек Ватан сугышы елларында бер генә көнгә дә ябылмаган берләнбер бина да әле ул. Блокада чорында балаларны һәм сугышчыларны үзенә сыендырган. Хәтта 1942 елда Яңа елны каршылаганнар монда. Сугышчылар ачлыктан тилмергән балаларга бәйрәм бүләге итеп үзләре өлешеннән берәр котлет һәм берәр кашык мүк җиләгеннән ясалган желе бүлеп биргәннәр. Дошман самолетын бәреп төшергән өчен бирелгән каплы печеньеларын очучылар балаларга бүләк иткән. Кыш бабай булып бүләк өләшкән кеше ачлыктан өзлеккән балаларга карап күз яшен тыя алмаган, диләр. Әлбәттә, бу легендар сарай, әмма мин килгәндә аның хәле шактый начар иде. Түбәдән су үтә, кырык еллык урындыклар, зал яраксыз, фасад таушалган… Ремонт ясар өчен профсоюзлардан 63 миллион ссуда алып, театр-концерт комплексын ремонтладык. Соңрак ул акчаларны кире кайтару мөмкинлеген дә таптык һәм тагын 145 миллион акча эшләп, аны да Мәдәният сараен төзекләндерүгә тоттык. Биредә эшләү дәверендә элеккеге традицияләрне саклап калырга тырыштым.



МӘХӘББӘТ Хатыным Иннага мин бер күрүдә гашыйк булдым! Аны совхозга килгәч очраттым һәм бик яраттым. Танышып, 10 көн узуга, аның эш кабинетына кереп, «паспортыңны ал, бер җиргә барып кайтабыз, кая икәнен баргач күрерсең», – дидем. Без Нева елгасы ярындагы ЗАГСка килдек. Ул каршы килмәде. Язылышканчы без бары тик бер тапкыр парлы бию биедек. Бер кешенең исе икенче берәүне тартып китерә, диләр. Дөрестер ул! Бу турыда Шекспир да язган бит. Авыр операцияләр кичергәндә дә, тормышымны эшкә багышлаган чорда да ул һәрвакыт минем ышанычлы тылым, ярдәмчем булды. Кызларны да күбрәк аңа тәрбияләргә туры килде. Ул бик әйбәт хуҗабикә. Татар халык ашларын тәмле итеп пешерергә өйрәнде. Бәлеш, пәрәмәчләрне тел йотарлык итеп әзерли! Гомеремнең һәр көнендә Иннаның «мин сине бик яратам!» дигән сүзләрен ишетеп яшим, Аллага шөкер. Хатыным каршында бераз оят та миңа. Эшкә күмелеп, аңа аерым игътибар күрсәтә алмадым.



БАЛАЛАР Бер кызым – танылган табибә, икенчесе – рәссам. Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, портретчы Елена Сәетбагинаның әтисе мин. Эш буенча килгән дан-дәрәҗә берни түгел, җәмгыятьтә үз урынын тапкан горурланырлык балаларың булсын икән ул! Киләчәктә балаларым, оныкларым үзләрен «татар» дип яздырасына иманым камил. Без, татарлар, бик эшчән халык бит. Мин эшкә киткәндә кызларым йоклап кала, кайтканда да йоклаган булалар иде. Инде кызларымның кызлары үсеп җитте. Аларга татар телен өйрәтеп, сөндереп каласым килә. Оныкларым Шәрык гимназиясендә белем ала.



ДУСЛАР Кечкенә генә тарихым бар. Тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, мин мәктәптән документларымны алып китәргә җыендым. Башка укый алмаячагымны, яшәр өчен акча эшләргә кирәген аңлый идем инде. Өч сәгатьтән соң килергә куштылар. Билгеләнгән вакытка килгәч, завуч янына кертеп җибәрделәр. Аның улы безнең параллель сыйныфта укый иде, ялкау укучылардан санала. Анфиса Ильинична сүзне малаеннан башлады. «Әнвәр, син бит инде безнең Женяны беләсең. Аны тәрбияләргә безгә булышсаң иде дип, синнән ярдәм сорамакчы булам. Безгә яшәргә күч әле?!» – диде. Аның укытучыларга хас нинди зирәклек кылганын еллар узгач кына аңладым. Өч балалары янына дүртенчегә мин килдем. Бер өстәл артына утырып ашадык. Ул балалар әле хәзер дә миңа «Кадерле абыем!» дип язалар. Аллаһ минем юлыма һәрвакыт олы йөрәкле, яхшы күңелле кешеләрне чыгарып торды. Минем бик хөрмәтле дусларым күп. Алар белән туганнарча аралашып яшәргә насыйп булды. Мин яраткан кешеләремне үземнән җибәрмим, аларның да минем янымнан китәселәре килмидер дип уйлыйм.



ДИН Карт әбием бакыйлыкка йөздән узып күчсә дә, соңгы көненә кадәр биш вакыт намазын калдырмады. Нинди генә заманнар булса да, ул безгә диненә тугры калу үрнәген күрсәтте. Аллаһка ышану хисе күңелемдә һәрвакыт яшәде. Әбием өйрәткән догаларның да ярдәме көчле булды. Равил хәзрәт Гайнетдин ярдәме белән хаҗга барып кайту мөмкинлеге дә ачылды. Һәр гамәлемнән Аллаһ риза булуын телим.



АКЧА Катлаулы сынаулар кичергәннән соң, үзем дә авыр хәлләрдә калган кешеләргә булыша башладым. Ләкин бу турыда үзегез сораганга гына сөйлим. Кылган гамәлләрем турында кычкырып сөйләп йөрергә яратмыйм. 45 ел профсоюз оешмаларында эшләгән кеше буларак, зур байлыклар турында сөйли алмыйм. Ярдәм кирәк кешеләргә булдыра алганча чын күңелемнән булышам. Акча өчен борчылмыйм. Юмарт булырга тырышам. Акча минем өчен зур роль уйнамый. Яшәргә һәм дәваланырга җитсә…



КУРКУ Куркам! Бу катлаулы заманда балаларымны, оныкларымны калдырып китәргә куркам. Аллаһка ихластан ышанган һәр кеше Кыямәт көнендә Аның каршында җавап тотасыннан куркып яши. Мин дә шундыйлардан…

Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул инде. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...

КАП-КАРА КӨН ИДЕ...



Миңа 13 яшь. Яңгыр явып тора, кап-караңгы ямьсез көн. Тыны бетеп, сулуы капкан әни иртән көтү куып кайтты да: «Балалар, торыгыз, сугыш башланган! Ирләрне сугышка алалар. Әтиегезне дә алырлар инде», – дип елап җибәрде. Дүрт бала үстек без. Мин – олысы. Шул көнне үк күп авылдашларны яу кырына озаттык. Ә сентябрь аенда әтигә дә чират җитте: ул да сугышка китте. Әмма башта ук фронтка китмәделәр әле – Тәтешкә отрядны туплау урынына җыйганнар иде. Бу хакта ишеткәч, тулган көмәне белән әти янына башта әни барып кайтты. Анда аларны айдан артык авыл хуҗалыгы эшләрендә эшләткәннәр икән. Ноябрь башында мин дә бер бабайга ияреп әтине күрергә киттем. Җәяүләп бит әле! Туктамыйча диярлек атлап, дүртенче көнне генә барып җиттек. Солдатларның китәр көннәре җиткән, иртәгә юлга кузгаласылар икән. Әти мине күреп, күтәреп алды. «Ничек курыкмыйча җибәрде сине әниең?» – дип, озак итеп кочаклап сөйде. Ул көнне әти янында куна калдым. Икенче көнне саубуллашып, әти мине Чүпрәле кешесенең атына утыртып җибәрде. Аякта – резин галош, өстә дә юка кием.
7 ноябрь – Октябрь бәйрәме көне иде. Кайтырга чыккач, котырган буран башланды. Ярый әле теге кеше толыпка төреп утырткан иде, юкса, белмим, ничек кайтып җитәр идем?

Әти белән соңгы тапкыр күрешеп, бәхилләшеп калуыбыз булган икән бу. Киткәннән соң нибары бер хаты гына килде. Безнең җавап хатыбыз да барып җитмәгәндер, берничә авылдашыбыз белән Мәскәү янындагы беренче сугышта ук өсләренә бомба төшеп, үлеп калдылар. Бергә сугышка кергән иптәшеннән алган хәбәр аша белдек ул хакта, рәсми кәгазь килмәде. Гәүдәсе табылмаган, билгесез югалучылар исемлегенә кертелгән иде. Нәкъ шул көнне сеңлем Гөлсинә дөньяга аваз салды. Кайгылы хәбәрне ишетүгә, өянәге тотып, әни аны кулыннан төшереп җибәрә...

Әни күңеленә кереп калган бер вакыйга турында гел елый-елый сөйли иде: «Бервакыт без ерак авыл ягына утынга киттек. Атыбыз юк, ике сыерны җиктек. Бүреләр бик күбәйгән иде ул елларда. Агачларны төяп бетергәч, Мирзаҗанны йөк өстенә утыртып кайтырга кузгалдык. Ярты юлга җиткәндә, әллә каян гына каршыбызга берничә бүре килеп чыкты. Бик курыктым, әмма үземне кулга алып, сыерларны һәм баланы куркытмас өчен, эчемнән генә догаларымны укый-укый Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорадым, тыныч булырга тырышып атлавымны белдем. Күрәм: бүреләр дә минем белән рәттән бара, ләкин, ни хикмәт, безгә бер адым да якынаймыйлар. Шулай тавыш-тынсыз гына озак атладык. Минуты сәгатькә тиң кебек иде... Йөрәгемнең дөп-дөп типкәне боларга ишетелмәсә иде дип уйлыйм үзем. Тиздән авыл күренде. Бүреләр дә, көтмәгәндә генә ничек килеп чыксалар, шулай тиз арада сиздермичә генә юк та булдылар. Әллә сугыш афәте кешеләрне генә түгел, бүреләрне дә куркытканмы? Юкса бүре ябагасын койса да, холкын үзгәртми, дигән әйтемне ишеткән бар иде өлкәннәрдән. Тынын да чыгармый утырган улым авылга кергәч телгә килде: «Әнәй, бүреләр ташланмады бит, әйеме?» Елап җибәрмәс өчен иренемне каты итеп тешләдем...»

Озакка сузылган, күпме гомерләрне алып калган, бетмәс-төкәнмәс күз яшьләрен түктергән, күпме газаплар китергән сугыш никадәр баланы – әтиләреннән, хатыннарны – ирләреннән, аналарны балаларыннан мәхрүм калдырды...

Әни еш искә төшерә иде: «Сугыш беткәннән соң тагын да авыррак көннәр килде. Исән калучылар – кем аяксыз, кем кулсыз йә күзсез, гарипләнеп булса да әкренләп кайта торды. Дүрт баламны җыям да мин дә аларны каршыларга чыгам. Күңел ышанмый, менә-менә безнеке дә кайтып килер төсле. Кемнәрдер шатлыктан елый, аларга карап минем дә күздән яшьләр ага. Шунда Мирзаҗан әйтә: «Әнәй, ә син алар исән кайтканга елыйсыңмы?» – ди. Минем ник елаганымны аңларлык түгел иде шул әле ул сабый...»

Фаизә ӘСМӘТУЛЛОВА

P. S. Бу әбиләрнең өчесе дә – сугыш чоры балалары, гыйбрәтле язмышлы кешеләр, ятимлек ачысын сабый чактан ук татып, яшьли олыгаерга мәҗбүр булган буын. Балачак хатирәләрен еламыйча, тыныч кына сөйли дә алмыйлар.

Әлеге язманың дәвамын журналист Әлфия Саматның якын көннәрдә басылып чыгачак «Татарның үз Үбие» исемле авыл тарихына багышлап язылган китабында тулысынча укырга мөмкин.
Фотода: Фаизә әби *(уңда)* сеңлесе Гөлсинә, киленнәре Фәрдания белән.



PRESSA



САНДЫК ТУЛЫ БАЙЛЫК, САНДЫК ТУЛЫ СЕР...



Лилия
ГӘРӘЕВА

Үзе – шкаф, үзе – карават, үзе – өстәл. Йә, табышмакның җавабын кем белә? Сандык ул! Яшь килennең бар дөньясын сыйдырган бирнә сандыгы! Туган йорт җылысы да сыйган үзенә, күз нурларын түгеп чиккән сөлге-тастымалы, яулык-күлмәкләре, сабын-кершәне дә...

Безнең дә бар иде ул. Ачкычын борсаң, челтерәп ачыла да, өй эченә җир җиләге катыш урман исе, яңа тукыма исе тарала. Сабантуйга киясе тәти күлмәкләр дә шунда, дәү әнинең кызыл башлы тастымаллары, озын чуклы ефәк шәле, күн читекләре, без курчакка күлмәк итеп йөргән изүләре, үлемтеккә дип җыйган яулыклары да... Бу йортка дәү әнинең үзе белән бергә килеп, бергә картайган ул. Әнинеке келәттә иде. Ә минеке булмады да. Безнең чорда яшь киленнәр бирнәләрен комодка яки чемоданга тутыралар иде. Алай да, йоласына китерер өчен, бер туганыбыздан алып торган идек сандыкны. Сандык сату, сандык чыгару, кияү йортында сандык ачу кебек матур йолаларны комод яки чемодан белән ничек башкарасың? Хәтерлим әле: сандыкка өелгән юрган-мендәрләр өстенә сеңлемне менгереп утыртып, дус кызларым бирнә бәясен күтәрә-күтәрә, көлешә-көлешә сатканнар иде аны. Аннары кияү егетләре ике ягыннан иплəп кенә тотып, машинага чыгарып куйганнар иде.

Ишеккәйләр ачтым, ай, көн күрдем, Сандыккайлар ачтым, мал күрдем.

Кызы – бишектә, җиһазы – сандыкта

Зәй районы Олы Шепкә авылында яшәүче Рәйхат Сафиуллиннар өендә сандыкларның төрлесе бар: зурысы, кечкенәсе, агы, көрәне, ясалып беткәне, үз чиратын көткәне...

– Боларны ясау катлаулымы? – дип кызыксынам, бизәкле сандыкларга сокланып.

Оста, мыек астыннан көлемсерәп, бермәл тынып тора. «Берәү килгән иде, ничегрәк ясыйсың, ди. Карап-карап торды да, бернәрсәсе юк икән моның, дип кайтып китте. Бераз вакыттан соң хатынынннан сорыйм, ясадымы, дим. «Ясый алмады, кызны кияүгә комод белән бирдек», – ди. «Комод белән кияүгә чыкмыйлар, комод белән кияүдән кайталар гына бит», – дидем. Кызыксынучылар бар ул. «Материалын кайдан аласың, күпмегә аласың, нинди буяуга буйыйсың?» – диләр. «Анысын үзегез эзлисез инде, мин дә беркемнән сорап өйрәнмәдем», – дим.

Иң беренче сандыгын күрше кызы Рузиләгә дип ясый ул. «Безгә дә кирәк», – ди дус кызлары. Аннары Минзәләдән киләләр, Чаллылар, Дүртмунчалар, Бөгелмәләр, Чаллыбашлары... Шушы ун елда гына да кырыклап сандык ясый оста.

Сандык ясау такта сайлаудан башлана икән. Күпләр уйлаганча, нарат такталар бармый аңа. Минем соравымны күземнән үк укып, Рәйхат абый аңлатырга ашыга: «Наратка буяу яхшы ятмый. Сандык өчен иң яхшысы чыршы инде. Әмма туп-турыга ярган такта да ярамый. Яхшы итеп киптерелгән дә булсын ул. Ярашлы материалын таба алсаң, калганы инде осталыктан гына тора».

Оста кулында балта да – пәке

Рәйхат абыйның гараж түбәсендәге остаханәсендә урман исе генә. Оста бер як стенага сөялгән такталарны кулына ала-ала безгә «дәрес» уздыра: «Менә болары – имәннеке. Имән такта авыр һәм нык була, ләкин сандыкны аннан ясамыйлар. Дөрес эшкәртмәсәң, тик торганнан гына да ярылып китәргә мөмкин ул. Болары – карагач. Анысының рәсеме матур, тиз генә муртаймый да, әмма ул да авыр. Карагач та, имән дә – салкын агач. Алардан ясалган җиһазлар да салкын һәм авыр була. Болары – юкә. Халык юкә дими, сөян, ди. Сөян агач – иң нык агач, бер кибеп китсә, балта белән дә юна алмыйсың. Элеккегеләр өйнең матчасын шуннан гына ясарга тырышкан. Юкәдән ясалган әйберләр нык була, ләкин бәясе кыйммәткә чыга».

Безне, әлбәттә инде, бер сандыкны ясар өчен күпме вакыт кирәклеге дә кызыксындыра. Останың: «Илһамың килеп торса, егерме көндә төгәлләп була», – дигәне тагын гаҗәпләндерә. «Һәй, егерме көн әле ул иң аз дигәне, – ди ул. – Кайчак ярты елга да сузылырга мөмкин. Кактың, суктың, буядың да эше бетте түгел шул... Әүвәл кысасын ясыйм, аннары такталарны беркетеп, «угольниклар» белән кысам: ярыклары калырлык булмасын. Әрҗәсен күңелемә ярашлы дип тапсам, кабаттан сүтәм дә, җилемләп, шөрепле кадак белән җыям. Аннары аякларын беркетәм. Иң ахырдан гына капкачына керешәм. Анысы – иң катлаулысы. Сандыкны җыеп бетергәч, шомартам, «растворитель» белән юып, махсус состав белән эшкәртәм. Өч кат буйыйм. Гадәти буяу бармый, агачның фактурасы күмелә. Буяу кипкәч, берничә кат махсус лак белән каплыйм. Аның өчен таман гына итеп мунча ягам. Лаклаган вакытта җылылык та, дымлылык та тиешенчә генә булырга тиеш. Аннары, утырып, ничек итеп сырасын уйлыйм. Анысына инде күгәрми торган калай кирәк. Илһам килсә, төне буе да эшли алам». «Төн уртасына кадәр тек-тек чүкеч тавышы бездә, – дип сүзгә кушыла йортның хуҗабикәсе Мөсфирә ханым. – Әле кичә берсен түр якка чыга торган ишек уемына бастырып куйган иде. «Чәй эчкәндә карап утырам мин аңа, ничек итеп сырсам матуррак буласын уйлыйм», – ди». Юк, ирен ачуланып түгел, яратып әйтә ул бу сүзләрне.



Ата һөнәре – балага мирас

Рәйхат абыйның әтисе Тәүҗип абый да балта остасы булган. Шепкәдә ул койган капка-коймалар әле дә исән. Көянтәләр дә бөккән ул, орчыклар да кырган, тараклар да ясаган. «Мәктәптән кайтуга, әтигә булышырга бара идем, – дип искә ала Рәйхат абый. – Аңа булыша-булыша, акрын гына өйрәнелгән инде. Башта балаларга уенчыклар ясадым. Кызым Айгөл янына кергән күрше кызларының курчакларына караваt



Фото: Анна Арахамия

Акыл күпкә җиткерер, һөнәр күккә кадәр менгерер.

ясап бирсәң, башлары күккә тия иде. Аннары караватларны зурлар өчен ясый башладым. Тәрәзә кәрнизләре, йөзлекләр, ишек уемына аркалар... Кайсын үзем уйлап чыгарам, кайсын телевизордан күрәм. Берсендә кулыма Чыңгызхан турындагы китап килеп керде. Шул чорның бизәкләп эшләнгән арка сурәтләрен карап, «Чыңгызхан арка»лары ясадым. Соңгы елларда менә сандыклар ясыйм».

Заманында Тәүҗип абый да сандыклар ясаган. Шепкә кызларын кияүгә шул сандыклар белән биргәннәр. Рәйхат абыйларның үзләрендә дә саклана әле аның берсе. Йортның хуҗабикәсе Мөсфирә апаныкы ул. «Монысы үз түремдә торыр», – дип уйладымы икән оста аны ясаганда?!

Бирнә биргән биркә килен

Рәйхат абыйлар гаиләдә бишәү үскән. Бишесе дә алтын куллы аларның. Иң олы апалары Разия ханым Рамазанова – чигү остасы. Үзе белән таныштырганда, уенын-чынын кушып: «40 ел мәдәнияттә эшләдем, 22 елын – түләүле, калганын – түләүсез», – дигән иде. 10 нчы сыйныфны тәмамлауга, Шепкә авылы клубына сәнгать җитәкчесе булып эшкә керә ул. Югары Мәлемгә тормышка чыккач, берара яраткан



эшеннән аерылып торырга туры килсә дә, соңыннан барыбер сукмаклары аны мәдәният йортына илтә. Бирнә әзерләү, сандык тутыру, туй йолалары турында аның кебек тәмле итеп тагын кем сөйли белә икән?!

– Әниебез Зәйнәп тә кул эшенә бик оста булды, – дип башлады ул сүзен. – Әллә ничә төрле чигү чигәр иде. Әле дә күз тимәсен үзенә. Бәхетсезлеккә очрап, сыңар кул белән калса да, үз көнен үзе күреп яши әле. Бөтен эшне әнидән өйрәндек. Кич утырып үзебезгә сандык малы әзерләр идек. Иң элек – түрләмә чигелә. Анысы өйне әйләндереп, түшәм астына эленә. Аннары дүрт-биш тәрәзәлек итеп пәрдә әзерләнә. Пәрдәдән соң тәрәзә арасы чигәсең. Карават башы белән караватка каршысы да кирәк. Аларның аскы итәгенә челтәр тотыла. Бидәр-бидәр чәчәкле сатин тукымадан караватка корырга чаршау тегәсең. Тышы чигүле ике мендәр әзерлисең, юрган сырдырасың. Урын-җир өстенә ябарга япмасы да кирәк. Берара әзер япмага шприцтан ясалган ыргак белән чигә башладылар. Йөнтәс келәм сыман, бик матур килеп чыга иде ул. Аннары ике өстәлгә ашъяулык әзерләнә. Сөлгеләр, тастымаллар да кирәк. Боларның барысын да сандыкка тутыргач, иң өскә кайнана-кайнатага, кияүнең үзенә, кайниш белән каенсеңелләргә дигән бүләкләр куела. Бирнә малы арасында тагын бер бик мөһим бүләк була әле – яшь киленнең Сабан туена бирергә дип чиккән сөлгесе ул. Безнең якта әле дә бар бу гадәт. Сабан туена бүләк җыючылар яшь килен төшкән йортка кереп, атап сорый аны.

Разия ханым үзенең өч кызын да бирнә әзерләп кияүгә биргән.
Ике кызы бабайлары ясаган сандык белән барганнар.

– Сандыкның да, чигүле мендәрләрнең дә беркайчан модасы чыкмады. Хәзер дә мендәр тышлары, килен сөлгесе, алъяпкычлар чигеп бирүемне сорыйлар. Туйны элеккечә итеп уздырырга теләүчеләр арта. «Кызымны борынгыча итеп бирәсем килә, – дип, Чаллыдан бер ханым килгән иде, – ди Разия ханым. Ул чиккән әйберләр Мәскәүгә кадәр киткән.

Бу якларда эре чигешне яраталар икән. Чигү җепләрен төсле шәлләр сүтеп әзерлиләр. «Мулине җепләренең төсләре ул кадәр җете түгел», – дип аңлата уңган ханым.

Кара эшкә – ак көмеш

Сандык хакларын белеш әле, дигән иде кызлар, юлга чыкканда.

Оста җавап бирергә ашыкмый. Сизеп торам, күңелен биреп, вакыты белән исәпләшми эшләгән сандыкларына хак кую авыр аның өчен.

– Казаннан берәү сорады. Ике сандык әзерләп куйдым. Яхшы машина белән кайтып туктады. Хакын әйттем. «Юк, мин аны бу бәягә алмыйм», – ди. «Ярар, көчләп сатмыйм, ерактан ук кайттың, шуның өчен бәяне киметәм», – дим. «Ул бәягә дә алмыйм. Илле мең дисәң, алыр идем. Ә син әйткән бәягә алырга оялам», – дип, утыз мең калдырып китте. Утыз меңгә сатмыйм, дип тә әйтеп карадым, ризалашмады, – дип, яңарак кына булган бер вакыйганы искә төшереп узды Рәйхат әфәнде. – Җиренә җиткереп, яхшы материалдан эшләнгән сандыкның бәясе арзан була алмый. Фанерадан гына җыеп, трафарет белән чәчәк кенә төшереп эшләсәң, арзан була, билгеле. Минекеләр өлешләп ябыштырып, яхшылап киптерелгән тактадан ясала. Буяуның да агач бизәген томаламый торганын, кыйммәтлесен алам. Лакның да гадәтие ярамый. Калайны Себердән үк кайтартам, бездә юк андый калай. Эш кораллары да гел яңартып торырга кирәк. Аның бәясе менә шулардан чыгып исәпләнә.

Сандыкны кияүгә чыгасы җиту кызлар гына сорыймы дисәм, юк икән. Өй җиһазы, йорт бизәге итеп алучылар күбрәк тә икән әле.

Зәйдән кайтышлый машинада уйлап бардым әле: теге ике сандыкны да кабаттан буяп, түргә куярга кирәк булыр. Сандыклы өй – серле өй бит ул.

ҖАТЫН-КЫЗГА МӘЧЕТКӘ ЙӨРҮ ДӨРЕСМЕ?



«Хатын-кызларга мәчеткә йөрергә ярыймы? Төрле кеше төрлечә сөйли, кемдер, мәчеткә хатын-кыз йөрми, намазыңны өеңдә укы, ди. Динебез моңа ничек карый икән?» – дигән сорауларны еш ишетергә туры килә. Аларга **Сәйдә абыстай АППАКОВА** җавап бирә.

– Әлеге сорауны миңа күп бирәләр. «Мәчеткә барган идем, анда хатын-кызлар юк диярлек. Бәлки, безгә мәчеткә йөрү тиеш түгелдер?» – диләр. Нигә йөрмәскә тиеш соң әле ул? 1990 нчы елларда, элегрәк тә Мәрҗани мәчете хатын-кызлар белән шыгрым тулы булды. Утырып торырга түгел, басып торырга да урын булмас иде. Шәһәрдә бер генә мәчет. Халык дингә бик сусаган вакытлар. Әгәр рөхсәт булмаса, имамнар туктаткан булырлар иде. Берсе генә дә безне кире бормады.

Хәзер инде мәчет-мәдрәсәләребез бик күп, Аллага шөкер. Имам-абыстайларыбыз да җитәрлек. Һәркем үзе алган гыйлем белән гамәл кыла. Әмма шуны белеп яшик, мәчет – Аллаһы Тәгалә йорты, аңа һәркем керә ала. Бер генә кешенең дә: «Ник килдең? Хатын-кыз намазын өендә генә укырга тиеш!» – дияргә хакы юк. Мәчеткә йөрү хатын-кызның үз ихтыярында. Коръәндә бу хакта аятьләр китерелә. Аллаһы Тәгалә: «Намаз бозык эшләрдән тыяр. Мин адәм балаларын бу дөньяга сынар өчен яралттым, акыл бирелгән икән, акылның зәкятен намаз белән түләсен!» – диде. Ирләргә генә димәгән бит, адәм баласына дигән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) әйтә: «Мәчеткә баручыга, аннан кайтучыга Аллаһы Тәгалә җәннәттә ризык әзерләп куяр», – дигән. Ир-атка гына димәгән бит ул да. Мөхәммәд пәйгамбәребезнең (с. г. в.): «Дингә иң (зур) күп зарар китерүчеләр – наданлык белән дин тотучылар», – дигән сүзе дә бар. «Үз башыннан чыгарып, динне авырайткан кеше иң соңында үзе уйлап чыгарган дини кагыйдәләр астында калып изелер», – болар да пәйгамбәребез (с. г. в.) сүзләре. Язмаларда: «Намаз укучыны тыймыйк, куркытмыйк, күңелен төшермик. Таләпләрен генә аңлатыйк, төзәтик, белгәнебезне өйрәтик. Дини кагыйдәләрне үзгәртергә беребезнең дә хакы юк», – диелә.

Элек хатын-кызлар мәчеткә йөрми иде, дип кырт кисүчеләр дә бар бит...

– Йөрергә аның вакыты булмаган! 10–12 баланы өйдә калдырып чыгып китә алмаган. Менә аның ире, мәчеттән кайткач, имам сөйләгәннәрне түкми-чәчми гаиләсенә җиткергән. Хәзерге заманда да шулаймы соң? Хатын-кызның мәчеткә бару-бармавы турында катгый тыю да юк, фарыз да ителмәгән, үз мөмкинлегендә. Тәкъдимнәр генә бар. Хатын-кызга җомга намазларын, гомумән, намазларын өйдә генә уку да рөхсәт ителә.

Кайбер язмаларда «хәерлерәк» дип тә язылган. Моны ничек аңларга?

– Барлык гаиләдә дә ире: «Бар, җаным, намазларыңны мәчеткә барып укып кайт!» – дип озатып калмаганын да белә бер чор кешеләре. Гаиләдә берсе – бер, берсе икенче якка тартып яшәгәнгә күрә балалар да үз дигәненчә үсте. Шулай да хатын-кызлар кыю, тәвәккәл, ихласрак булды. Динебезнең алга китүенә без хатын-кызга рәхмәт әйтергә тиеш. Ул елларда ирләр кайда булгандыр, дин белән кызыксынганнары санаулы гына иде. Укытучылар да хатын-кызлар булды. Әле хәзер дә шул күренеш. Мөхәммәд пәйгамбәребез (с. г. в.): «Әгәр белгәнеңне өйрәтмичә вафат булсаң, кабер газабының иң авыры булыр», – дип әйтеп калдырган бит.

Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд (с. г. в.) өммәтенә биш вакыт намаз укуын фарыз итте. Бу биш вакыт намазны кайда укысагыз да: өйдәме, мәчеттәме – укы гына! Ниятькә карап, гамәл кылына. Намазны мәчеттә укысаң, савабы 27 мәртәбә артык булыр, диелә. Сәламәтлегең, вакытың, мөмкинлегең, теләгең бар икән, рәхим ит, мәчеткә барып укы! Вәгазь тыңлап, күңелең тынычланып кайтырсың. Әмма мәчеткә йөрүнең үз кагыйдәләре бар, аларны да онытма!

Ул кагыйдәләр нинди?

– Мәчеттә кул биреп исәнләшмиләр, кеше зекер кылып, дога укып яки уйланып утырадыр. Җилкәсенә кагылып, синең аны бүлдерүең бар. Мәчеттә кычкырып сөйләшмиләр. Монда гайбәт тә булырга тиеш түгел. Гайбәт ул – мәет булган туганыңның итен ашауга тиң, бик әшәке гамәл, диелә. Аллаһы Тәгалә «Бүлмәләр» сүрәсендә (11 нче аять): «Бер кеше икенче кешене мәсхәрә итмәсен. Шәт, мәсхәрә ителгәне мәсхәрә итүчегә караганда хәерлерәктер», – ди. Аллаһы Тәгалә сиңа кирәкле мәгълүматны үзе җиткерә. Әгәр җиткермәсә, димәк, аның сиңа кирәге юк.

Динебезне тотып, вакытында намазларыбызны укып, Раббыбыз тыйганнардан тыелып яшәргә язсын барыбызга да. Амин!

Хатын-кыз күңелендә генә туа ала торган уй-кичерешләр, ярату, сагыну, үкенүләр... Ә шул хисләр шигырь телендә аеруча көчле, тәэсирле була икән! Флера Гыйззәтуллина шигырьләрен укып карагыз әле. Әйтерсең лә шагыйрә йөрәгендә карурман шаулый, күз яше дә шатлык китерә. Газаплы да, сагышлы да, бәхетле дә язмыш булачак шагыйрәне ятимлек ачысы белән дә сынаган, туган Азнакаеннан Кемерово, Донбасс шахталарына да, Ом–Том тимер юлларына да, Карабаш, Тольяттиларга да китереп чыгарган. Һәм алар тәэсир-тойгыларга төренеп, шигъри халәткә күчкән.



Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА

СУЛКЫЛДЫЙ КҮҢЕЛ, СУЛКЫЛДЫЙ...

Кайту

(Поэмадан өзек)

...Мәшһүр татар читтә ни күрсә дә,
Башын ком астына яшермәде.
Рухка суккан яшен камчылары
Йөрәгендә генә яшенләде.
Йөрәгендә генә моң атының
Ишетелә тояк кагышлары...
Чорга йөрәктәшлек күрсәтергә
Кайта Сөембикә варислары.
Кайта алар ерак Колымадан,
Кузбасслардан,
Кырым,
Донбасслардан...
Бу варислар сагынып ут йотудан
Ничә буын моң алмашы алган!..
Аларны да «Балам-багалмам!» дип
Багып үстергән бит Әткә-Әнкә...
Парлап үскән толым очларында
Челтер-челтер килә чулпы-тәңкә.
Челтери күк алар: «Онытмагыз!
Без бит сезнең дәүләт символыгыз...
Сызылып аяз таңнар аткан чакта,
Талга кунып сайрар былбылыгыз...»

* * *

...Сөргенлектә нужа чигергәндә
Татарга да кемдер ярдәм сузган.
Ирексездән телләр чатнаса да,
Корымаган җирдә иман, вөҗдан.
Ни күрсә дә Ватан әнкәләре
Чулпы-тәңкәләрен сатмаганнар:
Бу байлыкны алар сөю төсе,
Кыйбла төсе итеп саклаганнар.

Кайтам илкәемә

Барлый ил чакрымнар белән
Үлчәп юл араларын,
Кайчандыр читләргә китеп
Адашкан балаларын.

Мин дә сибелгән татарның
Бер газиз баласы ла;
Иделем аша юл сузам –
Чакрымнар арасыннан.

Сагыну-кайту юлының
Шатлыгын-сөенечен,
Акчарлак очыра Идел
Багышлап минем өчен.

Идел киң, акчарлак җанның
Уйнаклап очарына.
Кайтам мин, кайтам, илкәем,
Сыйдырсаң кочагыңа.

Мин дә сибелгән татарның
Бер газиз баласы ла;
Иделем аша юл сузам –
Чакрымнар арасыннан.

Хуш, Иделем!

Идел-йортны давыл чолгап алса,
Акчарлаклар үксеп өн сала.
Иделемнән милли хис яуладым,
Әрнешләргә җабып мең чара.

Мин үзем дә акчарлактай үксеп,
Ут-давылга җырлап баш куям.
Җыр иркендә, бәлки, йомшар эреп
Язмыш дигән текә таш кыям.

Каерылса да тынмый талпынудан
Акчарлакның җитез канаты.
Акчарлак ул – татар милләтенең
Саубуллашу экспонаты!

Хуш, Иделем! Сау бул!
Китәм синнән.
Китеп давылларда каламын...
Акчарлакның үксеп елауларын
Истәлегең итеп аламын.

Үкенеч

...Җир саргайса, искән җил саргая.
Без бу хәлне күрдек... кичердек!..
Шашкын мәхәббәттән исердек тә,
Күзге ачы җилдән киселдек.

Һәм бердәнбер көнне аерылыштык,
Бар дөньяны салып исәпкә...

...Куеннарга тулып сулкылдый җил,
Ялгыш кына башны исәк тә...

Дилбегәсе җилнең – Синдә микән?
Җирдә микән явы – күзләрнең? –
Арабызда сары җилләр йөри
Үкенече булып көзләрнең...

* * *

...Сулкылдый күңел, сулкылдый,
Сулкылдап аккан судай.
Сикереп суларга төшкәндә
Утларга пештем бугай.

Сулардан ялкын аламмы?
Янаммы өшер өчен?
Шифасын үзе тигезләр
Инешем – кичерешем.

Төшенер күңел фәрештәм,
Хәлемне бирсәм сөйләп...
Табыну – ялыну түгел,
Табынам үзем теләп.

Сагынам!
Сагынып түзелгән:
Түзгәнгә өзлегелгән!
Ут-сулар кичеп эзләдем,
Бизмәмен үзлегемнән.

Хәтердә – вәгъдәләр елгасы

Күк күкрәп яңгырлар яуганда,
Пар яшен йөрәкне чолгады.
Яшенләп, тетрәнеп сөюем
Ярыннан чыгарды елганы.

Бу нинди газаплы сөю соң?
Йөрәккә сүнмәс ут кабызган?!
Без сузган мәхәббәт күперен
Ярсулы ташулар агызган.

Хәтердә – вәгъдәләр елгасы!
Ашкына хыялга җитәргә...
Кызганам яшьлегем ярларын
Күперсез калдырып китәргә.

* * *

...Безнең авыл биек тау астында...
Тау битендә җир җиләге пешә.
Җиләкле җәй рухи ядкарь булып
Гасырлардан–гасырларга күчә.
Йөгрә-йөгрә җиләк җыйган чакта,
Кояштан да җиләк исе килә.
...Таңнар атып Кояш чыккан яктан
Саубуллашу көе ишетелә...
Ишетелә еллар аръягында, –
Әткәемнең чалгы кайраганы.
Кара төндәй шомлы карурманның:
– Сугыш!!!
– Сугыш!!! – диеп шаулаганы.

Ана

Гөрләвексез язлар буламыни –
Күз яшьләре аңа ямь генә.
Тетрәп китте җыерчыклы йөзе,
Күзен сөртте чыклы шәленә.

Таныш кебек сораштырды
Дус-ишләрне, күрше-күләнне.
Кулында зур төен. Юлчымы ул,
Бар байлыгы үзе беләнме?

Шигырь китаплары! Ник?
Аңламыйм:
Әллә әбкәй акылын җуйганмы?
Кем уйлаган гамәл кылыр чакта
Аңа шигырь кирәк булганны.

Озак сузмый үзе серне ачты:
– Дүрт улымның кабере дүрт якта.
Ташларына җырлар яздырыйм дим,
Күкрәгемдә көчләр бар чакта.

Кадерлем, чамала!

Сөю – ул күңелнең
Былбыллы тирәге, –
Яшәрә йөрәкләр сагында.
Без дә бит йөрәктән
Былбыллар очыртып
Серләштек тирәкләр шавында.

Сөю – ул гомернең
Тәңкәле толымы, –
Сагышка чылдырап камала...
Кадерлем, чамала! –
Толымнар чалара,
Гомерләр минутлап санала.

Сөю – ул өметнең
Кояшлы кыйбласы, –
Юл анда җыр аша ачыла.
Кояш та иртәрәк
Баерга ашыга
Моң төшсә кайгылы башыңа...

Таулар җыры

(Якташларыма)

Азнакай тавы Чатыр тау! –
Уралдан соңгы дулкын.
Күкрәктә күтәреп йөрттек
Без шул дулкыннар холкын.
Чатырдан Уралга үрләп
Сүттек без җыр йомгагын.
Сез минем үз җырларым бит!
Сез минем күз нурларым.
Сез минем гали затларым,
Тау җанлы таудашларым.
Мин юкта минем өчен дә
Сыйпагыз тау башларын.
Таулардан биек үрелеп
Карагыз киләчәккә!
Узганнар безне ишетми,
Ни генә сөйләсәк тә.

Тәкъдир

Тормыш! Нигә сине яратырга,
Бу кадәрле булгач мәкерле?!
Лена Шагыйрьҗан

Тормыш!
Сине шундый яраттым мин,
Керле йөзең ялап агарттым.
– Яраттым! – дип, Газраилне хәтта
Күзләремә туры караттым.

Палачыңа хәтта сәлам бирдем,
Биргән чакта башым кисмәгә...
...Аргамаксыз, башсыз җайдагыңны
Инде: «Ярат!» – диеп көчләмә!

Гөлчәчәкләр өмет итмә минем
Үрә катып калган хыялдан...
Төнгә кереп барган хыял күгем
Үтәләтә канга буялган.

...Алын алып гөлен биргәннәргә
Тапшыр, тормыш, сөю дилбегәң...
Ә мин әүвәлгечә иманыма
Тугрылыгым белән бил бөгәм.

...Сөю түгел...
Тормыш, син бит мине
Суламаска хәтта өйрәттең.
Инде... Миңа син дә елмаеп бак...
Соңгы тибешеннән йөрәкнең.

Ак бәхетләр телим

...Ярны – кочар өчен, ә канатны
Очар өчен Ходай яраткан.
Саф күңелдән ак бәхетләр теләп,
Ак канатлар сезгә таратам.

Күктән җиргә йолдыз коелганда
Кыйбла якка карап очыгыз!
Юлыгызда сезнең сүнмәс өмет,
Кулыгызда – бәхет кошыгыз.

Йөз нурларын, якты җан сафлыгын
Алышмагыз берүк бернигә!
Мәхәббәткә, назга сусау йөрәк
Күккә үрли, дәрли-дәрли дә...

Язмышмы бу?

Танылган журналист, язучы Диләра апа Зөбәерованың затлы нәселнең затлы баласы икәнен, нәсел-нәсәбе мәгърифәтче галим Таҗетдин Ялчыголга барып тоташканын, әнкәсе ягыннан тамырлары Ризаэтдин Фәхретдин белән бәйле икәнен ишеткән бар иде инде. Арышлар арасында адашып үскән күктәтәй төсле зәңгәр күзле, кыр чәчәгедәй самими-садә Диләра апаның үз язмышына кагылышлы бер җөмләсе – «Мин төрмәдә туганмын» – шулкадәр тетрәндерде, ул мизгелдә телсез калгандай булдым. Талантлы каләм ияләренең күбесенә хас сыйфат – беркатлылык, хыялыйлык аңа да ят түгелдер, дип гоманларга иде дә... Зыялы, милләт горурлыгы булырлык асылзатларны юк итүләре сер түгел инде. Чынлап та, әтисе Гази абзый – җиде буын мулла нәселеннән чыккан гыйлем зат – репрессия еллары корбаны икән. Халык дошманы хатыны дип, әнисен дә кулга алалар. Күп газап-михнәт күргән гыйлемле әниләреннән дә яшьләй ятим кала кыз бала. Алар җиде туган – җидесе җиде якка таралып көн күрә.

Алай да күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый, язмышлардан узмыш юк дисәләр дә, аңа гел аркасы белән торган икән язмыш дию, дөрес үк булмастыр.

1930 елның 9 гыйнварында якты җиһанга аваз салган Диләранең туган җире Сарман районы Кутәмәле авылы дип язылган. Җидееллык мәктәптән соң ул Алабуга педагогика көллиятенә укырга керә, аны тәмамлагач, Казан дәүләт педагогика институтында белем ала. Шигырь язу белән мавыга. Диплом алуга китап нәшриятына – яшьләр һәм балалар редакциясенә мөхәррир итеп алалар. Яшь иҗатчылар өлеп кызыгырлык дөнья! Ләкин сикәлтәсез шома юл Диләра өчен түгел. Тормыш ыгы-зыгысында кайнамый торып якты образлар иҗат итеп, шәп әдәби әсәр тудырып булмасын белә ул. Авылга китә, Чүпрәле ягында укытучы, мәгариф бүлеге инспекторы, район газетасында хәбәрче булып эшли. «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») газетасының Зәй районы буенча үз хәбәрчесе була. Тынгысыз журналистның язу сәләтен күреп, «Азат хатын» журналына эшкә чакыралар. Командировкаларда йөри, ялкынланып-рухланып көн кадагына суга торган очерклар иҗат итә, укучылар белән очраша. Әдәби мохит үткен каләмле журналистны үзенә суырып ала.

Диләра Зөбәерова «Дустым авазы», «Куш өянке шаһит», «Кыр чәчәге» повестьлары белән – үзенчәлекле язу стиле, җырлап торган йөгерек, мамыклы, матур теле, тирән мәгънәле, халыкчан образлары белән укучы күңелен яулады. Үзе күргән-кичергәннәрне ышандырырлык итеп сурәтли. Җанын ярып бирердәй булып балалар укыткан укытучылар, бәгырьгә төшәрдәй гайбәт аркасында саф мәхәббәтен югалткан Назилә, Ләйсән, Ленизалар тере, чын булып күз алдына баса. «Мине язганнарымнан эзләгез», дип кем әйтсә дә, хак әйткән. Аның геройлары хата-ялгышлардан да хали түгел, әмма үзәге нык, вөҗданлы кешеләр алар. Еллар үткәч тә яратып укырлык әсәрләр иҗат иткән әдибәне балалар кебек беркатлы, ихлас, самими итеп хәтерлибез икән, юкка түгелдер.

* * *

Иҗат ялкыны сүрелдеме, язу күәсе югалдымы, «Азат хатын»нан киткәч, яңа әсәрләре күренмәде Диләрә апаның. Хәер, күргәннәре байтак бу башның, дисә дә урынлы: ирсез калып, терәге, таянычы булыр дип үстергән бердәнбер улы фаҗигале төстә һәлак булды. Хулиганнар кыйды аның җанын. Авыр сынау, кайгы өстенә хәсрәт рухы нык булганнарны да аяктан ега. Ә Ходай талант белән бүләкләгәннәр, гадәттә, тормышка яраша, гаделсезлек белән килешә алмый. Күңел төшенкелегенә бирешмәүнең бердәнбер, сыналган ысулы, хәл кадәренчә эшләргә тырышу да... Хәрәкәттә – бәрәкәт, дип юкка әйтмәгән зирәк ил картлары.

Диләра апаның хастаханәгә эләгүен ишеткән идек. Янына барып хәл-әхвәлен белешергә теләк бар. Тик... кайсы хастаханәдә ятканын белмибез.

Журналист була торып, исем-аты билгеле әдибәне тапма, имеш. Әгәр дә эзләнүгә Мәдинә Авзалова кебек үткен, җитез журналист тотынсамы? Таптык! Карантин, кайчан килергә яраганын хәбәр итәрбез, дип ышандырсалар да, озак көттек. Бүген килергә ярый дигәнне ишетүгә, хастаханәгә йөгердек.

Бүлмәдә өч ятакның икесе буш. Бәләкәй өстәлгә күчтәнәчләребезне тездек. Диләра апа яшел алмага сузылды. Юл уңаенда кибеттән сатып алган алмаларны Мәдинә тиз генә юып килде. Җылы яктан килгән алма теш үтмәслек каты булыр дип кем уйлаган! Ә ул, нарасый җан, бездә үскән йомшак, әчкелтем сусыл җәй җимеше дип белде бугай. Ничә еллар үткәч тә, елыйсыны китереп, күз алдыма килә: Диләра апа, куш учына йомарлаган алманы ычкындырмый, мөлдерәп тик карап тора...

– Безне белмисездер дә инде. Бу – Мәдинә Авзалова, мин – Роза...

– Ничек белмим, беләм. Минем дәвам, минем кебек яза торган язучы Роза Мулланурова. Каләмле кызлар сез! – диде. Йөзе ачылып, тәмләп чәй дә эчтек.

Ни аяныч, бу безнең соңгы очрашу, соңгы күрешү һәм... хушлашу булган. Күп тә үтми, 2000 елның 15 декабрендә самими җанның бизәге – кыңгырау чәчәге төсле зәңгәр күзләр мәңгегә йомылды. Аңа 70 яшь тулган гына иде.

Исем-аты илгә-көнгә билгеле туганнары, җыелышып, Коръән укытып, мул табын корып, Диләра апаны искә алу мәҗлесе үткәрде. Мине дә чакырдылар. Мәңгелек дип, без табынган дөньяның фанилыгын уйлап күңел генә тетрәнде.

Җиһанга адәм баласы елап ялгыз килә, ялгыз китә. Әмма язучының күңел көзгесе – китаплары кала. Әсәрләрендә аның җаны яшидер кебек тоела миңа.

Роза МУЛЛАНУРОВА



Диләра ЗӨБӘЕРОВА

КЫЗ ВӨҖДАНЫ

(хикәя)

Журналист кешегә пароходлы сәфәр сирәк эләгә. Барасы җиреңә чыгып киткән кызулык белән барып җитеп, язасы нәрсәңне суытмый-оетмый алып кайтып, язып тапшырырга тиеш син. Бу юлы җаен табып, бер кешелек каюта алып, Идел буйлап түбәнгә, Алабуга якларына таба утырып киттем.

Алда олы мәшәкатьләр көтә. Ял итеп, фикер туплап, әзерләнебрәк башкарган эшләр хәерлегә була торган иде. Көне дә килеште, нәкъ Тукай әйткәнчә, «сабыр җитми» торган каты эссе көн. Мондый чакта җиләс палубага чыгып, Идел ярларын тамаша кылып утырудан да зур хозурлык бармы икән.

Һай, ямьле дә соң безнең якның табигате... Кояш нурлары алтынга манган Идел өстенә карый-карый күзләрең камашкач, тоташ куак сарган ярларга текәләсең. Шулчак сулышың киңәеп, күңелең олаеп китә. Куаклар артындагы Кама сыртларына баскан юантык имәннәр, ыспай наратлар үрелеп карый. Ара-тирә ашъяулык кына җәярлек аланнар ачылып китә. Яки атылып килгәндә атлап кына чыгышлы инешләр агып төшә.

– Пароходтан каласые да әнә шул инеш култыгына шалаш корып ятасые.

Моны мин әйтмим, күршем әйтә. Ярты йөзен күзлек каплаган, олыгаеп килүче Мәскәү агае әйтә. Җәйгә чыксаң, Уфа, Пермь якларына йөзүче теплоходка каюта табармын димә. Алар ял итүче сәяхәтчеләр белән Мәскәүдән үк тулып килә.

Зур күзлекле агай башлаган сүзне уртаклашмакчы булып авыз гына ачкан идем, палуба эргәсенә таянган ханым телгә килде. Телгә килде диюемнең хикмәте шунда, инде һич шикләнми иллене, илле бишне бирерлек бу сүзсез апаны мин пароходка утырганнан бирле күзәтәм. Кыяфәтендә, карашында ниндидер бер затлылык бар. Ашыкмый гына атлый. Иплэп кенә утыра. Авызын да ермый, маңгаен да җыермый. Өс-башы да пөхтә, яшенә карата килешле, башкалардан аерылып тормый. Кешеләр белән аралашмавы да һаваланудан түгелдер, уйлы-исәпле көннәре моның дип уйлаган идем дә... тавышы бик көр чыккач, аптырап киткәндәй иттем.

– Япа-ялгызыңа бик күңелле булмас.

– Ял итүчегә хикмәтең түгел, икмәгең белән һаваң җиткән, – ди агай. Күренеп тора, аның нияте сүз куерту, бәхәс ачу иде. Ханым сүз көрәштерә торганнардан түгел, инде ераклашып калган инешле ярга моңлы гына карап алды да яныбыздан китеп барды. Кызыксынуым көчәя төште, артыннан атладым. Ул инде пароходның икенче ягындагы агач диванда утыра иде. Күзләребез очрашты, елмаешып баш кагыштык.

– Рәхим итегез,— диде ханым, яныннан урын күрсәтеп. – Сез мине кемгәдер охшатасызмы әллә?

– Шулайрак.

– Булыр, булыр. Миңа мәрхүмә әнкәй, һәркемнең үз ише бар, ди торган иде.

Мин ханымның әнә шулай иркенләп торып сөйләшә башлавына бик канәгать идем. Кызыклы юлдаш булырга охшый.

Купега кереп тәрәзәләрне ачтым да җилләткечне көйләдем. Хәзер ресторан суыткычыннан бер ярты лимонад алып ханымны кунакка дәшәсе генә калды.

Кемнең кем булуын да, кайда эшләп күпме алуын да сорашып вакланмадык, тик кайсы пристаньда аерылышасыбызны гына белештек. Минем дөнья күргәләгән талымсыз кеше булуым күңеленә хуш килде димме, ят кешегә мәңге чишелмәс кебек тоелган табышмак юлдашым ачылып китте. Интуиция дигәннәре әллә чынмы икән. Бу юлы да алдан сиземләвем тикмәгә булмаган, тышкы кыяфәте белән үзенә тарткан серле ханым, чынлап та, рәсемен күргә үк укыйсыны китереп торган тере хикәя булып чыкты.

Көндезен юкка гына кыздырмаган икән, кояш кызарып-янып батты. Күкне тоташ болыт сүрүе каплады. Айсыз, йолдызсыз кара төн инде. Пароход, дулкыннарны шапор-шопыр як-якка аударып, баруын дәвам итә. Караңгы Идел өстендә маяклардан төшкән аллы-зәңгәрле нурлар тетри. Яр буйларында балыкчы утлары җемелди. Төн инде. Пассажирлар каюталарына ябылганнар. Палубада юлдаш апам белән без икәү генә. Ул миңа тормыш дулкыннарына бәрелеп чатнаган язмыш көймәсенең яңадан төзәлүен сөйли. Ул тәэсиргә бирелми, сабыр кан белән өстән-өстән генә сөйли. Минем сорау бирәбирә, төпченеп тыңлыйсым килә, ләкин килешми дә, ярамый да: авторны каушатуым, шөбһәгә салуым бар.

– Игътибарың белән тыңласаң, аңлашылгандыр, әткәемнән айлык кына булып калсам да, мин үземне ярты ятим итеп сизмәдем. Әнкәемнең бер генәсе һәм бик кадерлесе идем мин. Тагын шунысы бар, яшьлек киләчәге белән куәтле дигән булалар бит, шул куәтләнер көннәр бар иде бит әле алда. Синең киләчәгең бар, син иң бәхетле кыз, дияләр иде миңа. Чөнки авылыбызның беренче җырчысы идем мин. Чынлап менә, әллә кемнәрнең дә әллә кайларга яшеренгән серләрен актарта, тутыккан күңелләрне дә уята торган моң бар сыман иде миндә. Үземә үзем генә түгел, күпләр соклана иде. Ун яшемнән район үзешчәннәренә ияреп концерт белән күрше авылларга йөрдек. Сәхнәгә менсәм алкышлардан башым әйләнә. Укытучыларым да өметне зурдан баглыйлар, мине икенче Гөлсем генә дип йөртәләр. Имеш, калага барып, бер-ике ел укып кына алыйм, мин аннан да уздырачакмын әле. Ләкин минем бу татлы хыялларыма әнкәем гел каршы төшә, дөресен әйткәндә, яратып бетерми иде ул артист халкын. Әледән-әле миңа аларның ялыктыргыч күчмә тормышларын яманлый, алар арасындагы шәхси бәхеткә ышанмый. Аның бар теләге – мине медицина юлына озату. Үзе кебек гади фельдшер гына да түгел, врачлыкка укытасы килә иде аның мине. Бер генә бөртек булып үскәннәрнең бер төрләре көпшәк, юаш, әзергәбәзерне генә көтүчән, әниләренең итәгенә ябышып йөрүчән, ә күпчелеге иркә, үзсүзле, мөгез чыгара торган башбаштак булып үсә. Бу кирәкле-кирәксез гадәтләр миндә дә бар иде. «Җиденче классны тәмамлады» дигән таныклыкны эләктерү белән мин өйдән качтым. Чолан стенасында күмер белән: «Әни, бәхил бул, мин артист булмыйча кайтмыйм», – дип сызгалаган язуым гына калды. Дөресен әйткәндә, бу сәфәргә мин айлар буена әзерләндем. Башлап акча ягын юнәтергә кирәк иде бит. Кино-театр килдеме, әнкәй биргән билетлык акчаны янчыкка салам да үзем киночылар таралганчы бер җирдә посып торам. Каләмгә, кара буявына, дәфтәрләргә дигән акча да шул янчыкка чума. Йомышка алган каләм белән язам, кеше карасына манчыйм, вак кына язгач, дәфтәр дә бәрәкәтле тотыла. Ләкин бу тиеннәр белән мин артык мантый алмадым ла. Шулай итеп, ниһаять, әнине сукрандырып, үзем дә шуның тәэсирендә икеләнә-микеләнә генә театр училищесына кереп укый башладым. Бу хакта сүз кузгатмас өчен, тагын шуны да әйтим, минеке кебек ярыйсы гына моңлы, минеке кебек яңгыравыклы гына тавышлылар Казанда шактый бар икән. Тора-бара миңа алдагы бәхетле көннәр океан түрендәге хыялый кораб сыман гына тоела башлады. Тормыш миңа үзенең беренче дулкыннары белән үк бәрәгәйле селтәнде. Училищены тәмамлыйсы елны, миенә кан йөгереп, әнкәем үлеп китте. Күпме үкенеч... күпме яшь... Бу минем тормыш коясымның беренче батуы иде. Башымны кая куярга белми аңкы-миңке йөргәндә, мин «аны» очраттым. Икенче мәртәбә... Беренче кат җәйге каникулдан кайтышлый пароходта танышкан идек без аның белән. Ул чакларда Идел өсләп самолетлар очмый, Кама буйлап метеорлар чапмый, автобуслар аз йөри иде әле. Татарстанның яртысын кала белән тоташтыручы бердәнбер пароходлар гына бар. Пароход дигәнебез, күпме халыкны сыйдыра ала, шулкадәр төйи дә ике арада арлы-бирле йөри бирә. Аның койрыгын студентлар салоны дип атыйлар. Шунда чемоданыңны төртер почмак тапсаң, бик разый инде. Таптым. Запаска сөялгән якорь тирәсе иде, ахры. Шул тимергә башымны куеп черем иткәнмен. Кемдер дәшә кебек. Күтәрелеп карасам, әллә нинди ят күзләр, тотнаклы гына елмаю... Җиз төймәле кара китель, терсәк тирәсендәрәк сары сызыклар. Штурман микәнни?

– Интекмәгез,— диде ул миңа, ягымлы булырга тырышып, – әйдәгез безнең каютага.

Котым алынды. Минем әнкәем егерме икедә тол калган. Гомер буена башка иргә күтәрелеп бакмаган. Шуның тәэсиредер, ул мине үз үрнәгендә тәрбияләде. Юлда чакларда, ялгыз калганда ир кешедән уттан саклангандай сакланырга куша иде. «Әгәр дә мәгәр, – дия иде ул миңа еш кына, – чынаяк чатнаса, ямап булмый. Кыз бала хрусталь чынаяк ул. Төшеп ватылдымы, бетте инде. Алдана-нитә калсаң, миннән ваз кич...» Аның бу фәтвасы мине гомерем буена әрнетеп торды.

– Бармыйм, – дидем мин аңа рәхмәт тә әйтмичә, – и все!

– Шүрләмәгез тагын, – диде ул кесәсеннән пар тешле ачкыч чыгарып, – мәгез, үзегез ачып кереп бикләнеп йоклагыз. Мин эштә... Шундый әйбәт кызның койрыкта аунавын теләмим.

Бик катгый гына тагын кире каккач, китеп барган иде, бераздан тагын әйләнеп килде.

– Нәрсә кыланган буласың, – диде миңа янәшәмдәге пассажирлар, – шундый чибәр егет күңеленә ошагансың икән, горурлан гына.

Шуннан соң бөтен тән буйлап күңелләрне җилкетеп әллә нинди ток узып киткәндәй булды. Әллә оялудан, әллә күңелнең әллә нишләп китүеннән шунда кызарып



Рәсем: Наталья Васильева

киткәнмен. Моны егет тә тоеп алды. Пристаньга төшкәнче гел янымнан китмәде. Шул арада йөрәкләрне тибрәтеп берничә мәртәбә күзләр дә очрашып алды, саубуллашкан булып куллар да тоташкандай итте. Шулчакны кыштырдатмый гына уч төбемә бер кәгазь сылады. Укып баксам, мине нәкъ бер атнадан колхоз базарына чыга торган Болак күпере төбендә очрашуга чакырган икән. Тәннәрем чымырдап китте. Төнге ун... Соңыннан иптәшләрем аңлаткач кына төшендем, ул эшли торган пароход Казанда кичке тугыздан алып төнге уникегә чаклы гына тора икән.

Барыбер чыктым бит мин Болак буена. Килешле, челтәр җиңле күлмәгемне киеп, чәчләремне күпертеп, ярты сәгать алдан чыгып бастым мин аның каршына. Тик, оялуданмы, сабырлыгымны җуйдым, ун туларга нәкъ бер минут кала артыма да борылып карарга кыймый кайтып та киттем. Бик күрәсе килсә, ул да алданрак төшәргә тиеш иде. Шулай дип юаткан булдым инде үземне.

Ә торакка кайткач, иптәш кызларыма ниләр генә фантазияләмәдем аның турында. Имеш, бер генә күрсәгез иде сез аны. Өстендә чем-кара костюм. Якалары кершәндәй ап-ак. Галстугы – крепдешин. Ул чәчләре... Күзләре... Ә сезнең андый егетне кинода да күргәнегез юк ла... Пароходтан гына төштем, ди. Йөгергән. Көчкә тын ала. Кулында бер кочак чәчәк. Әллә нинди безнең якта атмый торган аллы-шәмәхәле чәчәкләр. Алмадым. Хәтере калды. Йөрдем ди бер көлтә букет күтәреп. Исәнләштек тә, аерылыштык та. Сынамый-нитми генә озаттырып йөртмәдем әле үземне. Шунда кызлар икегә бүленәләр. Берәүләре, дөрес эшләгәнсең, егетләр һавалы кызларны ярата, ди. Икенчеләре – һавалылык түгел бу, юләрлек, ди. Уйлама да, елап эзләсәң дә тапмассың ул егетне. Беткән ди аңа дөньяда синнән дә чибәррәкләр...

Ә мин юрган астыннан гына авызымны кыйшайтып ятам, көләсе дә, елыйсы да килә. Әллә инде, чынлап та, тагын бер генә минут басып торасы калган...

Чынлап та, көтәсе, ул пароход егетенең кем икәнен шул чакта ук белеп каласы калган. Икенче мәртәбә канаты сынган яралы коштай мин аның оясына кереп абынмаган булыр идем.

Башына төшкәне дә, төшмәгәне дә беләдер, газиз анадан язган көн – гомеремнең иң әче, иң рәхимсез көне. Мин ул көнне дөнья шатлыгыннан мәхрүм, кояш нурын танымаслык сукыр идем. Шулай итеп, мин кайгымны да уртаклашучы, шатлыкларыма да сөенүче кешесез – әнисез калдыммыни инде... Дөньяның җылысы, кызыгы бетте кебек... Портфельдә аңа язылып җибәрелми калган хат ята. Әнием, гадәттәгечә, миннән тилмереп хәбәр көткәндер. Теге вакытта качып, аны саргайткан чакларым өчен дә йөрәк әрни. Күңел тулы сагыш, үкенеч, газап...

Шулай башымны кая куярга белми Болак буйлап бара идем, кемдер акрын гына җиңемнән тартты. Теләми генә борылып карасам, пароходта очрашкан матур күзләр, җиз төймәләр икән. Алар икәү иде. Фырт кына киенгән кыска чәчле кызны сеңлем дип таныштырды штурман.

Башка чак булса, мин аларга ияреп китмәс идем, ялындырыр идем, шикләнер идем, әлбәттә. Ә бүген шикшөбһәләрдән ерак, дөнья уйларыннан азат, кара пәрдәгә чорналган кара көнем минем. Хәтта каршыма ажгырып трамвай килгәндә дә читкә тайпылмас кебекмен. Ишек катларыннан узасы түгел идем, ай-вай килеп, көйли-көйли пальтомны салдырдылар. Шул арада табын әзерләнде. Кулыма, сабыйга санагандай, кып-кызыл алма тоттырдылар. Тешләмәкче генә идем, штурман икенче кулыма саплы бокал сузды.

– Тукта, башта моны тот, — диде алар икәүләп. – Хәсрәтне шушы юып төшерә.

– Ай, бик әчкелтем, аракымы әллә бу?

– Юк-юк, җимеш суы гына. Менә кара, үзебез дә эчтек.

Башымнан алып табаныма кадәр кайнар йөгерде. Гәүдә җиңеләеп киткәндәй тоелды, һәм мин үземне үзем җәлләп үксеп-үксеп еларга тотындым. Йөрәкне сызып торган хәсрәт тышка бөркелеп чыккандай булды, уйлар таралып, дөньям чайкалып куйды. Моңа кадәр ят тоелган агалы-сеңелле бу кешеләр миңа әллә кайчангы якын танышларым сыман күренә башлады. Шул тәэсирләр астында тагын бер бокал күтәрдем бугай. Томанлы гына шуны да хәтерлим: сулкылдап өзә-өзә, «Карурман»ны җырлап җибәрдем. Ул арада бер почмакта радиола әйләнә башлады. Биергә чыгам дип абынып киттем. Ул мине күтәреп алды. Башымнан сыйпады. «Мин барында син бернинди хәсрәт күрмәскә тиеш», – дип елышканнан-елышты. Җәлли дип уйладым, юатуыдыр, дидем, тик кулларымнан, муеннарымны үбә башлагач кына айнып киткәндәй тоелсам да, кайгыдан йокысыз узган төн, сагыштан бер сынык капмый үткән көн тәмам хәлне алган. Шулай да иренемә өченче бокалны тидергәндә сугып җибәрүем һәм идәнгә төшеп чәлпәрәмә килгән пыяла тавышы, ишекне шапылдатып, кемнеңдер тузынып чыгып китүе истә калган.

Башым чатнап уянып китсәм, әнкәем хәсрәте искә төшеп, тагын йөрәгем «жу» итеп китте. Керфекләремә гер асканнармыни, ярым йомык күзләремне түшәмгә текәгәч, тагын аптырап калдым: бу ниткән матчалы түшәм... Мин кайда? Ян-ягыма борылсам... Абау, аның шәрә беләкләренә орындым. Нишләдем мин... Нишләттеләр мине... Шул чактагы оятымнан, хурлыгымнан ничек һуштан язмавыма хәзер дә гаҗәпләнәм.

Ишек яңагындагы пальтомны эләктердем дә атылып урамга чыктым һәм, ерткыч тырнагыннан ычкынган җәнлектәй, абына-сөртенә йөгерә башладым. Төштәге сыман, аяклар тартыша, сулышым каба, тамак төпләре әчетә. Кешеләр якаларын күтәргәннәр, йөзләре җитди. Көн салкындыр, күрәсең, ә мин аны үземчә аңлыйм, минем белән нәрсә булганын сизенәләр, шуңа күрә якаларына ышыкланып, миннән йөз чөерәләрдер кебек. Урам аркылы йөгергәндә, чаттагы милиционер бармак янап калды. Светофор кызарган чак булгандыр, мин аны үземчә кабул иттем: юньсез кыз син, каян кайтып килгәнеңне беләм дип янады төсле. Торакка кайтып керүгә, бүлмәдәш кызларым «ах» итеп муеныма сарылды. Кич кунарга кайтмавыма борчылганнардыр, җаныйларым. Ә мин аны үземчә фаразладым: хур булдың, Гөлсемкәем, кеше күзләренә ничек күренерсең, диюләредер инде...

Чынлап та, бу бәхетсезлектән – кыз башына килә торган хәсрәтләрнең иң дәһшәтлесеннән котылу юлы юк бит. Минем бик каты авырып егыласым, үләсем килде. Яланбаштан урамга атылып чыктым, муеным шәрә, аякта бер генә кат ефәк оек. Март азаклары. Кыш белән яз тартыша. Әче җил шәрә муенга сарылып чәнчи, тез башларын умырып чеметә. Түзәм. Шул кирәк миңа. Койма буенда сыза-сыза юкарып калган көрткә иеләм, күшеккән кулларым белән дерелди-дерелди кар йомарлыйм. Башка чак булса, мин аны, әнә, тротуар буйлап ашыга-ашыга ашханәгә баручы классташларыма атып калыр идем. И кызык та булыр иде соң...

Ә хәзер мин аны ашыйм. Бер йомарлыкны ашап бетердем инде, хәзер икенчесен әвәлим. Тагын берне ашап бетерә алсам, чынлап торып чирләрмен төсле. Башым, бөтен тәнем ут янар, үпкәм шешәр, сулышым капланыр. Әгәр дә терелтсәләр... Ой...

Үзе теләп алган чир, үз хәлен үзе белсен, диюче булмады. Больницага илтеп салдылар. Үпкә ишеләргә әллә ни булмаган, ә менә тамак шешкән. Операция вакытында саташтың, диләр. «Әчмим» дип кычкырганмын, докторга кизәнгәнмен, чапаланганмын. Операциядән тавышсыз калдым. «Тавышыгыз тора-бара ачылыр, хәзергә пышылдап кына сөйләшерсез», – диделәр миңа. Юатулары гына дип уйладым мин. Үләм дип гомерлек гариплек алдыммыни инде үземә!

Дөньяның ләззәтләре агу белән бергә укмаша, дия торган иде миңа мәрхүмә әнкәем. Күрәсең, шатлык белән кайгының чиратлашып килүен аңлатуы булгандыр инде. Ә менә миңа, моңа кадәр җил-яңгыр тими иркәдә үскән бердәнбер назлы кыз өстенә, хәсрәте, нәфрәте, чире, югалтуы вулкан атылгандай берьюлы ауды. Шулай итеп сабый чактан килгән хыялымнан – артист булудан өметемне өздем. Өсте-өстенә яуган бу кара кайгылардан котылу чарасы бар һәм ул берәү генә дип карар кылдым мин үземә: үләргә, югалырга, онытылырга!

Дусларым минем нинди хурлыклы уйда йөрүемне сизенмиләр. Моңа чаклы гел көләч, чытлык Гөлсемнең иптәшләреннән читләшеп, дәшми йөрүе олыгаю, җитдилек билгесе, янәсе.

Без узган ел атаклы җырчы Шаляпинның малай чагы узган Әмәт тавына күтәрелгән идек. Йөри торгач, тар тыкрыклар аша шәһәр кырыендагы таулар арасында яткан рельсларга килеп чыктык. Поездлар Урал, Себер якларына шушы юлдан уза.

Менә бүген икенче мәртәбә мин шул рельс кырыенда басып торам. Сәгать сигезенче китте. Тиздән-тиздән Казан–Төмән поезды узарга тиеш. Тирә-як тып-тын... Кеше әсәре күренми. Әһә, светофор ябылды. Әнә мендәр-мендәр ак төтен пошкырып паровоз да якынлаша башлады. Көпчәкләр әйләнә. Аларга ияреп минем баш әйләнә. Йә, ни көтәм соң әле? Барыбер бу дөньяда яшәр хакым юк инде минем. Ярый әле әнкәем исән түгел... Минем хәсрәтемнән нишләр иде икән бичара?! Йә, хуш инде, барлы-юклы гомерем, бәхил булыгыз, мине якын иткән әйбәт кешеләр. Яңакларым буйлап яшь тәгәри. Күз алларым караңгыланып китте, һәм чытырдатып күземне йомам да көпчәкләр астына ыргылам гына дигәндә, гөрселдәү тавышына ачынып кычкырган кеше авазы кушылды. Шул арада кемнеңдер сөякчел кулы җилкәмнән шундый каты эләктереп алды, тилгән тәпиенә капкан чебештәй тыпырчына да алмадым.

– Нәрсә, ата-анаңа моңарчы күрсәткән имгәкләрең аз тоелдымыни, җеннән туган нәрсә...

Мин гарьлегемнән аңа җавап бирү түгел, күтәрелеп карарга да базмадым.

– Тумас борын дөньядан туйган, имеш. Йә, кем кызы син, кайсы урамда торасың?

Мин учым белән йөземне каплап елап җибәрдем. Абзый кеше йомшарып куйды.

– Әй, бала-бала... синең бу эшеңә закон да, шәригать тә кул куймый бит. Рәхәткә чыгара торган әллә нинди юллар барында, шундый җинаятькә баралармыни?

Аның бу шелтәсе миңа әткәйләр бирә торган үгеткә охшап китте. Күңелем йомшарып, мин тагын да сулкылдабрак еларга тотындым.

– Әйдә, туйганчы ела инде алайса, – диде ул. – Җиңелрәк булып китмәсме. Башка төшкән аһ-зарны яшь белән генә җуа торган чагыгыз.

Гомере буена тимер юлда эшләгән Госман абзый белән шулай таныштым. Мин үземнең кояш ягына гына багарга, теләсә нинди җилдән аварга әзер торган кыл сабак кына икәнемне шуның аша аңладым.

Берничә көн мин аларда яшәдем. Госман абзыйның карчыгы Хәбирә әби чирләшкәрәк икән. Вак-төяк эшләрендә аңа булыштым. Комлап-сабынлап идәннәрен юып чыгардым. Әнкәемнән өйрәнгәнчә, кылдай нечкә итеп токмач кистем.

– Эшкә болай кулың ябыша икән, – диде беркөнне абзый миңа. – Болай булгач, тормыш итәрлегең бар, кызым. Артист була алмавыңа бер дә уфтанып йөрмә. Илдә чыпчык үлми. Югарыга карап фикер йөрт, түбәннәргә карап шөкер ит, дигән борынгылар. Кемнең генә кемнәр буласы килми икән. Минем дә менә инженер сыман берәр урындагы нәрсә буласым бик килгәние дә, укулар тимәде. Заманы башка иде. Ә хәзер әнә кырык ишек ачык. Кер дә кит, укы да чык. Артист була алмасаң, әйдә вәләй, берәр конторда хисапчы булып утыр. Анысын да теләмәсәң, агроном бул, җиләк-җимеш арасында гына йөрерсең. Әнә безнең авылның ата ярлысы Гыйльманны гына алыйк. Язга чыгу белән яңа җиткәнче гел балтырган ашы гына ашап торырларые шулар. Син ышан да, мин ышан, ике кызының икесен дә укытучы иткән. Ул итмәгән, хөкүмәт иткән. Кадерен белергә кирәк, кадерен бүгенге рәхәтлекләрнең.

Абзыйның бу сүзләре йөрәккә май булып ятты. Төне буе матур төшләр күреп чыктым.

– Анаң вафат булганга ай тулды дисең инде, кызым, ә? Яңарак чагы шул әле. Мәет чыккан көнне йөрәккә кырык шырпы кадала ди торган иде безгә әнкәй карчык. Кырыгына чаклы шулар берәм-берәм төшә бара, тик кырыгынчысы гына гомер буена шулай кадалган килеш кала икән.

Чынлап та, әнкәем кайгысыннан авырлык белән генә булса да акрынлап айный башлавымны тойдым мин.

Госман абзый саубуллашканда да миңа алтыннан кыйммәтлерәк киңәшләр бирде. Бу акыллы кешенең педагог дәрәҗәсенә күтәрелә алмавы бик кызганыч. «Юлга чыккансың икән, юл кешесенә юл яхшы, атлавыңны бел. Адашсаң, югалып калма, юл сорарга телең бар, карап барыр күзең бар. Шуңа сөен. Аяз көн күтәрсең, күгеңне болыт каплар; яңгыр теләрсең, кояш яндырыр. Сабыр ит. Сабыр иткән морадына җиткән. Син теләгән көннәр алда бихисап. Шуңа куан. Давыл чыгар, өермә кубар, өстеңә ком-таш явар. Түз. Ышыклан. Юлда гына түгел, өйдә дә кашык-аяк шалтырамый тормый. Басылмас давыллар юк. Өстеңне кагын, башыңны күтәр дә юлыңны дәвам ит. Менә шул чакта гына син дөнья күргән, тормышның әчесен-төчесен татыган кеше булырсың. Андый кеше утта да янмый, суда да батмый», – диде ул.

Гөлсем апа кыска гына пауза ясап алды.

– Шулай. Офыкка карагыз әле, нинди матур булып таң ата. Без сөйләшкән арада, болытларның әсәре дә калмаган.

– Кояш комачланып баткач, мин яңгыр көткән идем.

– Бәлки, явар әле. Көн башлана гына. Болытларны өреп таратып булмый, үзләре җыела, үзләре тарала алар.

– Ә менә сез тормыш күгегезгә хәзер үзегез хуҗа.

– Аяз тоеламыни?

– Күзләрегез якты. Сүзләрегез саф. Тавышыгыз аһәңле.

Гөлсем апа кырыс төс алды:

– Кешенең үз бәхетсезлегенә каршы көрәшә алуын һәм аны җиңүен күпләр батырлыкка саный. Ә минемчә, бу бик табигый хәл. Менә шуны аңлаудан мәхрүм кешенең күзен ача алсаң, син шәфкатьле кеше.

– Госман абзыйны искә алуыгызга ышанам.

Ул көрсенеп куйды:

– Пароход Казанда торган арада, мәрхүмнең каберенә чәчәк куеп килдем. Күрәсез, мин аннан гомерлерәк булып чыктым.

– Тагын бер сорау бирергә рөхсәт итсәгез...

– Танышканчы ук сезнең кем икәнегезне сизендем, иптәш журналист. Ә соравыгызны күзләрегез әйтеп тора.

– Сез бик үткен.

– Тормыш, тормыш чарлый кешеләрне. Шуның өстенә «Шәхес» дигән темага гыйльми эш язганым бар. Мәскәү вузларының берсендә кафедра мөдире булып торам. Монысы – җавабым.

– Соңгы сорау...

– Анысын да төшенәм. Ялгыз калдым мин. Хаталарның да кайберләре авыр яра кебек: төзәлсә дә, җөе кала. Очрамадылар түгел, очрадылар. Сорамадылар түгел, сорадылар. Ләкин... үз вөҗданы бар кеше башкалар вөҗданына орынмый. Еллар узып, акыл керә башлагач, мин бар гаепне дә ул егеткә генә аударып ялгызшканлыгымны аңладым. Ялгыз калган ямансу чакларымда, явымлы көнне сызландыра торган иске яра кебек, искә төшкәли ул. Бәлки, ул мине көткәндер, эзләгәндер... Очраклы очрашу, аңны алган шәраб аркасында мәхәббәтемне дә җуйдым, ахры. Менә шул газаплы кичерешләр хакына мин үземә «гомер буена ялгыз кал», дип хөкем кылдым, һәм хәлиткеч вакытларда һәрчак акылыма түгел, йөрәгемә мөрәҗәгать иттем. Ә ул, вөҗданыңа тугрылыклы бул, диде.

Ул арада сискәндергеч әче тавыш белән пароход гудок бирде. Карасак, мин төшәсе пристанема килеп җиткәнмен икән инде.



Яңа ел хикәясен яңа исем белән башлыйбыз.
«Сөембикә»дә Мөнирә Сафинаның дебюты.
Хәер, укучылар өчен бу исем берникадәр таныш та инде.
«Яратам дип әйтә алмадым», «Ай сылуы», «Болыт кызы» китапларының авторы. Хикәяләр, шигырьләр, пьесалар, җыр текстлары, сценарийлар яза.
Арча районы Симетбаш авылында җиде кыз балалы ишле гаиләдә туу, мәктәп елларында ук бик күп язучылар, шагыйрьләр белән аралашу, шигырьләре газеталарда басылу, яшьтәшләреннең «шагыйрә» дип үртәве... Барысы да аны әкренләп иҗат газапларына әзерләгәндер. Сәүдә техникумында укып, озак еллар шул өлкәдә эшләсә дә, ахырдан барыбер җаны хис-кичерешләр, хыял, язмышлар дөньясына ашкынган бит.
Уңышлар телик Мөнирәгә.



Мөнирә САФИНА

КАР БӨРТЕГЕ

(хикәя)

Машинасын туктатып җиргә баскан гына иде Динә, маңгай чәченә кар бөртеге килеп кунды. Ашыкмый гына, мине күрәсезме дигәндәй бөтерелә-бөтерелә, назланып кына килеп урнашты ул аның чәченә. Шунда гына табигатьнең матурлыгын күреп хәйран калды Динә. Күр әле бу гүзәллекне! Моңарчы да шундый зәңгәрсу төстә идеме икән күк йөзе?
Ә нигә ул аны күрмәгән? Әллә бер дә өскә күтәрелеп карамаганмы? Маңгай күзе сукыр булганмы? Югыйсә ап-ак кар өстеннән бер дә сокланмый гына атлап китәр идеме?
Йомшак юрган кебек күпереп яткан карга ничек кереп сеңәсе, битләрен куеп назланасы килмәде икән? Бүген нәрсә үзгәрде соң? Нигә үзгәрде? Маңгай чәченә башка көннәрдә дә кунгандыр бит кар бөртеге? Нигә ул бүген кар бөртеге өчен: «Сулышымның җылысы белән эретмим», – дип хафалана? Кулына бияләй киеп, кар бөртеген нигә тиз генә йомшак кар өстенә салып маташа?

Саф һаваның хуш исеннән башы әйләнгән Динә акрын гына урам буйлап атлады. Күңелендә – давыл, өермә, аның ак күлмәк киеп, ак кар өстендә биисе, әйләнәсе һәм бик тә берәүне күрәсе килә иде. Нәкъ теге чактагы кебек... Аңа ул чакта егерме генә яшь иде шул. Ә хәзер, түгәрәк саннарны тәгәрәтә башлагач, килешмәстер. Динә кире борылды, әмма өйгә керәсе итмәде, якындагы кафега кереп утырырга булды.

Кафеда кеше аз иде. Иң аулак, тыныч почмакта җайлап урнашты да, бер бокал чиста суга заказ биреп, уйларына чумды.

Бүген эштә әллә нинди мәшәкатьле көн булды. Телефонына бер-бер артлы килгән «смс»ларны күрергә дә, укып җавап бирергә дә вакыты булмады Динәнең. Кичке якта гына мөмкинлек чыкты. Арадан берсен ачып укый башлагач, телефоны кулларын пешерде. Егерме ел көткән хәбәр... Соңга калдың шул инде... Соңладың...

Нәкъ шул минутта, хатынының ниләр кичергәнен аңлагандай, ире Нәфис шалтыратты. «Кәефем юк, иртәрәк кайта алмыйсыңмы?» – ди. Авырса, Динәдән башка тора алмый инде, сабый бала кебек көйләтә. Башка вакыт булса, шул минутта ук чыгып китәр иде, бүген өйгә ашкынмый әле хатын. Эшеннән дә соң гына кузгалды, инде кайтып җиткәч тә өйгә керәсе килмичә кафеда утыра. Әнә, тагын шалтырата инде. Алмады Динә, телефон ду килеп боргаланды да туктады. Күрше өстәл артында утыручы яшь пар аңа карап алды да, бер-берсенә сыенышып, үбешә башлады. Үбешегез, әйдә, үбешеп калыгыз... Нигә үртәлә инде Динә? Нәфисе белән үзләре дә үбешми тормыйлар. Үпкәләшеп алганнан соң татуланышканда бигрәк татлы була үбешүләре.

Соңгы вакытта нигәдер күңеле үсми аның, эшенең гөрләп баруы да куандырмый. Беркөнне күргән төшеннән соң үзгәрде ул. Беренче мәхәббәтен оныта алмый аз интектеме, нигә кабат төшкә кереп газапка салырга җыена? Кулларын сузып: «Мине син генә коткара аласың, башка

беркем дә түгел, коткар!» – дип нигә ялвара? Хәзер менә «смс»лар җибәрә башлады. Нәрсәгә өметләнә инде?

Динә укытучы булырга хыяллана иде, хыялын тормышка ашырды, туган мәктәбенә эшкә урнашты, читтән торып укырга керде. Сессиядән кайтуына шәһәрдән яңа укытучы егет килгәнен ишеткән иде инде. Беренче тапкыр күрүдә үк аңа гашыйк булуын сизми дә калды. Динар да аңа гашыйк иде. Мәктәп укучыларына ясаган чыршы бәйрәмендә берсе Кар кызы, икенчесе Кыш бабай булып киенделәр. Кар кызы күлмәген киеп, Кыш бабай каршында бөтерелә-бөтерелә биеде. Ул көн кебек башка көннәр дә әкияттәй матур булыр төсле тоелды. Әмма... Мәхәббәтнең нәкъ бөреләнеп тулган чагында Динәне бер көнне директор үз бүлмәсенә чакырды. Аннан чыкканда кызны танырлык түгел иде. Динарның хатыны, баласы бар икән бит! Ярабби, ничек оят! Барысы да белгән, нигә Динә белмәде бу хакта? Әле ярый «Өйләнәм, бергә булыйк», – дигән сүзләренә ышанып, үзен харап итмәде.

Газап утларында тилмергән Динә шул көнне үк гариза язып эштән китте. Кайтып, тиз генә кирәк-яракларын бер чемоданга тутырды да, әнисе белән саубуллашып, шул көнне үк калага китеп барды. Динар белән очрашасы килми иде кызның, югаласы килә иде. Аны күрсә, гафу итәрмен дигән курку бар иде күңелендә. Берни аңламаган әнисе, күз яшьләрен тыя алмыйча, йөрәк пәрәсен догаларына төреп, юл чатында озатып калды. Китте Динә.

Мәктәпкә барасы килмәде, китапханәгә эшкә урнашты. Монда аның эзләп табу ихтималы юк кебек тоелды, онытырга ансат булыр дип уйлады. Дөрестән дә, биш елдан соң Динарның исеме тоныкланды, әмма сөюенең төсе җуелмады, күңелдәге яра төзәлсә дә, җөе калды. Бусына гына түзәргә була иде, акрынлап Динә дә тормышка әйләнеп кайтты. «Башка беркайчан беркемгә гашыйк булмаска!» – дип, үз-үзенә сүз бирде. Әмма тормышның үз законнары, адәм баласының «суга язылган» вәгъдәләре ул законнар каршында көчсез икәнлеген ул аңламый иде әле.

Китапханә бер заводныкы иде, Динә бер ел эшләгәч, аны ремонтларга әзерләнделәр. Яңа җитәкче әдәбият сөюче икән, китапханәгә үзе килеп, аның нинди хәлдә икәнен күреп китте. Динәнең күңеле күтәрелде, «Кирәкмәс эш белән шөгыльләнмим икән әле. Әнә бит, завод директоры да китаплар ярата икән, язучыларның, шагыйрьләрнең исемнәрен белә!» – дип горурланды. Ремонтка әзерлекне шул көнне үк башлап җибәрде кыз, китаплар, картотекалар, күргәзмә эшләре тартмаларга тутырылды. Хәзер инде завод директорының урынбасары килеп каравын көтәсе генә калды.

Озак көттермичә, икенче көнне үк урынбасар килеп тә җитте. Ул ишекне ачып керүгә, Динәнең күзе аның мәһабәт гәүдәсенә төште. Ирексездән: «Их, шундый ир белән яшәргә!» дигән уй күңелен сызып үтте һәм, үз уеннан үзе оялып, кызның бит урталары кызарып чыкты. Моны урынбасар да күрде.

Күрде дә баскан урынында катып калды. Нинди гүзәллек бу? Нигә монда, иске китаплар арасына яшердегез бу матурлыкны? Кемнән яшердегез? Урынбасар туп-туры Динә янына килде. «Нинди теләкләрегез бар? Әйтегез, сез кушканча эшләрләр», – дип, янында басып торган иргә бер атна эчендә китапханәне өлгертергә кушты. Кызның тавышына, мөлаемлыгына, үз-үзен тотышына сокланган, бер күрүдә гашыйк булган урынбасар китәргә ашыкмады, китапханәне озаклап караган булды. Күрде кыз: урынбасарның китапларда да, китапханәдә дә эше юк, ул күзләрен Динәдән алмый, нидер исәпләгән, караган кыяфәт белән бер яктан икенче якка йөри иде. Төрле сораулар биреп кызны шактый тинтерәткәч, Динәне үзе белән чакырды. «Кая?» – дип аптырап сорады кыз. «Күрерсең!» – диде гашыйк урынбасар. Шунда гына кыз аның ялкынланган күзләрен күреп алды. Аңа рәхәт тә, шул ук вакытта куркыныч та иде. Кая алып бара ул аны? Нигә бер сүз дә дәшми?

Ниһаять, шактый баргач, артык купшы булмаса да, матур итеп төзелгән йорт янында туктадылар. «Төкле аягың белән, Динә!» – диде урынбасар. Каян белгән ул аның исемен? Аныкын белә, ә үзенекен әйтмәде, таныштырмады. Нишләргә җыена? Хезмәтче булырга кушмакчымы әллә? Яшь түгелме соң бу егет, ничек завод директорының урынбасары була алган?

– Менә мин яшәгән йорт. Гафу, гафу, мин үзем белән таныштырмадым бит әле, Нәфис булам, – дип, егет кулын сузгач кына кызның эченә җылы йөгерде.


Йорт эче матур, зәвык белән бизәлгән. Артык әйбер юк, бар да үз урынында. Динә, күзләрен йөгертеп, йорт эчен күзәтеп торган арада, Нәфис зур гына чәчәк бәйләме тотып килеп керде. Бөтен шартын китереп, Динәнең алдында тезләнде, дулкынлануыннан каушап, сүзләрен бутап бетерде һәм кисәк кенә: «Минеке бул, үкенмәссең!» – дип әйтеп салгач, бармакларына көмеш балдак кидерде. Динәнең башы әйләнде, ни дияргә белмәде. Танышканнарына ике генә сәгать бит әле! Ул әкиятләргә, могҗизага ышана торган хыялый бер зат иде, «Могҗиза-а-а-а», – дип пышылдады иреннәре. Шулай да, көмеш балдакның гаилә истәлеге, әбисенең әбисеннән калып, буыннан-буынга тапшырылып килгән ядкарь икәнен белгәч, Нәфиснең җылы куенына кереп сеңде. Мондый балдакны болай гына кидермәсләр, үзе дә ышанычлы ир булыр, мин дә аның ышанычын аклармын дип уйлады. Бер тапкыр авызың пешсә дә, акыл керми икән. «Яратаммы, яратамы, яши алырбызмы?» – дип уйлап та тормады кыз, Нәфискә ышанды. Егеттән ниндидер бер олы хис бөркелә, ышандыра торган көч үзенә буйсындыра иде. Яши торгач, алар икесе дә бу көнне искә алганда рәхәтләнеп көләчәк, Нәфис үзенең кеше таный белү сәләте белән мактаначак һәм: «Миннән дә бәхетле кеше булмас, яратам бит мин сине, карчык!» – дип хатынын кочагына алачак...

Шул җылы куенда еллар сизелми дә үтте. Балалар туды... Хәзер инде Нәфисе – шәһәрнең хөрмәтле һәм дәрәҗәле кешесе. Динә үзе дә төшеп калганнардан түгел, бизнесы гөрли, исеме үзеннән алда йөри. Тагын ни



кирәк? Шатлыгы-мәшәкате белән гомер узып бара икән бит! Бер көнне төш күргәннән соң ул шуны аңлады. Бөтен күңелен әйләндереп салды бу төш. Рәхәттә, хөрмәттә яшәде, яраттымы ул Нәфисне? Әйе, ире бик яхшы кеше булып чыкты, Динәнең хөрмәте зур иренә. Бәс, шулай икән, нигә яшьлеге тынгы бирми? Гомере буе иренә тугры булып, яратып, кадерләп яшәде бит ул. Ә мәхәббәте ни дәрәҗәдә? Ире соңга калып кайтса көнләшмәде, артыннан күзәтмәде, кесәләрен актармады. Ярату, өстендә дулкыннар шаулап торган диңгез кебек, тынычсыз булырга тиеш түгелме соң? Әле дә бер-берсен тикшерүне, телефоннарын актаруны белмиләр. Нәфиснең дә көнләшеп җанына тигәне булмады. Ире артык яратты аны. Әле дә, кайнарланып: «Мин сине беркемгә дә алыштырмыйм!» – дип әйтеп куйган көннәре бик күп.

Динә кафеда телефонын онытып чыккан икән, артыннан официант кыз чыгып җитте. «Мин сезне күптән беләм. Сез бик чибәр ханым, зыялы. Берәр хәл булмагандыр? Борчулы күренәсез», – дип елмайды ул. «Юк, юк, рәхмәт, берни булмады, бераз арылган, сезгә шулай тоелгандыр гына», – дип саубуллашты Динә. Йорт янына кайтып җиткәч, телефоны тагын дулый башлады. «Нәфис! Кайтып җиттем, хәзер керәм!» – дип дәште ул һәм: «Мин әле бу, таныдыңмы?» – дигән тавыштан сискәнеп китте.



Рәсем: Наталья Васильева

Соңыннан үзе дә аптырады Динә, тиз генә үзен кулга алып, Динар белән берни булмагандай сөйләште бит. Ничек эшли алды ул моны? Каян көч тапты? Сөйләште, әмма сүзне иң кирәкле җирендә өзә дә белде. Башка шалтыратмаска, Динәнең барлыгын онытырга кушты. Әмма Динар кабат-кабат шалтыратты. Динә алмагач, ватсап аша фотолар җибәрә башлады. Берсе астына «Кызым белән» дип язып җибәргән. Картайган икән инде Динар. «Өч хатынга өйләндем, берсен дә сине яраткан кебек яратмадым», – дип язган. Кызгану хисе баш калкыттымы – бер-икесенә җавап язды Динә. Ярамаганын, алай эшләргә тиеш булмаганын да аңлый хатын, әмма бармаклары калтырый-калтырый җавап сүзе яза. Теге баштан: «Бер очрашырга иде бит, әллә ничек кенә аерылыштык», «Кайчан, кайда очраша алабыз?», «Кире какма, күпме көттем сине» ише язмалар агыла гына. Карале, мондый хат алу, кайдадыр еракта сине яратучы, синең өчен җан атучы булуын белү дә күңелле икән. Хат алышу күпме дәвам иткән булыр иде, анысы билгесез, шул мәлдә аш бүлмәсенә Нәфис килеп керде. «Динә! Сөйләшүем өзелде, зарядкасы беткән икән, синнән генә шалтыратып алыйм әле», – диде ул. Тораташ катып калган Динә телефонын иренә сузды. Мондый хәлдә калганы юк иде аның, әйтерсең лә җинаять өстендә тотылды! «Йа Раббым! Син мине ничек тиз җәзалыйсың! Мин бит хыянәт итәргә уйламадым да, җавап кына яздым бит. Кичер мине!» – дип бертуктаусыз кабатлады ул, күзен тутырып иренә карарга курыкты. Нәфис тиз генә сөйләште дә, Динәнең битеннән үбеп алып, телефонны кулына тоттырды. Ире күңелле көйгә сызгырып: «Баксига ашарга биреп керәм», – дип чыгып киткәч, хатын, хәле китеп, аңына килә алмый утырды. Нәфис бер тамчы шикләнмәде! Менә нинди бит аның ире! Нинди яхшы, керсез күңелле ир биргән аңа Аллаһы Тәгалә! Кичер Динәне, кичер! Кичер, гөнаһлы итеп калдырма! Урыныннан торып, тәрәзәдән иренең Бакси – гаиләләренә тугры хезмәт иткән дүрт аяклы дусты белән уйнаганын карап торганнан соң, хатын туйганчы елады. Елап туйгач, җиңеләеп киткәндәй булды, күңелендәге хисләр ташкынының тамчысы да калмаганын аңлады. Динәнең бөтен күңелен, йөрәген Нәфисенә булган якынлык хисләре биләп алган иде.

Ваннадан чыкканда Динәнең күңелендә үткәннәрдән бары бер хатирә генә калган иде инде. Хатын, җиңел сулап, телефонындагы әрсез хәбәрләрне, фотоларны, хәбәр җибәрүченең телефон номерын боздырды.

Яшьлек хатирәсен генә сызып ташлый алмас, калыр ул Динәнең күңел почмагында. Әмма бу хатирә башка беркайчан да аның күңелен җылытмас инде. Салкын иде ул, кар бөртеге кебек салкын иде...



Гөлназ
СӘФӘРОВА

**Авылдагы өйнең тәрәзләре –
Әбиемнең зәңгәр күзләре...
«Әбием безне кечкенәдән назлап үстерде, баштан сыйпап, «кызым» диюләре...» – мондый төче сүзләр минем әби турында түгел. Ул безнең иркәләп-иркәләнеп утырырга яратмый, иң беренче булып сугүче, юл күрсәтүче, җир җимертеп эшләүче кеше ул минем Әби.**

УЛ – АЕРЫМ БЕР ДӨНЬЯ...

Я Авылда әби белән төшкән фотоларны социаль челтәрләргә куйгач, күпләр мине авыл кызы дип уйлый. Әбиең кем, кайсы якныкы дип кызыксыналар.

Минем бердәнбер исән әбием – әнинең әнисе Хөсәенова (Сафиуллина) Гөлсинә Зәки кызы Арча районы Кышкар авылында яши. Ә тумышы белән ул – Тукай районы (элеккеге Чаллы) Түбән Суксу авылыннан. 1937 елның 1 маенда әтисе Зәки, әнисе Фатыйма гаиләсендә иң беренче бала булып (әбиемнәр биш бала үскән) дөньяга килгән ул. Зәки бабай сугыш елларында колхоз рәисе булып эшләгән, авыл кешеләрен ким-хур итмәс өчен бөтен көчен куйган. Моны күреп үскән Гөлсинә әбием дә кечкенәдән батыр, эшчән, бөтен өлкәдә беренче булырга омтылган. 1954–1955 елларда Алабуга ветеринария училищесын тәмамлап, бер сүз урысча белмәгән яшь-яшь кыз Сидоровка, Бәдкеише урыс авылларында ветеринар булып эшләгән, русчасын да өйрәнгән, кешеләр белән дә уртак тел тапкан, авырлыклар алдында да баш иеп тормаган. Хәзер дә берәр күңелсез хәл килеп чыкса, «баш ярылып, күз чыкмаган», дип әйтергә ярата. Ул бары тик бер Ходайдан гына курка, аннан гына ярдәм сорый. 1957 елда барысын да Ходай кулына тапшырып, Чаллы хәтле Чаллыдан ул чактагы Әтнә районы Кышкар авылына атаклы Хөсәеновлар гаиләсенә килен булып килеп кергән ул.

«Әби, Илдус бабайны яраттыңмы?» – дип сорый башласам, җәелеп китеп сөйләргә ашыкмый. Яратмаса, шуның кадәр ерактан килеп, аңа кияүгә чыгар идеме, өч бала табар идеме соң? Хәзер генә ул Чаллы–Казан арасы ике-өч сәгатьлек юл, ә әбием ул заманнарда әти-әнисен өзелеп сагынуы, алар янына паромнарда чыгып, пароходлар белән елга бер генә бара алуы хакында күзләре яшьләнеп сөйли.



Менә мин аны нык, сабыр, эшчән дим дә, күз алдыгызга «тимер хатын» килеп басмасын әле. Күңеленең йомшаклыгын, йөрәгенең зурлыгын сөйләп бетерерлек түгел. 40 ел ветеринар булып эшләгән елларын бөтен авыл халкы «Аһ!» итеп яратып, сагынып искә ала. Әби бит әле авылда уздырылучы «Иң чиста-пөхтә йорт», «Иң матур ишегалды» бәйгеләрендә дә гел-гел җиңә килүче. Әле дә йөгерә-йөгерә эшләп йөри, балалары, оныклары кайтышка пешеренә-төшеренә, мунчасын яга. Өйләре гел ялт иткән, тәрәзә төбе саен гөлләр шау чәчәктә, ышанасызмы-юкмы, ул идәннәрен атнасына өч (!!!) юа, кайтышыбызга бер эш калдырмый! Без күпме генә тырышсак та, андый була алмаячакбыз. Әби әйтмешли, «ялкау» без! Әй, үз оныгы бит, мактый, диярсез. Юк, ул андый булмаса, Әби өчен үлеп торыр идемме соң?! Ул минем өчен Әби дә, Әни дә, ул – аерым бер дөнья! Һәм шул дөньяга гел тартылам мин.

Һәр иртәм Әбигә шалтыратудан башлана: «Тордыңмы?» «Бүген нинди эшләрең бар?» «Рульдә телефоннан сөйләшмә...» – менә шундый безнең әңгәмә. Мин зарланам, көндәлек планнарымны, кая барганымны, кайсы җирем авыртканны әйтәм, кайчак аның сәламәтлеге турында да сорарга онытам. Әле нәрсәнедер кабатлап сораса: «Әби, ишетмисеңме инде әллә?!» – дип кыза башлыйм, «Соң, ишетмәм дә инде 82 дә», – дигәч, имәнеп китәм. 82 дә... Ә ул бит минем яшьтәшем кебек, ул бит минем «подружка»! Шул яшендә дөнья яңалыкларын белеп, газета-журналлар укып, акчаны нәрсәгә тотасын, ипотеканың иң уңышлы ставкаларын әйтеп, хөкүмәт программалары белән таныштырып бара бит ул мине. Әле аның яратып әйткән сүзләре ни тора: «Күзеңне акайтып чабып йөрмә» (ашыкма диюе); «Ә минем менә космоска очасым килә!» (мин берәр нәрсә эшлисем килә дип киреләнсәм, ул бу җөмләне котырып әйтә); «КА-БА-ХӘТ» (аның өчен иң яман сүгү сүзе, ачынып, шулай аерып-аерып әйтә); «Идән юу эшмени ул?! Тьфу!» (һәм чын-чынлап төкереп куя).

Әби! Әбием! Беләм, син моны укыячаксың. «Уф! Җүләр, тагын мактаган!» – дип читенсенәчәксең. Синең турында язам дигәч: «Кеше көлдермә, кемдә юк ул әби», – дигән идең. Синдәй Әби юк, валлаһи!

Рәхмәт сиңа биргән тәрбияң өчен: эш сөяргә, җебеп тормаска, куйган максатларга ирешергә, гаилә җылысын сакларга, алга, бары алга барырга син өйрәттең.

...Менә бу атнаны да әби янына кайттык. Соңгы вакытта ул миңа сандыгындагы кәфенлек, яулык-сөлгеләрне күрсәтә башлады. «Кайда нәрсә ятканын белеп, тыңлап тор, дөнья хәлен белеп булмый. Мин үлгәч, елап утырма, өйләр чиста булсын», – ди. Ул бу сүзләрне әйткәндә үкси-үкси кычкырып елыйсым килде. Тешемне кысып түздем. Әйе, беләм, бу дөньяда бернәрсә дә, беркем дә мәңгелек түгел, тик моны кабул итәсе, бу турыда уйлыйсы килми.

Йа Раббым, Әбиемә исәнлек, озын гомерләр бир, ул – миңа, безгә бик кирәк!





Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Язучы Айгөл Әхмәтгалиеваның «Балларда бал тәме» китабын укып чыкканнан соң, аның әниләребез, үрнәк әбиләребез турындагы фикерләре җәлеп итте. «Мин әсәрләремдә Ана образын безнең әбекәйләребез аша ачып бирәм. Әбекәйләребездәге җылылык, дини әхлак тәрбиясе иң күркәм тәрбия бит ул», – дип әйткән иде ул бер тапшыруда. Чынлап та, Айгөл Әхмәтгалиева әсәрләрендәге әбекәйләрнең (әйе, әбиләр генә түгел, ә чын Әбекәйләр!) тормышны ихлас яратулары (нинди генә авыр заман булуына карамастан), балаларын – бәгырь кисәкләре өчен өзелеп торулары, аларга иманлы тәрбия бирүләрен күрергә була. Әсәрне укыганда әбиеңнең сине бик йомшак итеп кочып алуы (тәне коры сөяк белән тирегә генә калса да), кытыршы куллары белән сыйпавының рәхәтлек биргән мизгелләре күз алдына килеп баса. Әти-әнинең гомере күп вакыт эштә үтә, аларга өй мәшәкатьләре өстәлә, баласына теләгән мәхәббәтен, җылылыгын биреп тә җиткерә алмый, ә шушы бушлыкны әбекәйләр тулыландыра! Тирән тамырларыңның кайдан икәнен онытмаучылар да шул әбиләребез икәнен төшенәсең.

Айгөл Әхмәтгалиеваның «Тузганак кергеге» дигән әсәрендә гәүдәләндерелгән әни образы минем бөтен йөрәгемне биләп алды. Быел Бөек Җиңүнең 75 еллыгын билгеләп үткәндә бу әсәр турында кайта-кайта сөйләрләр әле. Сугыш елларында никадәр авырлыклар, михнәт кичергән Анага һәйкәл куярлык әсәр иҗат итә алган язучы.

Ул сугыш нинди генә авырлыклар китермәгән кадерле әбиләребезгә. Ачлык, ялангачлык, коточкыч авыр хезмәт, нахак сүзләр, кадерле кешеңне югалту ачысы, газиз балаларының хәсрәте... Нинди авырлыкларга гына түзмәгән алар. Әсәрне укыганда җан актарыла, күздән яшь ага, аналарның түземлелегенә, киң күңеллелегенә сокланасың.

Айгөл Әхмәтгалиева – үзе дә бик тыйнак, мөлаем ханым. Шуңадырмы, әсәрләрендәге образлары үз әниләребезне күз алдына китереп бастыра. Укыганда мин дә әниемнең яшереп, бер кешегә күрсәтми генә йөрәге белән елаган вакытларын исемә төшердем. Йөрәгә аша гына узган күз яшьләре әниемнең сабырлыгын, якыннарын борчымавын, ихтыяр көченең ныклыгын күрсәткән бит. Күп очракта кызу гамәлләр кылудан да, авыр сүз әйтеп кемнеңдер хәтерен калдырудан да саклаган ул. Әнием арабыздан киткәнгә шактый еллар үтте инде, әмма ул һаман Айгөл Әхмәтгалиева әсәрләрендәгечә «кызым, сабыр бул...» дия сыман. Һәркемне уйландырырлык, гыйбрәтле әсәрләр.

Әниләребезне, әбекәйләребезне бик олылап ачып биргән автор. Айгөл Әхмәтгалиевага иҗат уңышлары теләп, ихлас рәхмәтләремне җиткерәм.

Гөлназ ИСМӘГЫЙЛЕВА.
Казан.



Әти-әниләренең күркәм һөнәрен дәвам итүче кешеләр һәрвакыт соклану уята. Гаиләдәге өлкәннәрнең яратып, күңел биреп башкарган эше эстафета кебек киләсе буынга күчеп баруы куанычлы күренеш. Мөслим районында туып-үскән Лилия Галиеваның да гыйлемгә омтылышы кечкенәдән башлана, чөнки ул шундый гаиләдә тәрбияләнә. Фәрваз белән Лилия Менделеевск шәһәренә 1985 елда киләләр. Фәрваз гомер буе теш табибы булып эшли. Лилияне С. Гассар исемендәге мәдәният сараена директор итеп куялар. Аннан ул район мәдәният бүлеге җитәкчесе, күп еллар Менделеевск районы хакимият башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары,

Аппарат җитәкчесе булып та эшли. Хәзерге көндә «Юность» кинотеатрын җитәкли. Бөтендөнья Татар конгрессының Менделеевск бүлеге җитәкчесе дә әле ул.

Лилия беркайчан да кабинет колы булмады. Районда мәдәният йортларының идәннәрен яңадан җәю, стена-түшәмнәрне ремонтлау, ишекләр алыштыру, суүткәргеч, электр системаларын алмаштыру, клуб биналарын төзекләндерү, кайберләрен яңадан салдыру кебек эшләрне һич иренми оештыра ул. Бәйрәмнәргә чыгышлар әзерләү, клубта концертлар, спектакльләр куярга ярдәм итүләр, үзенең дә сәхнәдә чыгыш ясаулары, сайлау, халык санын исәпкә алу кампанияләрендә катнашу... Нинди генә эшләргә алынмый! Шул ук вакытта зур мәхәббәт кичергән, бала үстергән, улының уңышларын күргән, оныклар тәрбияләү ләззәтен тойган чын хатын-кыз ул. Ире Фәрваз да хатынына һәрвакыт ныклы терәк, ярдәмче булып яшәде, атказанган теш табибы, спорт мастеры булды. Аларга карап сокланмаган кеше юктыр! Менә шундый матур, тынгысыз тормыш белән яшәп ятканда Фәрваз Нурлыгаян улы күптән түгел дөньядан китеп барды, гомере бик иртә өзелде. Шагыйрь Муса Җәлилнең «Янып калсын гомерең маяк булып, / Үзеңнән соң килгән буынга», – дигән юллары Фәрвазның тормыш девизы булды. Инде аның хыялларын улы Илнар, оныклары, газиз тормыш иптәше Лилиясе чынга ашырырга тырыша.

Лилия ханым үзенең зыялылыгы белән, эчкерсез елмаюы, әңгәмәдәшенә игътибарлы булуы белән һәрчак үзенә тартып тора, ул килеп керсә, бүлмәләр нурлана. Әле күптән түгел генә язучы Рабит Батулланың «Кичер мине, әнкәй» әсәре буенча төшерелгән «Инсаф» фильмында катнашкан артист, продюсер, режиссер белән очрашу кичәсен дә уздырды. Бу чара шәһәр халкында, бигрәк тә яшьләр күңелендә озак сакла违ныр дип уйлыйм.

Менә шундый алар Мөслимнәр, шундый ул безнең Лилиябез!

Илгизәр ТИМЕРГАЛИЕВА.
Менделеевск шәһәре.

***Очкыч Мәскәү шәһәреннән күтәрелеп китсә дә,** аэропортта күргәннәремнән әле һаман арына алмый утырам. Шереметьево аэропорты бала елаган тавышка кинәт тынып калгандай булды.* 3-4 яшьләрдәге түп-түгәрәк йөзле, калын кара чәчле малай үкереп елый, кулындагы күкрәк баласын кая куярга белмәгән әнисе ике бала арасында бәргәләнә. Кечкенәсен арбага куеп, олырагын юатмакчы булганда, инде үксеп елап арыган бала берни дәшмәс, аваз салмас булып, аңын югалтты. Ашыгыч ярдәм чакырттык, дару биргәннән соң йоклап киткән баланы урындыкка салып, өстемдәге җылы кофтамны баш очына мендәр итеп куйдым. Әни кешегә 24-25 яшь тирәседер. Ул кечкенә баласын күкрәгенә кысып, ян ыма килеп утырды да кулымны алып, үзенең йөрәк турысына куйды. Аның тагын авырлы икәнен аңладым. Юатыйм дип, русча сүз башлаган идем, аңламый булып чыкты. Төрекмәнчә дәшеп карадым, аны да аңламый. Саф татар телендә аралашып киттек без бу яшь хатын белән! Елый да елый үзе, туктата гына алмыйм бит. Үзбәк кызы икән, кыргыз егетенә кияүгә чыккан. Ош шәһәренә якын бер авылда яшиләр. Ире эш эзләп Мәскәүгә киткән, ул китеп сигез ай үткәч, икенче баласы туган. Ә ирдән бер хат-хәбәр дә килми, югалган дип саныйлар. Аннан бу кызны иренең армиядән генә кайткан энесенә кияүгә биргәннәр. Инде анардан да авыры бар икән. Шушы көннәрдә үз иренең дә исәнлеге турында хәбәр ала яшь хатын. Өйдән балаларын алып, ирен эзләп китә. Шереметьево аэропортында төн кунганнар. Боларны ире килеп таба, үзенең тоткында булганлыгын, хәбәр бирә алмаганлыгын аңлата һәм кире кайтыр юлга җитәрлек акча биреп, калдырып китеп бара. «Минем сезне яшәтерлек мөмкинлегем юк, минем әти-әни сезне какмас, яшәр урыныгыз булыр, ичмаса», – дип аңлаткан ул үз гамәлен. Әйе, ир дә үзенчә хаклыдыр, гаиләсен шулай кайгыртуыдыр, әмма балаларның ни гаебе бар соң? Аларга бит әти кирәк! «Яратышып өйләнешкән идек бит!» – дип зар елый хатын да.

Их, аңламассың бу дөньяны! Чарасызлыктан, акча табу ниятеннән чыгып киткән бу ир үзе дә бәхетсез, алмадай матур хатыны да... И Ходаем, багалма кебек нарасыйларын багып үстерергә сабырлык, көч-куәт бирсәң иде аларга!

Зәйнәп ЯРУЛЛИНА.
Апас районы.

***Менә инде яңа 2020 елга да аяк бастык.** Нинди булыр ул, безгә нинди яңалыклар белән килер – барысын да киләчәк күрсәтер. Ә узган ел безнең өчен бик шатлыклы, гаиләбезнең зур хыялы чынга ашкан ел булган иде.* Хәтеремдә, 2018 елны каршы алган төндә, сәгать телләре уникегә якынлашканда, илләр тыныч, үзебез исән-сау булсак иде, дип сорадым һәм күптән күңелемдә йөрткән хыялымны – «кыз бала сөясем килә», – дип пышылдадым. Могҗизалар әкиятләрдә генә түгел, чынбарлыкта да була икән бит! 2019 елда Аллаһ безгә өченче балабыз – кызыбызны бүләк итте. Шулай итеп, ике улым янына Язгөлемне алып кайттык, күп балалы гаилә статусын алдык. Тормышыбыз янәдән бала мәшәкатьләренә чумды. Ни дисәк тә, яшәү мәгънәсе балаларыбызда бит! Шулай да, тормыш гел шатлык, куанычтан гына да тормый. Узган ел дәү әтиебез Рифат белән хушлашырга туры килде... Дәү әтисе турындагы истәлекләрне хәзер кызыбызга сөйләрбез инде. Нишләтәсең, кемдер килә, кемдер китә, тормыш шулай дәвам итә. Булган бәхетебезне саклап, якын кешеләребезнең кадерен белеп яши алсак иде. Бу ел бары тик шатлыккуанычлар гына китерсен!

Ләйсән САТТАРОВА.
Кайбыч районы.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA

ҮЗ БӘЯСЕН БЕЛГӘН ХАТЫН-КЫЗ КӨЧЛЕ УЛ...



Фото: Анна Арахамия

Яратышып яшәгән икәүнең арасы көннәрдән бер көнне шартлап өзелә. Карашлары төрле булганга, диләр. Ләкин тормыш диңгезендәге айсбергның өсте генә түгел микән бу? Төптә бит бөтенләй башка сәбәп... Һәм ул, күп вакыт, өченче бер кешегә килеп тоташа. Арага ятлар керү мәхәббәтне үтерә шул... «Йөрәктәге яралар да төзәлә, гафу да итәсең, тик ярату юк икән, аны кире кабул итә алмыйсың», – ди «Болгар радиосы» алып баручысы Дилбәр ФӘИЗ. Аерылышуларына аны гаепләүчеләр барын белде ул. Белде һәм эндәшмәде. Нигә? Ачыктан-ачык сөйләшәбез.

Театр училищесының икенче курсында укыганда безнең төркемгә килеп кушылды ул. Без – бала-чагалардан күпкә олырак, тормыш тәҗрибәсе туплаган чибәр ир-ат. Озак та үтми концертлар белән Минзәләгә җибәрделәр. Ул заманнарда шулай студент чактан ук гастрольләргә йөри идек. Концерт алдыннан аяк киемемнең каешы өзелде. Ул аны миңа ясап бирде. Шул көннән башлап һәрвакыт бергә булдык дисәм, бер дә ялган булмас. Гел җитәкләшеп кенә йөри идек. Өченче сыйныфтан өйдән чыгып киткән кеше мин. Интернатта яшәп укыдым. Әти-әнине күрмәдем дә диярлек. Шуңа күрә ул минем өчен әти дә, абый да, ир кеше дә булды бугай. 19 яшемдә мин инде кияүгә чыктым. Нигәдер булачак иремне әти кабул итеп бетерә алмады, тик минем сайлавыма каршы төшмәде. Училищены тәмамлагач, яшьләр театрында эшли башладык. Без – ул театрга нигез салучылар. Бик күп рольләрне бергә уйнадык. Төрле образлар тудырдым. Театрның тормыш өчен ярдәме зур булды. Шуның өчен мең рәхмәт аңа. Соңрак бергәләп башка театрга күчтек. Анда ир-ат актерларга кытлык булгач, аны алдылар, ә миңа урын табылмады. Соңрак алабыз, диделәр. Без яшь гаилә: кечкенә бала, акча җитми, мохтаҗлыкта яшибез. Театрга администратор булып эшкә урнаштым. Әле һаман да алабыз дигән сүзгә ышанып яшим бит инде. Кулыма кечкенә баламны күтәреп, кичкә эшкә киләм. Әтисе уйнамаган көннәрдә бала аның белән кала. Аннан соң залда билетер булып та эшләдем. Тик вәгъдә ителгән урын булмады миңа. Шул театрда эшләгән артистларның балаларын алдылар. Шулай итеп, бу театр сәхнәсендә уйный алмый калдым. Филармониягә алып баручы итеп чакырдылар. Яшәргә кирәк – барып урнаштым. Анда инде бертуктаусыз гастрольләр... Кемнәр белән генә эшләмәдем, кайда гына бармадык. Кызым әтисе белән кала иде. Арабызда көнләшү дигән хис бөтенләй юк. Бу уңайдан бернинди сүзгә килешү, үпкәләүләр булмады. Мин – аңа, ул миңа ышандык. Аннан соң ирем белән икәүләп бер бабайга укырга йөрдек, вәгазьләр тыңладык, дин сабаклары өйрәндек. Икәү бергә намаз укый башладык. Ул елларда дингә тартылу башланган иде. Шул шаукымга ияргәнбездер дип уйлыйм. Нәрсә этәргәнен әле дә аңламыйм. Ул чакта мин ир артында гына яшәгән, бер сүз әйтсәләр дә елап җибәрә торган бер җебек яшь хатын идем. Ул дин юлына баскач, мин дә аның артыннан ияргәнмендер инде. Тик бу адымга чын күңелемнән ышанып, әзер булып бардым. Ул – бик гыйлемле кеше. Нәрсәгә тотынса да, җиренә җиткереп эшли. Хәтере дә яхшы, тиз ятлый да иде. Кызыбыз да кечкенәдән үк намаз укып үсте. Һаман да шулай кулга-кул тотынышып, бер-беребезне ярты сүздән аңлап яшәдек. Мин зур конкурс аша үтеп, «Дулкын» радиосында эшли башладым, ә ул театрдан дини оешмага күчте. Дин сабаклары укыта башлады. Әледән-әле чит илләргә

> Миннән җиде яшькә өлкән булгач, аны яклаучым итеп тойдым. Бәлки, аннан ата назы эзләгәнмендер.

белемен арттырырга йөрде. Бик соң кайткан чаклары булды. Үземнең уйларым чиста булгач, бер шигем юк иде. Хыянәт итми микән дигән уй күңелемә килеп тә карамады.

Аның чит илгә укырга барып кайткан вакыты иде. Өй телефонына туктаусыз шалтырата башладылар. Трубканы алсам, эндәшмиләр. Кем икән дип аптырап беттек. Ул вакытта радиода каршылыклы фикерләр яңгыраган тапшыру эшләгән идем. (Шуның аркасында эштән дә кудылар әле мине.) Әллә шулай тикшерәләр микән дип тә уйладым.

«Мине шантажлыйлар», – ди бер көнне ирем. Сораштыра башлагач: «Сиңа кирәк түгел», – диде. Кабат телефон шалтырады. Монысында эндәштеләр: «Мин – ирегезнең хатыны», – дип таныштырды үзен телефонның теге очындагы ханым. «Ярый, әйдә, килегез, сөйләшик», – дидем. 15 минуттан ул безнең өйдә минем каршыда утыра иде инде. Баксаң, алар дин дәресләрендә танышканнар. Очраша башлаганнар да никах укытканнар. Андый очрашулар бер ялкыта шул. «Ул миңа талак әйтте. Китапта беркая да язылмаган. Аның талагы дөрес түгел», – дип зар елый бу ханым. Гадәттә, мондый вакытта хатын-кызлар истерикага бирелә. Ә минем минут эчендә күңелем катты да калды. Ул мескен хатынны тыңлап утырдым-утырдым да, иремә: «Әйдә, өч көн – анда, өч көн миндә яшә, ә бер көнеңне теләсә кайда яшә», – дидем. Ә ул талак әйткән хатынын күрергә дә, ишетергә дә теләми, аны куа. Шулай дип әйтсәм дә, күңелгә салынган яраны тиз арада дәвалап булмады. Бераз уйлап йөргәннән соң: «Болай яши алмыйм, аерылышыйк», – дидем. Ул, ялгышканмын дип, гафулар сорады, гаиләмне ташларга теләмим диде. Тик күңелемдә аңа карата бернинди хис калмаган иде инде... 12 ел бергә яшәгәннән соң, без аерылыштык. Аерылышуыбызда мине гаепле итеп калдырдылар. Имеш, намазга басмаганмын, башыма яулык япмаганмын. Кыскасы, дини кануннар буенча яшәргә теләмәгәнмен. Ләкин бу – нахак. Әйе, яулык япмадым, хәзер дә яулыксыз йөрим. Тик моңа карап кына гөнаһ кыламмы? Аллаһыга ышану ул кешенең күңел түрендә булсын. Дин бит ул иң элек үзең өчен. Син калыпларыңны беләсең, әмма бу хакта кычкырып йөрмисең.

Ул вакытта нәрсәдер раслап йөрергә теләмәдем. Бу хакта уйланмадым да, уйланырга теләгем дә, вакытым да булмады. Яшәргә кирәк иде бит. Бик үзгәртте мине аерылышу, бик. Эшкә чумдым. Ат урынына эшләдем. Һәрвакыт кеше арасында булдым. Шуның белән җиңдем дә бугай. Аннан соң,

Кача-поса кеше ире белән никах укытырга риза булган хатыннарны җәллим дә, шаклар да катам.

күрәсең, мәхәббәтем көчле булмагандыр дип уйлыйм. Бөтен барлыгым, назым, дәртем белән сөймәгәнмендер, яраткан булсам, кире кабул итәр идем. Яраткан хатыннар хыянәт иткән ирләрен кичереп, кире кабул итә, әле аның өчен чәче белән җир себерергә әзер булып яши. Шундый бик күп парларны беләм. Икенчегә китсә дә, иреннән башын алмаган хатыннар да бар. Ярата икән, хатын-кыз кала ул! Ә мин гафу иттем, тик калмадым...

Аерылышу ир өчен дә, хатын өчен дә авыр түгел. Әмма иң зур яра – бала күңелендә кала. Кызым бик авыр кичерде. Иң авыры аңа булды. Аннан соң, аерылышасың икән, араларны шартлатып өзәргә кирәк дип уйлыйм хәзер. Читтәге ата белән аралаштыру баланың күңелен генә яралый. Әтисенең яңа хатынын, балаларын җиңел генә кабул итә алмый ул үсмер күңеле.

Аерылганда 33 яшь иде миңа. Хатын-кызның чәчәк кебек янып торган вакыты. Кияүгә чыкмый калуым да балам хакына. Бик күп сөйлиләр, язалар: үги ата үги кызын көчләгән, дип. Иң курыкканым шул булды. Бөтен мәхәббәтемне балама бирдем, һәм моның өчен тамчы да үкенмим. Тормышымны ялгызым дәвам иттем. Үземә ир дә, хатын да булырга туры килде. Авылга кайтканда, һаман кешегә утыртып алып кайтыгыз әле дип ялынмас өчен руль артына утырдым. Ул вакытта хатын-кызлар машина йөртергә курка иде әле. Бик тиз өйрәндем. Тормыш өйрәтә икән ул. Җебек хатыннан – янган йортка барып кергән, чабып барган атны туктага торган хатынга әйләндем. Яшәү өчен тырышу дигән нәрсә бу! Син бит мондый түгел идең, дип аптырады күпләр ул вакытта. Бөтен уем – тормышны алып бару. Ә акчасыз көн итеп булмый. Тормышта балык кебек йөзәргә, киреләнмәскә, юк дип әйтмәскә, тәкәбберләнмәскә Хәния апа Фәрхи өйрәтте. Урыны җәннәттә булсын, бик зирәк кеше иде. Мин бит әле интернатта яшәгән кеше, кечкенәдән мөстәкыйль булып үскәннәр тормышта нык булалар.

Ә теге хатынга ачу-үпкә саклыйсыңмы дип сорыйсың килә инде синең... Юк, үпкәләмим. Җәлләдем мин аны. Никах укыткач, ул аны хатыным дип кабул итәргә тиеш булгандыр. Ә аны файдаландылар да ташладылар. Бу бит инде гаилә бозу! Әйе, чит илләрдә күп хатынлылык бар. Ләкин анда да ул бетеп килә. Бездә бит ир-ат икенче хатынга өйләнә икән, бу адымга ул бары бер нәрсә турында гына уйлап бара. Андый ир-атлар ике хатынын да тулаем тигез тәэмин итә ала дип уйламыйм. Мәсәлән, өйләнә икән, икенче хатынын да тораклы итәргә тиеш. Ике хатынына да фатирлар алып бирсен. Ә бездә бит өйләнә икән, хатынының өенә барып йөри. Гәрчә, аның өе булмаса да. Дини каннуннар буенча, олы хатынының ризалыгын алырга тиеш. Дөрес, бездә ул кануннарны үзгәртеп торалар. Качып-посып никах укытуның бөтен максаты шул йоклауга кайтып кала. Никах минем өчен – иң изге әйбер, ЗАГСка барып мөһер сuктырудан да зуррак дип уйлыйм мин аны. Шуңа күрә никах белән сату-алу итүне кабул итә алмыйм. Алай булырга тиеш түгел ул. Аңлыйм, ялгыз хатынга наз, игътибар җитми. Үзен бәяли белмәгәннәр тәмле телгә, өч минутлык назга, ике-өч мең сумлык бүләккә алданып ышаналар да икенче, өченче хатынлыкка да риза булалардыр. Хатын-кыз үз кадерен белмичә югалып кала микән әллә? Тормыш алып барырга ярдәм итәр дип өметләнәләрдер, мөгаен. Ирләр кебек, дәрт белән генә эш итмиләрдер дип уйлыйм. Хатын-кыз уйламыйча бер адым да ясамый ул. Ирләре йөргән хатыннарга шуны әйтер идем: бер йөргәне гомер буе йөри инде аның. Яратасың икән, түзеп яшисең, әмма үзеңнең дә кеше икәнеңне онытырга ярамый. Акылга утыртам дип яшәү дә дөрес түгел. Кешене үзгәртеп булмый ул. Бигрәк тә ир-атларны. Тагын шунысын да онытмаска кирәк: ир-ат югалып калырга мөмкин әле, ә хатын-кыз бервакытта да югалмый ул. Ирләргә ялгыз яшәве авыр – ашарга пешерүче, иднен юучы, өен җыештыручы кирәк. Аерылышканда тикмәгә генә бала ана белән калмыйдыр инде ул. Бу күп нәрсә хакында сөйли.

Хатын-кыз ир-атка караганда тәвәккәлрәк тә бит әле ул. Курыкса да, уйлаганын эшләми калмый. Ә ирләрдә андый нәрсә юк. Ул уйлап йөргән була, аны төрткәләп торырга, илһамландырырга кирәк. Аннан, ир чын ир-ат икән, барысын да уртага салып сөйләшсен. Нәрсәдән канәгать булмавын әйтсен. Уртак тормышыбызның киләчәге юк, гафу ит, мин башка хатын алам дисен, ә качып-посып башка хатын-кызлар белән чуалып, никах укытып йөрмәсен. Бу инде егетлек түгел.

Аның хыянәтендә үземнең дә гаебем бардыр. Мин – яшь-яшь кыз, ул – тәҗрибәле ир-ат. Бәлки, башны югалтып яратышу кирәк булгандыр. Тик йөргән ирне моның белән генә тыеп буламы икән? Алтыдагы – алтмышка дип тикмәгә әйтмәгәннәр. Юк, кемне дә булса һич гаеплисем килми. Аллаһы Тәгалә шулай язган, димәк. Бар нәрсәм җитеш, гаиләм бар. Ул да бәхетле яшәсен. Баламның әтисе бит ул.

Еллар үтеп, хәзер үзем дә дәү әни яшенә кергәч, ата-ана сүзенә колак салырга кирәк икән дип уйлыйм. Гомер тәҗрибәсе булган өлкәннәр кешене сизми-белми калмый шул. Гаиләдәге хәлләремне кайтып сөйләгәч, әти: «Менә, кызым», – диде дә, башка бер сүз әйтмәде.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

«ТАТАР ҖЫРЫ» ЮБИЛЕЕНДА...

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

«Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә узган «Татар җыры» Халыкара эстрада фестиваленең 20 еллык юбилеен Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ачып җибәрде. Ул әлеге әһәмиятле проектны оештыручыларга рәхмәтен җиткереп, дәүләт бүләкләре тапшырды. Фестивальнең генераль партнеры «Татнефть» ААҖ профсоюз комитеты рәисе Гомәр Яруллин оештыручы һәм тамашачыларның һәммәсен җыр бәйрәме юбилее белән тәбрикләде. Татар эстрадасы йолдызлары Салават, Айдар Галимов, Зәйнәб Фәрхетдинова, Гүзәл Уразова, Филүс Каһиров, Эльмира Кәлимуллина, Ришат Төхвәтуллин бәйрәм сәхнәсендә соңгы елларның иң популяр хитларын башкарды. Арабыздан киткән җырчылар Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Әлфис Кыямов, Хәния Фәрхи, Вәсилә Фәттаховаларны искә алу мизгелләре исә аеруча тәэсирле булды.

«Татар җыры» фестивален һәр елдагыча меңнәрләгән кеше ТатМузТВ каналыннан туры трансляциядә карады.

Партнерлар: Генераль партнер «Татнефть» компаниясе, рәсми партнер «ЕлАЗ» Алабуга автомобиль заводы, автопартнер «Мерседес-Бенц» автомобильләренең рәсми дилеры «КАН Авто компанияләр төркеме», «Кукмара металл савыт-саба заводы» ААҖ, «Камский коммерческий банк», «Фармленд» даруханәләр челтәре, «Изумруд» ювелир кибетләр челтәре, «Россельхозбанк» ААҖнең Татарстандагы төбәкара филиалы, «Югория» иминият компанияләр төркеме АҖ, «Алмаз» ВИП бизнес-сувенирлар» җитештерүче зәркән оешмасы, «Туган авылым» милли комплексы.

Турыдан-туры трансляциянең Генераль партнеры – «Савин хаус» торак комплексы.

Фото: Давид Аветисян





АМЕРИКА



Роза
ДИНМӨХӘММӘТОВА

Ниһаять, күптәнге хыялым чынга ашты – Американы күрдем! Моңарчы дөньяның күп кенә илләрендә булсам да, океан артына ук барып җитмәвемнең сәбәбе гади: андагы тормышны автобус тәрәзәсеннән генә карыйсым килмәде. Инглизчәне Таиланд, Мисыр, Төркия кебек илләрдә яхшы аралашырлык белсәм дә, экскурсияләрне аңларга ук көчем җитмәячәк. Миңа юлдаш – тылмач кирәк иде! Кызым Айсылуга рәхмәт: 3 һәм 1,5 яшьлек ике улы белән үзе генә калса да, ире Адельне минем белән ерак юлга чыгарып җибәрде. (Бизнесымны да үз өстенә алып калды әле!) Безгә Айсылуның дус кызы Миләүшә дә кушылды. Ул – өлкәннәргә инглиз теле өйрәтүче фирманың хуҗасы, инглиз теле буенча аспирантура тәмамлаган. Кызым АКШта берничә тапкыр булды: башта студент вакытта Work and Travel программасы буенча, соңрак – Америка фирмасында эшләгәндә, берничә тапкыр – командировкада... Шуңа күрә сәяхәтнең башыннан ахырына кадәр аның киңәшләренә таяндык. Безгә Сан-Францискода инде 13 ел яшәп ятучы дус хатыным Фәүзия дә килеп кушылды.

Виза алу

АКШ белән Россия арасы суынганнан соң, Америкага виза алу авырлашты. Гаризаны интернеттан июнь башында ук җибәргән идек. Ләкин интервью узу өчен АКШның Мәскәүдәге илчелегенә эләгеп булмады: түләүле виза үзәге безне Екатеринбургка чиратка язды. Визаны өч елга бирделәр. Ә менә Миләүшә визаны Казакъстанга, Нурсолтан шәһәренә барып алды. Анда чират юк икән, тик визаны никтер өч айга гына биргәннәр.

Бару

Иң арзанлы билетларны Төркия һава юллары авиакомпаниясендә таптык: бару-кайту – 33 мең сум. Истанбулга кадәр 4 сәгать очтык, аннары 7 сәгать Нью-Йоркка очучы самолетны көттек. Кабат-кабат тикшерү узып, ниһаять, 450 урынлы зур очкычка кереп утырдык. Юл озын – 11 сәгать тоташ күктә булачакбыз... Әмма ни гаҗәп, юлның авырлыгын тоймадык. Берничә тапкыр ашап, йоклап алдык – шулай узды да китте ул. Нью-Йоркта паспорт тикшерүе үтүнең бер читенлеге дә булмады. Таможняда махсус автомат тора, шуңа үзең турындагы мәгълүматны кертәсең, паспортны сканерга куясың. Һәм син – Америка җирендә!

Караңгы төшеп килә. Алай да метроны тиз эзләп таптык. Нью-Йорк метросы турында күп ишеткән, укыган бар – мактамыйлар. Безгә дә ул караңгы, тәбәнәк булып күренде. Киявебез Адель – IT-белгеч: аның смартфонында бөтен кирәкле һәм уңайлы өстәмәләр дә бар. Шуңа күрә метродан чыгуга җәяү генә туп-туры үзебез алдан броньлаган апартаментка (фатирга) киттек.

Бераз яңгыр сибәләп тора. Тротуарларда чүп капчыклары өелгән, урамнар караңгы... Барып җиткәнче хәйран чыландык. Фәүзия безне беренче катка ук төшеп каршы алды: ул алданрак килеп урнашкан иде инде.

Фатирыбыз ике йокы бүлмәсе һәм кунак бүлмәсеннән гыйбарәт.

Америкага аяк баскан һәркем Ниагара шарлавыгын күрергә тиеш!
Канада ягыннан ул тагын да матуррак күренә, диләр.

Җиһазлары шактый иске, үзе караңгырак – ошап бетмәде. Әмма «бер кичкә – кер мичкә» диләрме әле? Нью-Йоркта яхшырак торак бик кыйммәт, бер көнгә 280 доллардан башлана, шулай булгач, түзәрбез.

Урамга чыгып, якындагы беренче очраган пиццериядән пицца, ипи, эчәргә су, йомырка, сыер мае, сөт алдык. Татар сөтле чәйсез торамы соң?! Кичке ашны фатирда гына ашадык. Америкада һәр фатирда плитә, кофе машинасы бар. Ә менә чәйнек юк – суны чүмечтә кайнаттык.

Иртәнге ашны да фатирда гына ашадык: кыздырылган йомырка, ипи, май. Үсемлек мае суыткычта бар иде, анысын кемдер калдырган. Үзебез белән Казаннан чикләвек, чәй, күрәгә, каһвә, карабодай ярмасы алган идек. Ашамлыкларны соңыннан арендага алган машинага төяп, үзебез белән шәһәрдән шәһәргә алып бардык – барысының да кирәге чыкты.

Нью-Йорк

Америкадагы иң беренче, иң кызыклы көнебез башланды! Фатирыбыз Нью-Йоркның атаклы Үзәк паркына якын урнашкан иде. Иң элек шуны карарга булдык. Чын урманны хәтерләтә ул: агачлар куе, биек... Табигать белән күзгә-күз очрашу тәэсире тудыра: рәхәт... Аннан җәяү генә Нью-Йоркның гына түгел, бөтен Кушма Штатларның символы саналган Таймс-сквер мәйданына киттек. Аны фоторәсемнәрдә күрмәгән кеше юктыр. Бөтен җиренә реклама щитлары урнаштырылган дип уйлый идем. Баксаң, тугызар катлы йорт биеклегендәге зур экраннар икән болар! Искиткеч яхшы сыйфатлы! Таймс-сквер кичен матур: төсләр, йөзләр уйный... Рекламага төшкән артистлар – барысы да йолдызлар.

Киләсе тукталыш – Трамп-Тауэр. 58 катлы «небоскреб»! Трампның аны ничек төзүе турында китап укыган идем. Чыннан да, бик матур, бай, зиннәтле икән: эчтән дә, тыштан да. Чын сәнгать әсәре кебек күренгән кызыл, сары-коңгырт төстәге мәрмәр бу ташларны Трамп үзе сайлаган. Бер-берсен кабатламаган бизәкләрнең андагы матурлыгы! Инде тамак ялгап алсак та була... Утырып, тәмләп ашый торган җир табу бик ансат түгел Нью-Йоркта: алар үзләре гел аягөсли, тиз-тиз капкалап алырга күнеккән: адым саен фаст-фуд саталар. (Җаныбыз теләгәнне таптык анысы, тик тәме генә әллә ни булмады. Бер кешегә 30–40 доллар тирәсе түләдек.)

Азатлык статуясын күрергә барабыз! Көн матур. Юл буйлап ким дигәндә кырыгышар катлы йортлар тезелгән. Гарәп Әмирлекләреннән аермалы буларак, аларның һәрберсенең үз тарихы бар. (Нью-Йоркны тоташ таш кала дип уйламагыз тагын – агачлар, яшеллек тә күп монда. Хәтта йорт түбәләрендә дә үсәләр! Әмма биек биналар арасында күмелеп, югалып калалар.) Башта – автобуста, аннан утрауның үзенә кадәр паромда бардык. Статуяны 1876 елда, ике ил арасындагы дуслык билгесе итеп, Франция Америкага бүләк итә. Дөрес, тарихның бу өлеше инде күптән онытылган, монумент бүген Америка халкының азатлык символы булып санала. Эчкә һәркемне аерым тикшереп кертәләр – статуяны террористлардан саклыйлар.

Вашингтон

Американың башкаласы күбрәк курорт шәһәренә охшаган. Бөтен дөньясы яшеллеккә күмелгән: шәһәр түгел парк диярсең! Пыяла һәм бетоннан төзелгән яңа биналар Нью-Йорктагы «небоскреб»ларны хәтерләтә, әмма биеклекләре 12 кат тирәсеннән узмый. Авиация һәм космонавтика музеен карарга ниятләп килгән идек. Вашингтонның барлык музейлары кебек ул да бушлай, машина куйган өчен 15 доллар гына түләдек. Шәһәр читендә үк урнашкан икән, ачылышына – сәгать тугызга ук бардык. Шунда ук экскурсия башланды: рус телендә юк, билгеле. Миңа аны Миләүшә тәрҗемә итте. Нинди генә самолет моделе юк монда! Күбесе, әлбәттә, хәрби самолетлар. Нишләтәсең, кешелек тарихы авиация барлыкка килгәннән бирле сугыша да сугыша... Беренче «фанер» очкычларны да күрдек. Свастика ясалган фашист самолетларын да. Япон шәһәре Хиросимага атом бомбасы ташлаган самолетны да. Дөньяда иң тиз самолет саналучы Blackbeard та бар монда. Миңа ул күбрәк машинага охшаган кебек тоелды. Пассажир самолетларыннан французларның «Конкорд»ы истә калды. Аннан кичкә кадәр ишекләре ябылганчы Сәнгать музеенда йөрдек: Леонардо да Винчи, Дега, Ренуар картиналары алдында басып тордык. Музейдан чыкканда аяк табаннары яна иде: Америкада булганда көн саен ким дигәндә 15 чакрым җәяү йөрелде... Машинабызны кичке дүрттән иртәнге тугызга кадәр өй янында бушлай куярга була дип аңлаган



■ 70 катлы Рокфеллер үзәгенә җиткәч исә, бу биек бинаның иң югары ноктасына күтәрелергә уйладык. Кошлар очар биеклектән шәһәр өстенә карап тору гаҗәп икән! Кай якка күз салсаң да – «небоскреб»лар тезелгән. Берсе икенчесен кабатламый...

Автор фотолары

Америкада юан кешеләр күбрәк, кибетләрендә S, SX, M үлчәмле кием-салым табам димә.





■ Авиация һәм космонавтика музеена күбрәк космонавтика тарихы белән танышу өчен килдек. Җирнең иярченнәрен күреп шаккаттым: алар зурдыр дип уйлый идем моңарчы. Баксаң, нибары урындык кадәр генә икән! Астронавтларның фотолары очрамады. Безнең Гагарин да юк...

идек, ялгышканбыз. 30 доллар штраф түләргә туры килде. Иртән чемоданнарыбызны тутырып, кабат юлга кузгалдык – моннан Филадельфиягә кадәр якынча ике сәгать ярым барасы.

Филадельфия

Американың беренче башкаласы булган бу кала бездәге шәһәрләрдән аерылып тормый дисәң дә була. Йортлардан алда заводлар каршы алды, димәк, сәнәгать шәһәре бу. Кара тәнле кешеләр бик күп – халыкның 20 процент тирәсе, диделәр. Арада шундый чибәрләре очрый – карап туйгысыз. Ә чәчләрен ничек кенә ясамыйлар! Кайсыдыр бөдрә чәчен турайткан, аны ачык җирән төскә буяган... Юан кешеләр дә нәкъ менә алар арасында күбрәк. Бик юаннар! (Америкада кытайлар да бик күп, әмма ялгыш та таза бер кытайны күрмәдем.)

Филадельфия урамнарында туристлар өчен кызыл таштан сукмак салынган: шулар сине шәһәрнең тарихи урыннарына алып бара. Колокол музеена кердек. Американың Бөекбританиядән бәйсезлеккә ирешүе турындагы Декларациягә кул куелганнан соң, халыкның рухын күтәрү өчен чаң суккан колокол аерым павильонда урнаштырылган. Авырлыгы – 943 килограмм, киңлеге 3,7, биеклеге 1 метр булган зур колокол ул. Бераз чатнаган. (1846 елны Джордж Вашингтонның туган көне хөрмәтенә берөзлексез берничә көн какканнан соң чатный ул. Хәзер аның чыңын елга бер тапкыр, 4 июль көнне көндезге сәгать икедә генә ишетергә була: 1776 елда бу көнне Декларациягә 13 штат кул куя – шуңа күрә колоколга нәкъ унөч тапкыр сугалар.) Декларациягә кул куелган бинада булдык, аның төп нөсхәсен дә күрдек. Декларацияне дөньяның бөтен телләренә дә диярлек тәрҗемә иткәннәр, рус телендәгесе дә бар.

Ниагара шарлавыгы

Юлыбыз – төньякка. Ниагара шарлавыгына кадәр җиде сәгать барасы. Заправкага кереп чыктык: 87 нче сортлы бензинның бәясе 0,85 доллар, ягъни 49 сум тирәсе. Ә юллар... юллар безне шаккаттырды. Беренчедән, алар шундый итеп салынган – машина йөртүче бернichек тә каршыга килүче транспорт белән бәрелешә алмый. Хәтта теләгән очракта да! Уртада – бер юл киңлеге буш ара, анда чокыр казылган. Юл читендәге үләннәр чабылган. Америка агачлар каплаган калкулыклардан гына тора кебек. Юл читендә сирәк кенә йортлар күренеп кала. Бер, ике, өч... Кайда яши икән соң болар бөтенесе? Кукуруз кырыннан кала, башка басу да очрамады. Өй тирәләрендә дә бакча-мазар күренми: газон чәчкәннәр дә – шуның белән шул. Йортлар каркастан төзелгән, бик сирәге генә кирпечкә охшаган плитка белән тышланган. Күбесенчә беркатлы яки мансардалылар. Кыскасы, бик арзанлы йортлар. Октябрь ае иде бу. Урамда – алтын көз. Агачлар нинди генә төскә кермәгән! Нью-Йорк–Ниагара-Фоллс юлын шулай хәтерләп калдым... Буффало шәһәрендә каһвә эчәргә, ашап алырга туктадык. Каһвәләре нигәдер тәмле түгел... Гомумән, ризыкларының тәме юк. Без күнекмәгәнгә шулай тоеламы соң, белмим. Тавык ите сорасаң, гел түш җирен генә китерәләр. Аякларын кая куялардыр аның? Шоколадлары бездәгедән ике тап-



■ Ниагара шарлавыгы элек туристлар өчен ябык була, аны электр энергиясе алу өчен генә кулланалар. XX гасыр башында бар да үзгәрә, гидро-электростанциянең инде аның кадәр кирәге калмый. Җәмәгатьчелек соравы буенча, 1920 нче елларда шарлавыктан плотинаны алалар. Төньяк Америкадагы бу иң зур шарлавыкны карарга хәзер ел саен 12 миллион турист килә.

кыр баллырак. Отельдә, мәсәлән, бушлай капучино эчәргә була иде, мин аны йота да алмадым – артык баллы. Башка бик күп ризыклары да чамасыз баллы тоелды.

Ниагара-Фоллс шәһәренә караңгы төшкәч кенә барып җиттек. Без тукталган коттеджның хуҗабикәсе Украинадан булып чыкты. Искерәк булса да, зур, иркен, чиста йорт. Нью-Йорктагы фатирдан соң монысы патша сарае кебек булып күренде...

Яшеллеккә күмелеп утыручы җыйнак кына кечкенә шәһәр икән Ниагара-Фоллс. «Троллейбуска билет алыгыз, ул сезне туристлар йөри торган барлык урыннарга алып барачак», – диделәр. 3 доллар торучы билетлар браслет рәвешендә ясалган, аларны көн дәвамында кулланырга ярый.

Троллейбус тәрәзәсеннән үк шарлавыкның бер чите күренеп калды, зур, көчле суның тавышы ишетелде...

Барыбызга да «дождевик»лар тараттылар, аяк киемнәрен алыштырып, яланаякка сандалилар кидек. Шарлавыкларны без көймәдә кереп карадык. Табигатьнең бер могҗизасы бу! Егермешәр катлы йорт биеклегеннән бик зур тизлектә су ишелеп төшә. Тонналаган! Андагы тавыш! Шарлавыкларга шактый якын алып бардылар: чәчрәгән су тамчылары безгә кадәр килеп җитте. Фотога төшерү мөмкин түгел – бар да томан эчендә... Куркыныч матурлык! Тәэсирләр мин көткәннән күпкә көчлерәк иде... Шушы су ташкынына ияреп, аска төшеп карарга җөрьәт иткән тәвәккәлләр дә бар бит! 1901 елны Энни Тейло дигән укытучы (хатын-кыз!) агач мичкә эчендә утырып шарлавыктан төшә һәм исән кала – башы гына җәрәхәтләнә. Әмма, кызганыч, башкаларга бәхет болай елмаймый...

...Самолетыбыз төнлә очачак. Метрога кергәндә Америкага килеп төшкәндәге кебек үк эңгер-меңгер иде. Нью-Йорк метросы безгә инде ошый да башлаган икән: эскалаторлы станцияләр юк диярлек, бөтен нәрсә аңлатып язылган, чиратлар булмый... Халкы да әйбәт, ярдәмчел: бер генә тапкыр да алдымда бер ишек тә шапылдап ябылмады – һәрвакыт аны кемдер тотып торды. Моны эшләүнең бер авырлыгы юк икән...

Тагын барасыңмы, дип сорыйлар. Барыр идем! Американың уртасында урнашкан искиткеч каньоннарны, Көнбатыш ярдагы зур-зур табигать паркларын, Лос-Анджелес, Сан-Франциско, Майями шәһәрләрен, Диснейлендны күрмәдем бит әле! Ә анда яшәр идемме икән? Юктыр... Минем туган җирем, торган җирем бер генә бит – газиз Татарстаным!


Бу кызык



Сәяхәтебезнең уночсенче көнендә яңадан Нью-Йоркка әйләнеп кайттык. Метрополитен музеен күрәсе килеп калган иде әле. Американнар аны кыскартып, «Мет» дип атый. Рус теле белән чагыштырганда, инглиз теле гел кыскартуга омтыла. Шуның аркасында таныш сүзләрдән торган җөмләләр дә кайчак ребуска әйләнә...
Билет бәясе 19 доллар тора, әмма синьоралар, ягъни 65 тән узганнарга – 17, ә студентларга 16 доллар гына. Бер алган билет белән музейга ике көн рәттән керә аласың. Югыйсә 900 дән артык залны бер көндә генә ничек йөреп чыгасың, ди? Дөньядагы иң бай музейларның берсе бу. Европа, Америка рәссамнарының бик зур коллекциясе, Ренессанс (Яңарыш) эпохасы картиналары... Караваджо, Гойя, Рембрандт, Рубенс, Фрагонар... Импрессионистлар – Ренуар, Климт, Боннар, Матисс. Рус рәссамнарыннан – Репин, Шагал... Тагын Сезанн, Пикассо, Мунк, Ван Гог, Боччони...
Соңгы көнебез дә шушы музейда узды. Индеецларга багышланган берничә зал шаккаттырды. Аларның VIII гасырда ясалган әйберләре Африка халкының XX гасырда иҗат иткән эшләреннән күпкә остарак эшләнгән! Бер зал тулы гел алтын! Менә кайда ул байлык! Яннарына бернинди сак та куймаганнар.
Америка залында Америка рәссамнары картиналарын, XVIII–XIX гасырлардагы бай американнарның өй эче, йорт җиһазларын карадык. Бөтен дөньяга билгеле Рокфеллерлар гаиләсенеке дә бар. Искиткеч бай, зиннәтле!

PRESSA

«УРТАКЛАШЫР СҮЗЕҢ БУЛСЫН...»



Рөстәм СӘРВӘРОВ, «Аксу» компаниясенең генераль директоры; гаилә стажы – 24 ел; ике бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Мин үзем иң элек күзләргә һәм буй-сынга игътибар итәм. Хатын-кызның күзләрендә бөтен нәрсә дә язылган: ул сине кабул итәме, юкмы, ошыйсыңмы аңа, әллә ул сиңа битарафмы... Күзләреннән ул бернәрсәне дә яшерә алмый. Бик оста актрисалар гына уйнарга мөмкин. Ә андыйлар бик сирәк.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Хатын-кыз бит ул! Яратсаң, аның барлык кимчелеген гафу итәргә туры килә. Ә ныклабрак уйласаң... хыянәт юлына басса кичерү авырдыр. Әмма тормышта төрле очраклар була. Әйтик, ир-ат хыянәт итә. Үзе күп вакыт хыянәт дип тә санамый ул аны. Ошыймы-юкмы дип тә уйлап тормый. Бигрәк тә салган баштан. Соңыннан ул аның исемен дә, кыяфәтен дә хәтерләмәскә мөмкин. Ярату-яратмауга бернинди мөнәсәбәте булмаган табигый инстинкт уянган мәл бу... Ә хатын-кыз бу хакта белеп, аңа үч итеп, шундый ук хыянәткә бара кайчак. Миңа калса, бу очракта нәкъ менә ир-ат үзе гаепле. Шуңа күрә ул аны гафу итәргә тиеш тә.

Ә хатын-кыз гел хыянәт итсә, анысы инде дөрес күренеш була алмый, андыйларга «фахишә» диләр... Тик хәтта бу очракта да күп вакыт ирләр үзләре гаепле дип уйлыйм. Димәк, җылы биреп җиткермәгән...

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Миңа алиһә кирәк, ә комфортны аны икәү бергә дә тудырырга була. Шул чакта ул кадерлерәк тә була әле. Бергә обой ябыштыру, өй җыештыру араларны якынайта гына. Үз гомерендә бер тапкыр да идән юмаган кеше генә яңа юган идәнгә пычрак аяк киеме белән баса ала. Үзе тотынып җыештырып карамаса, өйне тәртиптә тотуның никадәр мәшәкатьле икәнен аңлыймыни ул?!

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әйе, була. Без менә 24 сәгать бергә. Ул миңа киңәшче дә, дус та, таяныч та... Мондый очракта икең бербөтен кешегә әйләнәсең. Тормышка караш бер, хыяллар бер... Сөйләшер сүз бер... Бер-береңнән ничек туясың ди?! Икең ике якта эшләп кайтып, сөйләшергә сүз таба алмасаң, тизрәк өйдән чыгып китү ягын карыйсыңдыр кебек тоела миңа. Ә уртаклашыр сүзең булганда, киресенчә, тизрәк өйгә чабасың бит... Бер эш белән янганда, уңышлар да күбрәк була. Ул эшне икең дә хобби дип санасаң – бигрәк тә. Ә безнеке шулай.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Без аның белән бер үк эшне эшләп, бер үк нәрсәләр өчен янып йөргәндә таныштык. Ул мине тулыландырды, мин – аны. Шулай якынайдык... Тәкъдим ничек ясаганны хәтерләмим дә, ул үзеннән-үзе килеп чыкты.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Юк, минем очракта алай түгел. Әйткәнемчә, караш-лар уртаклыгы зуррак роль уйнады. Дөньяга, гаиләгә, тормышка караш. Хәтта аның әти-әнисенә булган мөнәсәбәте дә. Ә ул, аларга кирәк икән, төн уртасында да чыгып китә ала... Тормыш итәргә кеше сайлаганда, туганнары белән арасы якынмы-юкмы икәнлегенә дә игътибар итәргә кирәктер. Мал аркасында туганлык беткән гаиләләр байтак хәзер. Бер танышым сөйли. Хәлле генә кеше ул. «Әти-әнигә гел ярдәм итеп, йорт-җирне карап тордым. Алар мәрхүм булгач, апа-абыйлар бөтенебез бергә җыелдык. Шунда иске генә суыткыч өчен аздан гына сугышып китмәделәр. Бөтенегезгә берәр шундый суыткыч алып бирәм, дигәч кенә тынычландылар», – ди. Шундый хәлләрдән Ходай сакласын...
Тик мондый хәл килеп чыкканга кайчак ата-ана үзе дә гаепле. Шундый бер очракны беләм. Кече уллары әти-әнисен озак еллар карады, соңгы юлга озатты, ә алар йортны читтә яшәгән, елга ике тапкыр гына кайтып күренә торган олы улларына яздырган булып чыкты. Ерактагы кояш җылырак бит... Тегесе исә кайтты да энекәшен гаиләсе белән урамга куып чыгарды...

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Әгәр алар бербөтен булып яши икән, кем күпме алганны сизмәячәкләр дә. Кайтарып куйган, акча бар... Әмма һәр очракны аерым карарга кирәктер. Малны бит төрлечә табып була: бик җиңел генә кергәне бар, акыл яки мускул көче сораганы... Аны ничек чагыштырасың?! Ир-атка, әлбәттә, мондый очракта барыбер авыррактыр. Бигрәк тә без – татарлар малны ир-ат табарга тиеш дип саныйбыз. Ә хатын-кызның урыны – өйдә, балалар янында дибез. Кухняда бикләнеп ятсын димим мин үзем. Һич юк! Бу көннәрдә Заһир Бигиевнең бер романын аудиокитап итеп яздырдык. Детектив ул. Берәүнең йортына полиция килә. Ишекне асрау кыз ача... Узган гасыр башы бу. Икең дә эш белән мәшгуль икән, шул заманның хәлле татарлары кебек, бүген дә өйдә кеше тотарга була: аш-су тирәсенә – берне, бала карарга – икенчене...

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Ятып калганчы атып кал диләрме? Яшь чакта ояласың бит. Кулына кагылсаң да ток суккандай була. Безнең баштан да кичте андый хәлләр... «Их...» – дип соңыннан үкенгәнче, кыз бала хисләрен үзе белгертүнең бер гөнаһысы юк. Югыйсә тормышта бик еш кына шулай да була: берсе аңламый, икенчесе аңлата алмый. Гомер аерым уза, картайгач кына очрашалар. «Нигә шул чакта әйтмәдең мине якын иткәнеңне?» – дип сорый берсе. «Мине яратмыйсың дип уйладым», – ди икенчесе...

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Яшь чакта күбрәк матурлыкка карыйсың – хатын-кыз да шулайдыр. Ә тора-бара: «Ир-ат маймылдан аз гына кайтыш булса, шул җитә», – дия башлый ул. Тормыш тоткасы булсын, аның артында үзеңне калкан белән капланган кебек тою мөһимрәк ди... Аң-белем ягыннан да кеше бер-берсенә туры килергә тиеш дип саныйм: бөтенләй бер китап укымаган, газета-журнал тотмаган хатын-кыз, нинди генә чибәр булса да, үзенә карата алмыйдыр. Сөйләшергә уртак сүз дә кирәк бит әле. Пенсиягә чыгып, өйдә икәү генә калгач, сөйләшергә сүз тапмаган парлар бар. Икесе ике бүлмәдә торалар. Менә бу фаҗига... Шундый ук фаҗига икең ике милләттән булганда да кабатлана. Бер гаиләне беләм. Ире зур дәрәҗәдәге хәрби кеше. Олыгайгач, ул – мәчеткә, хатыны чиркәүгә борылды. Бер түбә астына яши алмас хәлгә җиттеләр. «Икебез дә интегәбез. Әнинең: «Улым, ялгышасың!» – дигән сүзе көн саен исемә төшә», – ди.

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Хатыным белән без шулай килешкән: ул минем эш өстәлемә кагылмый, мин – аныкына. Чикләр икебездә дә бар. Алар булырга да тиеш. Өстәлем никадәр тузган кебек тоелса да, кайбер нәрсәне анда күз йомып та таба алам. Ә көнкүрештә... Минем аннан беркайчан: «Бу әйбер нишләп анда түгел, монда ята?» – дип сораганым юк. Күп әйберне күрмим дә. Атлап чыгып китә алам, кайткач, кире атлап керә алам. Ята, димәк, ятарга тиештер... Иҗат кешесе бит.

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Әгәр бу зур югалтуларга китермәсә, ул хаталарны яңадан төзәтеп булса, юл куям. Яшьрәк чакта шундый бер очрак булды. Хатыныма: «Машина оттыгыз», – дип шалтыратканнар. Һәм тиз арада күпмедер акча салырга кирәк дигәннәр. «Ялган бу!» – дип торам, ә ул мине ишетми. Шулкадәр ышандырганнар: «Менә бит, сайтлары да бар», – ди. Ярый, бирдем акчаны, салды. Ә тегеләр, син бер тапкыр салгач, икенче юлы зуррак сумма сорый. Ике тапкыр салгач: «Булды, җитте, тукта», – дидем. Шуннан соң гына аңлады. Аның каравы, моның кебек афераларны әйләнеп уза ул хәзер.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым дип, диванда кырын ятып тора.

– Беренчедән, мин талымсыз: ипи белән сөт ашыйм да, ятам да йоклыйм. Пешерергә оста түгелмен, билгеле, ләкин гади генә ризык әзерләргә булдыра алам. Ашау проблема түгел бүгенге көндә, шалтыратсаң ярты сәгатьтә китереп бирәләр – акчаң гына булсын. Хәзер кайбер гаиләләрдә суыткыч, гомумән, буш диярлек: алар йә кафеда, йә ресторанда ашый. Ире дә, хатыны да арып-талып эшләсә, бу дөресрәк тә. Икең дә сигез сәгать эшләп кайтып, берең диванда ятып тору, икенчең кич буе почмактан чыкмау дөрес түгел бит. Кафеда ашау очсызрак бугай хәзер. Анда сайлау мөмкинлеге дә зуррак.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан.

– Икебез дә тиз җыенабыз: өч минутта әзер булып, каядыр чыгып китә алабыз. Ярты гардероб эштә безнең: өс-башны алыштырырга өйгә кайтып торырга да кирәкми. Беркөнне менә башта «Үзгәреш җиле»н карадык, аннан – Зур концертлар залына, музыка училищесының юбилеена кердек. Сүз уңаеннан, «Үзгәреш җиле» фестивaленең музыка җитәкчесе Вадим Эйленкриг тамашасына караганда, училище шәкертләре чыгышы минем үземә күпкә ныграк ошады. Аерма шунда гына: беренчесенә, аның оркестрына миллионнар түгәләр. Авырткан җир бу минем... Читтән белгеч чакырырга телиләр икән, чакырсыннар, тик ул килгән кеше безнең оркестр белән эшләсен иде. Үзебезнекеләрне камилләштерү дөресрәк булыр иде: ул музыка безнең белән кала, аны кабат-кабат уйнап була. Казакъстан бу яктан барыбызга да үрнәк булып тора: белгечләрен читкә җибәреп укытып кайтарды да, эстрадасын халыкара дәрәҗәгә күтәрде әнә. Читкә киттем...

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?

– Бер-беребезгә бүләкне, гадәттә, бергә чыгып алабыз. Чәчәкләр сирәк бүләк итәм: алар ике көннән шиңә дә чүп чиләгенә саласың. Шуңа күбрәк гөл алам. Үзем дә гөлләр яратам, ләкин өйдә алар да күбәеп китте инде.



Кызамык

Узган гасырда бик күп гомерләрне вакытсыз кыйган чирләр арасында кызамык дигәне дә бар. Һәр гаиләнең ишеген каккан әлеге зәхмәт, аеруча балаларны аямаган. Кызамыкка каршы вакцина уйлап табылганнан соң гына җиңелгән ул. Хәзер менә кабат баш калкытмакчы. Республика балалар клиник хастаханәсенең эпидемиология бүлеге җитәкчесе, медицина фәннәре кандидаты, югары категорияле табиб Илсөя ФАЗЫЛҖАНОВА белән әлеге куркыныч авыру һәм аны кисәтү юллары турында сөйләшәбез.

Кызамык – үтә дә йогышлы чирләрнең берсе. Аның белән шушы вируска каршы иммунитеты булмаган, вакцина ясатудан баш тарткан яки вакцинадан соң әле тиешле иммунитеты урнашып җитмәгән кешеләр авырырга мөмкин. Бигрәк тә 1 яшьтән алып 5 яшькә кадәр булган балаларга куркыныч тудыра. Кагыйдә буларак, туганнан соң алты айга кадәр балалар кызамык белән авырмый, чөнки бу чорда әле аларның әниләреннән алган иммунитеты нык була.

Югары температура, интоксикация билгеләре, хәлсезлек, тын юллары ялкынсыну, конъюнктивит, соңрак тәннең чабыруы белән узучы әлеге чир бер кешедән икенчегә һава аша йога. Авырлы ханым йөклелекнең соңгы айларында кызамык белән авырса, карынындагы балага да йогу куркынычы бар. Вирус әйләнәтирәлектә озак яшәми, шуңа да ул көнкүреш кирәк-яраклары аша күчми. Авыручы кеше белән турыдантуры контакт булмаса да, куркыныч янамый.

Кызамык чиренең клиник билгеләре дүрт төрле чор белән аерымлана.

Вирусның инкубацион чоры 7–14 көн. Организмына иммуноглобулин яки кан компонентлары, плазма кертелгән пациентларда 21 көн дә булырга мөмкин.

Катараль чор 3-4 көн бара.

Тәннең чабыруы 4-5 көннән башланып, үзе 3-4 көнгә сузыла. Бу чорда температура, интоксикация, катараль синдромнар бик көчле була.

Тәннең тимгелләнү чоры – 7-14 көн.

Тән чабырганчы – 5 көн, аннары тагын 5 көн аралыгында чир үтә дә йогышлы.

Кызамыкның төп билгеләре – катараль чорда яңакның эчке ягында, сирәк очракларда ирендә, казналыкта Бельский-Филатов-Коплик тимгелләре барлыкка килә. Алар бик вак – 1-2 мм зурлыгындагы, ялкынсынулы тар гына кайма белән әйләндереп алынган аксыл-соргылт төерчекләр рәвешендә була. Ул шпатель белән алынмый, 2-3 көнгә кадәр бара.

Баланың температурасы күтәрелеп, коры ютәл барлыкка килсә, күзләре кызарып, яктылыкка карый алмаса, битенә, колак артларына ялпак кызыл таплар чыкса, әлеге билгеләр кызамык башлануын белдерә. Ул таплар бераздан баланың тәненә, кулаякларына тарала, үзара кушыла, ләкин кычытмый.

Кызамык иммунитетны какшатканлыктан, төрле патоген һәм шартлы патоген микрофлораның активлашуына, хроник чирләрнең кискенләшүенә китерә, тын юлларында өзлегүләр китереп чыгара. Бу йогышлы чир белән авырганнан соң, тын юлларында, нерв системасында, күрү һәм ишетү, бәвел бүлеп чыгару органнарында, тән тиресендә төрле ялкынсынулар, өзлегүләр булу ихтимал. Кызамык шул өзлегүләр белән куркыныч та.

Диагнозны фәкать табиб кына куя ала! Дәваны да табиб билгели. Ул амбулатор яки стационар шартларда узарга мөмкин. Кызамык вирусына гына каршы юнәлдерелгән ниндидер махсус дәва чаралары юк. Гадәттә, ялкынсынуга һәм бактерияләргә каршы терапия, ютәлне басучы, температураны төшерүче һәм антигистамин дарулар билгеләнә. Шулай ук А витаминын да бирергә була, ул күзне сукыраюдан сакларга ярдәм итә.

Авыру баланы урынга яткырырга кирәк. Тәрәзәләрне калын пәрдә белән капларга мөмкин. Һәр көн күзләрен, авыз-борын эчен юдыру һәм чайкату мөһим. Авызны чәй содасы эремәсе белән чайкау булыша. Ә күзләргә ялкынсынуны басучы тамчылар тамызалар. Авырган чорда рационда сөт ризыклары булмасын. Ризык тиз үзләштерелешле, витаминнарга бай булырга тиеш.

Моны белү мөһим

■ Кызамыкка каршы вакцина профилактик прививкалар календарена кертелгән. Аның беренчесен балага 1 яшь тулганда, икенчесен 6 яшьләрдә ясыйлар. Моңарчы прививка ясалмаган яки булып та, ул хакта беркайда да теркәлмәгән очракта, вакцинаны 55 яшькә кадәр теләсә кайчан кадатырга була.



Мастопатия

Хатын-кызның матурлыгы да, горурлыгы да, бизәге дә – күкрәк. Ләкин ул аның иң нечкә җире дә... Күкрәк бизендә ниндидер үзгәрешләр булуын тоеп, кайсыбыз гына хафага төшмәс икән. Андый чакта күңел төрлесен уйлый. Күкрәк бизендәге һәр төер яман шеш дигән сүз түгел. Күп очракта ул мастопатиянең билгесе булып чыга. Республика клиник онкология диспансерының баш табиб урынбасары, медицина фәннәре кандидаты, югары категорияле табиб-онколог Илсур ШӘЙМӘРДАНОВ белән шул хакта сөйләшәбез.

Мастопатия – җыелма мәгънәдә әйтелүче сүз. Мин аны хәтта авыру дип тә әйтмәс идем. Ул күкрәк бизенең функциональ бер халәте. Ләкин алай да мастопатия онкологларның игътибарында тора. Ник дисәгез, күкрәк яман шеше белән мастопатия дип аталган функциональ халәтнең килеп чыгу сәбәпләре бертөрле.

Бүгенге көндә ул сәбәпләрне төгәл генә әйтә дә алмыйлар. Алай да инде тикшерелгән берничә сәбәпне атарга мөмкин: күремнең бик иртә башлануы һәм соң бетүе, гәүдәнең артык авырлыгы, тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр куллану, күкәйлектәге, бавырдагы, калкансыман биздәге чирләр. Күкрәк бизе хатын-кыз организмында була торган һәрбер гормональ үзгәрешкә бик сизгер.

Халыкта һәм кайбер табиблар арасында да, мастопатия – яман шешнең башлангыч чоры, дигән сүз йөри. Бу дөрес түгел. Мастопатия яман шешне китереп чыгармый. Гомере буе мастопатия билгеләре белән яшәүче, күкрәгендә төерләр булган хатын-кызларның 60 процентында яман шеш күзәтелми. Ә икенче бер өлешендә мастопатия билгеләре булмый, булган очракта да ул клиник чагылыш тапмый, әмма яман шеш башлануы ихтимал.

Күрем килер алдыннан күкрәкнең тыгызлануы, сызлавы – мастопатиянең бер билгесе. Кайчак күкрәктә каты төерләр дә барлыкка килә.

Табиб киңәше

- Балигъ булып, күкрәк бизе үсә башлауга, кыз балаларны маммологка күрсәтергә кирәк. Үз сәламәтлегеңне кайгырту культурасы балачактан ук тәрбияләнергә тиеш.
- Сәламәт яшәү рәвеше – тәмәке, спиртлы эчемлекләрне кулланмау, гәүдәнең авырлыгын нормада тоту, вакытында кияүгә чыгып, тәртипле җенси тормыш алып бару, баланы тиешенчә имезү – мастопатияне кисәтү чарасы булып тора.

Имчәк башыннан бүлендек килергә мөмкин. Күкрәк бизендә берninди үзгәрешләр сизелмәсә дә, елга бер тапкыр маммологка күренергә кирәк. Мастопатия гомергә куркыныч яный торган чир булмаса да, хатын-кыз табибның җентекле күзәтүе астында булырга тиеш. Аеруча аның төерле формасы даими күзәтү һәм игътибар сорый. Медицинада кабул ителгән стандартлар буенча, күкрәктәге каты төерләр алынырга һәм гистологик тикшерүгә җибәрелерегә тиеш. Диагнозны төгәеп ачыклар өчен эшләнә ул.

Мастопатия халәте УЗИ яки маммография ярдәмендә ачыклана. Гадәттә, маммография 45 яшьтән соң гына билгеләнә, чөнки гормональ актив чорда хатын-кызның күкрәк бизе тыгыз була һәм маммография барлык үзгәрешләрне күрсәтмәскә мөмкин. Шуның өчен яшь туташларга һәм ханымнарга УЗИ тикшеренүе билгеләнә. Хатын-кыз өчен иң куркыныч чор – климакс башланыр алдыннан булган вакыт һәм климакс чоры. 75 яшьтән соң күкрәк яман шеше ихтималы кими.

Күп кенә пациентлар, мастопатия булганда кояшта кызынырга, кайнар мунчада юынырга ярыймы, дип сорау бирәләр. Аның төерле формасы (узловая) булмаса, әлеге халәтнең чынлап та яман шеш түгеллеге ачыкланса – тыюлар юк.

Мастопатия халәте дәвалауны таләп итми. Алай да медицинада пациентларның хәлен җиңеләйтүче препаратлар кулланыла. Аларны табиб билгели. Әйткәнемчә, төерләр булганда, аларны алдырырга кирәк. Бу – пациентның үзе өчен иминлек чарасы булып тора. Һәм, әлбәттә инде, хатын-кыз елга бер тапкыр маммологка күренергә тиеш.

Моны белү мөһим

- Галимнәр күкрәк бизенең нәселдән килүче формасы барлыгын ачыклаган. Моның өчен BRSI гены җаваплы. Әлеге генның булу-булмавы кан анализы ярдәмендә билгеләнә. 2013 елда Америка артисты Анжелина Джоли ике күкрәген дә алдырып, җәмгыятьнең игътибарын әлеге проблемага юнәлтергә тырышты. BRSI гены табылган очракта, кеше үзенең сәламәтлегенә өчләтә игътибарлырак булырга тиеш.

Корольләр табыныннан

Шәрык үзенең серләрен тиз генә ачып бирергә ашыкмый. Яшәү рәвешләре, тормыш кануннары, хәтта аш-су әзерләү үзенчәлекләре дә җиде кат йозак астында саклана. Без үзебез дә кунакларны шаккаттырырлык нинди дә булса үзенчәлекле ризык әзерләргә яратабыз инде анысы. Менә бүген сезгә тәкъдим итәсе ризыкның да тарихы бик кызыклы. Ә тәме-е-е! Бөтен дөньяның аш-су серләрен өйрәнүче – Сталика ХАНКИШИЕВ аны Мароккога барып, король сараенда яшәп, шундагы аш-су әзерләүчеләрдән өйрәнеп кайта. Шулай итеп, Марокко корольләре ризыгының сере ачыла.
Ә безгә бу затлы ризыкны Казанда яшәүче тәҗрибәле аш-су остасы, үзе дә 15 илдә сәяхәт кылган Дамирә ханым МАКСУТОВА әзерләп күрсәтте.
Марокко кухнясы – төрле кулинар традицияләрнең кушылмасы, аш тәмләткечләренең чын ярминкәсе ул. Йә, без дә әзерләп карыйбызмы?





Кирәк:
- 1-1,5 кг ит;
- 1 кг дөге
(«Басмати» сорты кулланыла);
- 2 данә айва;
- 2 данә лимон;
- 5 данә груша;
- 2 кг суган;
- 2-3 аш кашыгы томат пастасы;
- анар согы.

Аш тәмләткечләре: корица, зира, кара борыч, куркума, канәфер, кориандр, шикәр комы, тоз.













Фото: Анна Арахамия

Эш тәртибе

■ Ике-өч көн алдан бераз тоз сибеп, итне суыткычка куябыз. Пешкәндә бик йомшак булсын өчен ул какланган иткә әйләнергә тиеш.

■ Пешерер вакыт җиткәч, шул итне алып казанда яки зур табага май салып берәм-берәм ике яклап кызарганчы кыздырып алабыз. Ит кисәкләренең артык кечкенә булмавы мөһим! Аннары зур казанга ваклап туралган суганны салып кыздырабыз. Суган өстенә ит кисәкләрен, бер аш кашыгы шикәр комы, тәменчә тоз, куркума, кориандр, зира, 2 аш кашыгы томат һәм ит күмелгәнче су салабыз да ике сәгатькә утка куябыз. Ит йомшак, шулпасы әчкелтем-татлы булырга тиеш.

■ Дөгене савытка салып, пешкәндә ябышмасын өчен башта ике сәгать җылы суда тотабыз, аннары җиде кат чайкап түгәбез. Ул арада зур кәстрүлдә су кайнатып чыгарабыз, шуңа тоз һәм юылган дөгене салып, бутап алабыз.

■ Лимоннарны дүрткә бүлеп, төшләрен алабыз. Суга азрак тоз һәм шикәр комы салып, лимон кисәкләрен шул суда 20 минут пешерәбез.

■ Икенче бер савытка су, азрак шикәр комы, анар согы, корица, түгәрәк борыч, канәфер, кабыклары чистартылган грушаны һәм дүрткә бүленгән айваны салабыз. Айва белән грушаны кызгылт төскә кергәнче 20 минутлап утка куеп пешерәбез.

■ Дөге пешеп чыккач, аны саркытабыз һәм алдан әзерләп куелган зур савытка салабыз. Дөге өстенә пешкән итне куябыз. Ит пешкән хуш исле шулпаны дөге өстенә кашык белән аз-азлап салып чыгабыз. Алар янына пешкән груша, айва һәм тозлы лимон куела.

■ Барысы да әзер булгач, әлеге ризык өстенә тозлы чия сибеп җибәрәбез. Ул аерым бер хуш ис (пикантлык) биреп торачак.

Чияне тозлау: катырган чияне салкын суга салабыз, өстенә азрак тоз сибеп, 15–20 минут шунда тотабыз.

Бу ризык табынга зур савыт белән чыгарыла. Һәркем үзенә кирәгенчә тәлинкәсенә дөге, ит, айва, груша бүлеп ала.

Марокко ризыгы – өстәлдә! Корольләр белән бергә без дә татып карыйк әле!

Рәхим итегез!

Салатны матур итеп өстәлгә бизәп чыгарганда ул тагын да тәмлерәк була сыман. Бизәр өчен укроп, черри помидоры, гранат төшләре, петрушка яфраклары, кызыл яки сары борыч кисәкләре кулланырга була. Менә бу салат өстендәге ала миләүшә (анютины глазки) чәчәге бик файдалы япон тормасыннан ясалды. Төрле төсләргә кертер өчен тәмләткечләр, яшелчә, җиләк-җимеш сулары кулланылды.

■ Сары төс – куркума.

■ Шәмәхә – кызыл чөгендер.

■ Алсу – нарат җиләге (брусника).

■ Чәчәкнең үзәгенә алтын төстәге кандурин сибелде.





Фото: Камилә Димөхәмматова

Дөрес тукланырга һәм менюларын төрләндерергә теләүчеләр өчен яшелчә котлеты менә дигән! Аны теләсә кайсы яшелчәдән әзерләргә була. Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА исә брокколи һәм чәчәк кәбестәдән әзерләргә тәкъдим итә.

Котлет... яшелчәдән

Брокколи – ашкайнату эшчәнлеген яхшырта, иммунитетка һәм йөрәк-кан тамырлары системасына уңай тәэсир итә. Аның иң кыйммәтле үзлеге – ашказаны һәм эчәклек яман шешеннән саклау. Чәчәк кәбестә исә ялкынсынуны басу, йөрәк-кан тамырлары системасының эшен көйләү үзлегенә ия. Әлеге яшелчә баш мие эшчәнлегенә уңай тәэсир итә, артык авырлыктан котылырга булыша.
Яшелчә котлетларын тазә яшелчәләрдән дә, туңдырылганыннан да әзерләргә мөмкин.
Тазәләрен алдан – җиде минут чамасы пешереп алырга кирәк булыр, ә туңдырылганнарын эретү дә җитә.



Фото: www.pixabay.com

Котлет өчен кирәк:
- 300 г брокколи;
- 300 г чәчәк кәбестә;
- 200 г «Мексика җыелмасы» (аны кишергә алыштыра аласыз) алына.

Эш барышы:
Яшелчәләрне блендерда ваклап, 2 аш кашыгы көрпә (отруби), 2 аш кашыгы чистартылмаган бөртектән тарттырылган он (цельнозерновой), 1 йомырка сарысы, тоз-борыч, күңелегезгә хуш килгән аш тәмләткечләр кушабыз. Без исә «Италия үләннәре» тәмләткече һәм киптерелгән сарымсак салдык. Йомырканың агын күбекләнгәнче күпертеп, яшелчә массасына кушабыз һәм сак кына туглыйбыз.
Котлетларны сары майда кыздырабыз.
Ашларыгыз тәмле булсын!

Кучкар. Сезнең өчен бай эчтәлекле ай булачак. Елны яңа максатлар белән башлап җибәрсәгез, язга таба уңышка ирешерсез. Авырлыклардан курыкмыйча, алардан файда алырга тырышырга кирәк.

Үгезбозау. Шәхси тормышыгызда зур уңышлар көтелә. Күптәннән хыялланган сәяхәткә китеп барырсыз. Иң мөһиме: үткәннәр белән яшәмәгез һәм берничә дә курыкмагыз. Яңа һөнәрләргә өйрәнә башласагыз да ярый.

Игезәкләр. Өстәмә керем турындагы уйларыгызны әлегә читкә куеп торыгыз, шуның аркасында сәламәтлек белән проблемалар килеп чыгарга мөмкин. Ай ахырында хезмәтегезгә югары бәя бирелер.

Кысла. Югалтулар һәм табышлар ае булыр. Тормышны уңай якка үзгәртер өчен кирәкле кешене очратуыгыз ихтимал. Ял көннәрен гаиләгез белән уздырырга тырышыгыз, өйдәгеләр күптән сезнең игътибарга мохтаҗ.

Арыслан. Икеләнүләрегездән арына алсагыз, хыялларыгызны тормышка ашырыр өчен әйбәт ай. Имиджыгызны үзгәртер вакыт җиткән. Сездәге үзгәрешләр яраткан кешегезне романтик рухка этәрер.

Кыз. Бу айда финанс хәлегез яхшырыр. Танышларыгыз арасында сездән көнләшүчеләр табылыр, сак булыгыз! Шуңа күрә шатлыкларыгыз турында күп сөйләмәгез. Китап укып, яраткан киноларыгызны карап, үзегезгә ял оештырыгыз.

Үлчәү. Төрле алымнар белән бәхетегезне сынар чак. Ерак булмаган җиргә сәяхәткә бару җаен тапсагыз, яңа идеяләр белән кайтырсыз, көч тупларсыз.

Чаян. Күптән борчыган сорауларга көтелгән җаваплар табарсыз. Гомерлек мәхәббәтегезне очратып, гаилә кору мөмкинлеге дә туарга тора. Эш эзләүчеләр яхшы эш таба алыр. Иң мөһиме: хыялыгызга ышаныч белән атлагыз.

Укчы. Эшлекле сөйләшүләр, килешүләр өчен кулай вакыт. Теләгәнегезгә тырышлык һәм үҗәтлек аша ирешерсез. Шуңа күрә могҗизага ышанып, кул кушырып утырырга ярамый. Һәр өлкәдә җитди, җаваплы булырга кирәк.

Кәҗәмөгез. Спорт белән актив шөгыльләнергә вакыт. Дөрес тукланырга, табигатькә чыгарга, йокларга, рәхәт кешеләр белән аралашырга тырышыгыз. Туганнарыгыз, якыннарыгызга ярдәм итүдән баш тартмагыз.

Сукояр. Көтелмәгән чыгымнар килеп чыгуы бар. Мәхәббәттә юл куярга, уйларыгызны тәртипкә салырга тырышыгыз. Уңай энергияле кешеләр белән аралашу әйбәт булыр.

Балык. Ай ахырында күптән көтелгән яхшы хәбәр килеп ирешер. Уңышлардан башыгыз әйләнеп, дусларыгыз һәм якыннарыгызга буш вәгъдәләр бирүдән сак булыгыз. Әйткән вәгъдәгезне үтәмәү аркасында аларны югалтуыгыз бар.

ТИРӘ-ЮНЬДӘГЕЛӘР ӨЧЕН СЕЗ НИНДИ?

Башкаларның фикерен хөрмәт итәсезме? Хезмәттәшләрегезнең сүзенә колак саласызмы? Сез сабыр кешеме? Башкаларга карата мөнәсәбәтегезне ачыклар өчен тест узып карагыз әле. Сорауларга тиз генә, озаклап уйланмыйча гына җавап бирергә кирәк.

СОРАУЛАР:

1. Сезнең өчен кызыклы булып тоелган идеяне беркем дә хупламаса, күңелегез төшәчәкме?

а) Әйе.

б) Юк.

2. Дусларыгыз сезгә бергәләп ниндидер уен уйнарга тәкъдим итсә, кайсы юлны сайлыйсыз?

а) Кем яхшы уйный, шул гына катнашсын.

б) Уен кагыйдәләрен белмәүчеләр катнашуга да каршы килмәячәксез.

3. Күңелсез хәбәрне тыныч кына кабул итә аласызмы?

а) Әйе.

б) Юк.

4. Җәмәгать урыннарында аек булмаган кешеләрне күрсәгез ярсыйсызмы?

а) Чикләрне узмасалар, исем китми.

б) Үз-үзен тота белмәгән кеше һәрвакыт ачуымны китерә.

5. Дәрәҗәләре, һөнәрләре, традицияләре белән сездән аерылып торучылар белән уртак телне тиз табасызмы?

а) Уртак тел табу авыр.

б) Андый әйберләргә исем китми.

6. Сезгә карата шаян сүз әйтсәләр, реакциягез нинди була?

а) Шаяртуларны да, мәзәк сүз сөйләүчеләрне дә яратмыйм.

б) Шаяртуга шаян сүз белән җавап бирәм.

7. Күпләр тормышта үз урынын таба алмый дигән сүз белән килешәсезме?

а) Әйе.

б) Юк.

8. Дустыгыз компаниянең игътибар үзәгендә булса, ничек карыйсыз?

а) Миңа игътибар итмәүләре кәефне кырачак.

б) Аның өчен шатланачакмын.

9. Кунакта хәзерге яшьләрне сүгүче өлкән буын вәкилен очратсагыз, сез...

а) Уңай сәбәп табып, иртәрәк китәргә тырышасыз.

б) Туйганчы бәхәсләшәсез.

НӘТИҖӘЛӘР:

1б, 2б, 3б, 4а, 5б, 6б, 7б, 8б, 9а җавапларына **2 балл** бирелә.

0-4 балл. Сез кире һәм үзсүзле кеше. Сезнең хакта: үз фикерен тагарга ярата, диләр. Максатыгызга ирешер өчен тавышыгызны күтәрүдән уңайсызланмыйсыз. Белдекле булырга тырышуыгыз башкалар белән уртак тел табарга комачаулый.

6–12 балл. Үз фикерегезне ачык итеп әйтә аласыз. Кешеләр белән уртак тел таба беләсез. Кирәк икән, җайлап кына фикерегезне дә үзгәртәсез. Әмма кайчак артык кискен итеп әйтеп кую, тавыш күтәрү дә хас сезгә.

14–18 балл. Һәртөрле яңалыкны җиңел кабул итәсез. Фикерегез дөрес булып чыкмаса, аннан җайлы гына баш тарта аласыз.

тест

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Раилә ХӘЯЛИЕВА әзерләде.





Җылылык, ихласлык бөркелә

«Нинди сәер сынлы сәнгать бу натюрморт: оригиналларына ис тә китмәгән әйберләрнең күчермәләренә сокланырга мәҗбүр итә», – дип язган заманында француз математигы Блез Паскаль. Әйе, аның чорында да һәм башка гасырларда да яшәгән байтак рәссамнар үз сәләтләрен шушы жанрда сынап караган. Хәзер дә бу темага алынучылар күп.

Менә Балтачта яшәп иҗат итүче Таһир Ильясов картиналарына карагач, натюрмортлары киндергә әле икенче елын гына языла дип һич уйламассың! Моңа кадәр ул сәләтен пейзаж һәм портрет жанрында чарлаган. «Соңгы елларда антиквар җиһазларны реставрациялим, шуннан бирле әйберләр дөньясы күңелемне ныклап биләп алды, – ди оста. – Алар бит киндерләрдә башкачарак килеп чыга, мондый картиналар бәйрәм тантаналары өчен дә бер дигән бүләк!»

Әсәрләрен ул академик язу рәвешендә башкара, Балтач сынлы сәнгать мәктәбендә укыган балаларны да 23 ел дәвамында бары тик академик сынлы сәнгать белеменә генә өйрәткән. Ике дистәдән артык укучысы нәкъ менә рәссамлык юлын сайлаган!

Таһир Марсель улы «Россия рәссамнар берлеге» иҗтимагый иҗат оешмасының «Татарстан рәссамнар бүлеге» әгъзасы буларак, бүлек оештырган бар күргәзмәләрдә теләп катнаша, әсәрләре XI һәм XII «Зур Идел» күргәзмәләрен бизи.

«Рәсем ясау канга сеңгән, – ди ул. – Балачакта да күп ясалды ул рәсемнәр, Казан сынлы сәнгать училищесында укыганда да, полк рәссамы булып хезмәт иткәндә дә, укыту дәверендә дә...»

Хәзерге көндә ул – ирекле рәссам, димәк, вакытын иҗат өчен күбрәк сарыф итә. Күңелләргә үтемле натюрмортларындагы тотрыклы композицияләрнең эчтәлеге бары тик татар рухын, татар мохитен сурәтләүгә юнәлдерелгән. Аларда халкыбызның, милли колориты, кунакчыллыгы, үз тарихына булган игътибары тулы чагылдырылган, гамәли әйберләрнең формалары, сыйфатлары, төсләре бербөтен итеп колачланган. «Мин татар булуыма, татар җирендә яшәвемә куанам, шуңа күрә әсәрләрем дә шатлык хисләре аша туа», – ди Таһир Ильясов. Әлеге кышкы салкын кичләрдә дә натюрмортларыннан ихласлык, күңел күтәренкелеге, яшәү яме, җылылык бөркелә. Рәссам кәгазь битләренә нидер сыза: яңа әсәр композициясе төзелә. Матур, кабатланмас, Таһирча үзгә!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА







ТАҺИР ИЛЬЯСОВ

ТАССР

Празднование 100-летия Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

1920-2020



Ренат ВӘЛИУЛЛИН,
Татарстан Республикасының
Санкт-Петербургтагы һәм
Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле

Кадерле дуслар! Без зур тарихи вакыйгалар елына аяк бастык. Күңелдә тирән җаваплылык та, рәхәт бер тантана да бар: Татарстаныбыз олы юбилейга әзерләнә!
ТАССР төзелүгә 100 ел булачак! Бу вакыйга гади юбилей датасы гына түгел, ә безнең милләтнең яңа үсеш этабы башлану дәвере. Бүгенге көндә Татарстаныбыз – бар юнәлешләр буенча да әйдәп баручы төбәк. Ул – куәтле индустрия, фән-техника, авыл хуҗалыгы республикасы, мәдәният-сәнгать, спорт үзәге. Эш сөючән фидакарь халкыбыз тырышлыгы белән уңышларга, шундый югарылыкларга ирештек. Алга карап эш итә белгән зирәк Татарстан җитәкчелеге һәрвакыт халык мәнфәгатьләрен беренче урынга куеп эш итте һәм халкыбыз хөрмәтен яулады.

Татарстан Республикасының уңышлары читтә яшәүче милләттәшләребез өчен дә зур сөенеч. Кайда гына яшәсә дә, татар кешесе тарихи ватаныбызга омтыла, аңа үзенең яклаучысы, таянычы итеп карый.
Алдагы елларда да Татарстаныбызга иминлек, бәрәкәт, үсеш һәм тынычлык телибез.

